ЯҢАШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

№11 (382)
НОЯБРЬ 2023

1920 ЕЛДАН НӘШЕР ИТЕЛӘ

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

КЫТАЙ ДӨНЬЯСЫНА ЮЛАМАН

№11 (382)
НОЯБРЬ 2023

16+

Редакция:
420066, Россия, ТР,
Казан, Декабристлар ур., 2,
тел. (843) 222-09-79
tatarstan@tatmedia.com

РЕДАКЦИЯДӘН

КАРАРГАМЫ, ӘЛЛӘ УКЫРГАМЫ?

Хәзер кешегә хәрефләр белән эш итү катлаулырак кебек. Алфавитка хөрмәт кимеде, ихтыяҗ юк – хәрефләре артык күпме шунда? Ә хәрефләрдән җыелган сүзләр тагын да күбрәк. Әле тагын шулардан торган җөмләләре бар... Катлаулы, кушма, тезмә җөмләләр... Җитмәсә аналитик, синтетик төрләре дигәннәре дә бар. Барысын да белеп кара! Укуы, төшенүе, аңлавы авыр, дөресрәге, озак.

Һәм бу эш белән шөгыльләнергә вакыт та юк – монысы, мөгаен, төп дәлилдер. Рәсемнәрне карап чыгу тизрәк тә, уңайлырак та, гадәтирәк тә. Хәрефләр саны рәсем һәм видеоларны карап чыгу ягыннан оттыра, билгеле. Хәзер барысы да шул карап чыгулар саны белән үлчәнә бит. Рәхәтләнеп карап чыгасың – шул җитә. Бармакларыңны егерме секундлап ял иттереп аласың да, тагын карарга мөмкин. Аның каравы һәрвакыт барлык вакыйгалардан хәбәрдар буласың.

Рәсемнәрне карау өчен – безнең «Телеграм» һәм башка социаль челтәрләргә рәхим итегез! Ә хәрефләрне чүпләү өчен элеккегечә бирегә – журналга күз салыгыз! Монда алфавиттагы хәрефләр элеккегечә үк – сүзләргә, аннан соң җөмләләргә, кызыклы тарихларга әйләнә – аларның мәгънәләре дә нәкъ менә укуда ачыла. Битләрне кыштырдатып карап чыгарга да була. Күпләргә шул кыштырдау тавышы ошый да. Уку модасы әкренләп кире кайта, диләр. Чөнки акыл ияләре акыллы сүзләрен тикмәгә генә әйтеп калдырмаган: «Бай кешеләрдә – зур китапханә, ярлыларда зур телевизор булыр». Ясисә зур телефон экраны – болай заманчарак яңгырый. Сезне «Татарстан» китапханәсенә чакырабыз – басмабыз битләрен кыштырдатып укырга, карарга һәм баерак булырга.

Сезнең бай редакциягез.

Укырга | Карарга

Баш мөхәррир: Татьяна Николаевна Вафина,
vafina@tatmedia.com
Шеф-редактор: Әскәр Сабиров,
sabirov@tatmedia.com
Баш мөхәррир урынбасары: Фәридә Әхмәтҗанова
Бүлек мөхәррирләре: Руфия Фазылова, Николай Коновалов,
Евгения Чеснокова, Дмитрий Сивков
Веб-редактор: Алсу Троицкая
Авторлар: Илдус Заһидуллин, Айдар Шәйхин, Луиза Янсуар
Гөлсем Спасская, Наилә Хәйретдинова
Фотографлар: Александр Ефремов, Алсу Шакирова,
Ната Смирнова, Нурислам Исмәгыйлов
Дизайн-макет: Олег Бурилов
Вёрстка: Анастасия Хатыйпова, Игорь Глушков
Препресс: Игорь Глушков
Корректор: Айсылу Корманова
Тышлыкта: Аида Демьянова, «ВАНМЕЙ ГРУПП»
консалтинг агентлыгына нигез салучы, Казанда
өч кытай ашлары рестораны хуҗасы, Кытай белән
бизнес оештыру буенча эксперт.
Фото Аида Демьянованың шәхси архивыннан.

Журнал 1920 елдан нәшер ителә
1977 елда Халыклар дуслыгы
ордены белән бүләкләнә

Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр
һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек
буенча федераль хезмәттә теркәлгән. Теркәлү таныклыгы
ПИ № ФС77 – 66045, 10.06.2016.

Тираж:
2 400 данә
Бәясе ирекле

Редакциянең язма рөхсәтеннән башка «Татарстан»
журналындагы материалларны күчереп бастыру тыела.
Күчереп бастырганда, журналның исемен күрсәтү мәҗбүри.
Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә
мөмкин. Реклама материалларының эчтәлеге өчен редакция
җавап бирми.
Журнал «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс»
полиграфия-нәшрият комплексы типографиясендә
басылды: 420066, Россия, ТР, Казан, Декабристлар ур., 2

Заказ №: С-2986
Басарга кул куелды: 14.11.2023
Чыгу көне: 20.11.2023

Коммерция директоры:
Рәшит Хәйретдинов,
тел.: (843) 222-09-76, +7-9600-487-900
Коммерция директоры урынбасары:
Алина Майорова ,
тел.: (843) 222-09-76, +7-9033-132-741
Дистрибуция һәм трафик бүлеге җитәкчесе:
Миләүшә Байрашева, milyaushanb@tatmedia.com

«Татарстан» журналы шулай ук рус телендә 2350 данә
тираж белән чыга.
Гомуми тираж: 4750 данә.
Реклама 16+

Бухгалтерия:
Ольга Басаркина, тел.: (843) 222-09-80

Редакция советы:
АЛЕКСАНДРОВСКАЯ Ирина Алексеевна
ӘХМӘТШИН Равил Кәлимуллович
БЕЛЯКОВ Роман Юрьевич
БИКЧӘНТӘЕВ Фәрит Рәфкатович
БОЛЬШАКОВ Андрей Георгиевич
ВӘЛИЕВА Зилә Рәхимҗановна
ГАЛИЕВ Марат Гадыевич
СӘЛӘХОВ Мәгъзум Кәлимуллович
ФАЗЛЫЕВА Ләйлә Ринатовна
ФӘЙЗУЛЛИН Равил Габдрахманович
ХӘКИМОВ Рафаэль Сибгатович
ХОМЕНКО Вадим Васильевич

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла

Басма Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча федераль агентлык ярдәмендә нәшер ителә

ТАТ МЕДИА

Гамәлгә куючы: «ТАТМЕДИА» АҖ
Нәшер итүче: «ТАТМЕДИА» АҖ
420097, Россия, ТР, Казан,
Академическая ур., 2

«Татарстан» журналына ТРның барлык элемтә бүлекләрендә язылырга мөмкин:
Индекс **П2381** – татар телендә ярты елга
Индекс **ПА468** – татар телендә бер елга

Индекс **П2378** – рус телендә ярты елга
Индекс **ПА471** – рус телендә бер елга

2024 елның яртыеллыгына ТР буенча язылу бәясе:
1212 сум 00 тиен китереп бирешле,
1175 сум 40 тиен соратып алганда.
2024 елга ТР буенча язылу бәясе:
2423 сум 92 тиен китереп бирешле,
2350 сум 66 тиен соратып алганда.

«Татарстан» журналына РФ буенча онлайн-язылу:
Индекс **П7077** – татар телендә
Индекс **П7076** – рус телендә

«Халыклар атасы»ннан троллейбус

Беренче троллейбуслар Казанда нәкъ 75 ел элек – 1948 елның 7 ноябрендә пәйда була. Бу көнне линиягә чыккан сигез МТБ-82 троллейбусы Куйбышев мәйданын (хәзерге Тукай мәйданы) Соцгород янындагы Караваево бистәсе белән тоташтыра. 11 километрлы маршрутта алты тукталыш ясала, йөрү бәясе юлның озынлыгына бәйле була. Шунысы кызык: Казанда троллейбус хәрәкәтен оештыру турындагы документны «халыклар атасы» үзе раслый. СССР Министрлар Советы Рәисе Иосиф Сталин тарафыннан 1948 елның 13 февралендә имзаланган Министрлар Советы карарында болай дип язылган: «1. Авиация сәнәгате министрлыгына түбәндәгеләрне йөкләргә: а) Казан шәһәренең Ленин районын Куйбышев мәйданы белән тоташтыра торган 11 км озынлыктагы троллейбус линиясен төзергә, 1948 елда моның өчен чыгымнар күләме – 6 1250 мең сум... ж) 1948 елның беренче яртыеллыгында Казан шәһәре Башкарма комитетына РСФСР Министрлар Советы фондлары хисабыннан 8 троллейбус машинасы тапшырырга». Казан СССРда троллейбус хәрәкәте оештырылган егерменче шәһәр була, РСФСРда – унынчы.

© «Татарстан» журналы

WWW.PROTATARSTAN.RU

ЭЧТӘЛЕК

акыллы гамәлләр

4. Контракт – ЗАГС түгел
Бизнес-форумда нинди нәтиҗәләргә ирешелде

8. Инвестицияле климат
Кайда яхшырак

14. Партнёрлык финанслары серләре
Ислам банкингы буенча эксперимент ни өчен кирәк

игелекле эшләр

30. Киләчәккә юллама
Мәктәптә һөнәр сайлау эше ничек куелган

34. Чаяннан – тәм-том
Попкорнны катык белән ничек ашарга

40. Үзебезнекеләр
Апас якташлык җәмгыяте нинди традицияләрне саклый

46. Табигать могҗизалары
Татарстанга аюлар каян килгән

мәңгелек кыйммәтләр

52 ...Үлгәннәрнең каберен бел
Сугышта сигез баласын югалткан Фатыйха Әхмәдиевага һәйкәлне кем куяр

56. Онытылмас исемнәр
Әхмәтгәрәй Хәсәни нинди мирас калдырган

60. Тарихи сәхифәләр
Кем ул «татарның Островские»

80. Татарстан авыллары
Ташбилгедә ни өчен «Татарстан» журналын яраталар

86. Афиша
Кайда нинди чаралар үткәрелә

88. Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елы
Быел «Каз өмәсе» кайда үтте

Тулырак мәгълүмат түбәндәге сайтта: protatarstan.ru

Фото: 100tatarstan.100tatarstan.ru

Акыллы гамәлләр

31.10

Марат Җәббаров, ТР премьер-министры урынбасары – авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры, – «Бизнес-Онлайн» газетасы белән әңгәмәсендә:

– Көнбатыштан Көнчыгыш илләренә борылырга туры килде. Көнбатыш илләре белән импорт һәм экспорт буенча бөтен эш туктатылды диярлек. Узган ел Татарстанның агросәнәгать комплексы тарафыннан 450 миллион долларлык продукция экспортланган. Быел, 1 октябрь мәгълүматларына караганда, без экспорт буенча 20 процент үсеш белән барабыз. 54 илгә сатабыз.

Игелекле эшләр

23.10

Илсур Метшин, Казан мэры, – «Россия – спорт державасы» XI Халыкара спорт форумында ТР башкаласы иң яхшы спорт муниципалитеты итеп танылганнан соң:

– Әлеге эш муниципалитет тарафыннан өстенлекле юнәлеш итеп сайланды. Сәламәтлек бишьеллыгында без үз алдыбызга амбициоз максатлар куйдык: ул вакытта Казан халкының 13 проценты системалы рәвештә спорт белән шөгыльләнә иде, без бу күрсәткечне дүрт тапкырга диярлек арттырып, халыкның 50 процентын спорт белән системалы шөгыльләндерүгә тарту һәм сәламәт яшәү рәвеше тарафдары итү буенча эш алып бардык. Һәм үз максатыбызга ирештек.

Мәңгелек кыйммәтләр



27.10

Фаррух Закиров, «Ялла» ансамбленең сәнгать җитәкчесе, – үзенә Татарстанның халык артисты исемен бирү турында ишеткәннән соң:

– Бу олы хөрмәт һәм зур шатлык! Казахстан, Кыргызстан, Таҗикстан һәм хәзер менә Татарстанның халык артисты. Беренче чиратта, мин моны халкыма хөрмәт буларак кабул итәм. Мин Үзбәкстанда татарларның зур диаспорасы белән бик якын элемтәдә. Безне күп нәрсә берләштерә: күркәм традицияләр, бездә алар күп, тел бер үк, дин. Шуңа күрә дуслашырга кирәк!

Фото: tatar-inform.ru, uz.sputniknews.ru / Рәмис Бәхтияров

игелекле эшләр

акыллы гамәлләр/

мәңгелек кыйммәтләр

Бу санда тәкъдим итәбез:

Үзбәк форумы **нәрсәләр** бирде

Кытай белән бизнесны **ничек** дөрес итеп оештырырга

Ни өчен ислам банкингы Россиядә экзотика булудан туктый

ТАШКЕНТ – КАЗАН: ЕРАК АРАЛАРНЫ ЯКЫНАЙТЫП

Дмитрий Сивков

3,5 миллиард долларлык контрактлар, сәнәгатьнең төрле тармакларына караган 3 төбәкара һәм 7 коммерцияле килешү – болар барысы да Россия һәм Үзбәкстан арасындагы төбәкара хезмәттәшлек форумының беренче нәтиҗәләре генә. Форум быелның 4 октябрендә Татарстан башкаласында узды. Утырышларда һәм башка чараларда нәрсәләр булганы турында хәбәрчебезнең күзәтүләрен тәкъдим итәбез.

Потенциаль партнерлар арасында контракт һәм килешүләргә кул куела торган сөйләшүләр, мөгаен, форумның иң «тәмле» һәм кызыклы өлешедер. Әмма, кызганычка, иң ябык өлеше дә: чит кешеләрне монда кертмиләр. «Казан Экспо»да оештырылган күргәзмә – нәрсәне булса да күреп калуның сирәк мөмкинлеге. 70 ләп компания биредә үзбәк ягы өчен кызыклы булырга тиеш дип санаган иң яхшы продукцияләрен тәкъдим итә. Ә алга таба инде – вазгыятькә карап.

КОНТРАКТ – ЗАГС ТҮГЕЛ

«ТатТелеМед» фирмасы (Чистай) стенды. Түрдә – «КАМА-Ф-ИМИ» мобиль телемедицина флюорография комплексы. Үзбәкстан премьер-министры урынбасары Җәмшид Ходжаев машинаны карарга вакыт таба. Хәтта өскә күтәрелеп, эчендә нәрсәнең ничек эшләнүен дә бәяләргә тырыша. Аннары коллегалары белән үзбәкчә фикер алышып өлгерә. Ходжаев, сүз уңаеннан, хөкүмәттә инвестицияләр һәм тышкы икътисадый элемтәләр өчен җаваплы зат, шуңа күрә аның кызыксынуы юктан гына түгел дип уйларга кирәк.

– Контрактка кадәр, әгәр ул төзелә калса да, әлбәттә, шактый ерак әле, – дип минем оптимизмны уртаклашмый «ТатТелеМед» ҖЧҖ идарәсе рәисе Виктор Классен. – Кайбер бизнеслардагы кебек булырга мөмкин дип уйламагыз: таныштык та – шунда ук ЗАГСка. Монда «очрашып йөрүләр» чоры шактый озын булырга мөмкин.

Әйе, базарда бер без генә түгел. Кызыксынучы яклар туган телдә аралашканда яңгыраган чит ил көндәшләренең атамалары тәрҗемәсез дә аңлашыла. Уйласыннар, киңәшләшсеннәр.

Автор фотолары

– Без конкуренциядән курыкмыйбыз, – дип аңлата миңа Виктор Классен, делегация читкәрәк киткәч. – Ясалма медицина интеллектын куллану буенча безнең нәтиҗәләргә бары тик Көньяк Корея гына якын. Без моны яхшы беләбез. Европа Берлегендә дә, АКШта да, Канадада да мондый нәтиҗәләр юк.

Ә Алабуга автомобиль заводы өчен «очрашып йөрүләр» чоры артта калган кебек. «Форум алдыннан гына диярлек үзбәк коллегаларыбыз белән ыргагы 100 тонналы чыдатырга сәләтле алты күтәрү агрегаты җитештерү буенча контракт төзелде», – диде предприятиенең экспорт бүлеге башлыгы Айназ Гарипов. Техника заказчыга быел ук озатылырга тиеш.

Ләкин имзаланган килешүдән тыш та хезмәттәшлек өчен перспективалар шактый. Беренчедән, күтәрү агрегатлары АлАЗның Көнчыгыш партнеры игътибарына лаеклы бердәнбер продукциясе түгел. Икенчедән, ике якның да кызыксынуы булган очракта экспорт күләмен һәрвакытта да арттырырга мөмкин. Ниһаять, башка хезмәттәшлек вариантлары гадәти «сатып алучы – сатучы» форматына сыймаска мөмкин.

КАБЕЛЬ ТАШКЕНТКА ИЛТӘ

Бу хакта продукциясе Үзбәкстанда яхшы билгеле булган «Таткабель» ҖЧҖ стенды янында да сөйләштек.

– Без Үзбәкстанга кабель продукциясен зур күләмдә озатабыз. Быел 200 километрдан артыкка заказ алган идек, аның зур өлеше кулланучыга җибәрелде инде, – диде заводның сату эшләре буенча директоры Михаил Камашев. – Хәзер үзбәк коллегаларыбыз белән продукцияне Урта Азия базарында алга таба этәрү өчен безнең базада уртак предприятие төзү мөмкинлеген карыйбыз. Потенциал зур.

Мөмкинлекләрнең күплеге гади күзгә дә күренә. Хәтта югары – 110 киловольтлы кабель чорналган фатир түшәме биеклегендәге гаять зур барабан да күргәзмә үрнәгә түгел икән. Аны Үзбәкстанга җибәрәчәкләр: ул – Ташкент шәһәренең электр челтәрен реконструкцияләүне тәгәлләргә тиешле кабельнең соңгы «кисәкчәсе».

Яшел Үзәннең «Ранлайн» предприятиесе стенды башкалар белән чагыштырганда шактый тыйнак. Әмма телевидение аппара-

– Без Үзбәкстанга кабель продукциясен зур күләмдә озатабыз. Быел 200 километрдан артыкка заказ алган идек, аның зур өлеше кулланучыга җибәрелде инде, – диде заводның сату эшләре буенча директоры Михаил Камашев.

турасы җитештерү буенча эре предприятие җитәкчесе Шөһрәт Моратов, профессионал буларак, мөгаен, бирердә потенциал күреп алгандыр. Һәм бу, һичшиксез, очраклы түгел: Яшел Үзәндәге предприятие импортны алмаштыру кысаларында үз чипларын булдыру юлы аша төеннәр һәм платалар буенча да, элемент базасы дәрәҗәсендә дә уңышлы эшләп, төрле электроника уйлап таба һәм җитештерә.

Әйе, «Казан Экспо» күргәзмәсендә тәкъдим ителгәннәрнең күбесе әлегә ихтимал булган контрактларга таба беренче адымнар гынадыр. Әмма ике якка да файдалы хезмәттәшлек перспективалары шактый ачык шәйләнә. Якларны чимал ресурслары гына кызыксындырган чаклар үткәндә калды. Моңа, турыдан-туры булмаса да, түбәндәге факт дәлил булып тора: Казандагы форумга Үзбәкстанның барлык 14 өлкәсенең хәкиме килде – илдә мамык сезонының кызган чагы булуга карамастан...

Трендта – югары технологияле өлкәләрдә хезмәттәшлек, үзара инвестицияләр, уртак белем бирү проектлары. Сүз уңаеннан, пленар утырышта сүз барган гамәлдәге контрактлар да шуны күрсәтә.

ҮЗАРА ХЕЗМӘТТӘШЛЕК ТЕЛЕНДӘ

Сер түгел, Үзбәкстан белән Татарстан арасында мөнәсәбәтләр икътисадый хезмәттәшлек кысаларына гына сыешып бетми. Пленар утырышта Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов та искә төшереп үтте: безнең халыкларның мәдәни, дини һәм тел тамырлары уртак, бу бер-беребезне яхшырак аңларга ярдәм итә. Узган ел йомгаклары буенча Татарстан–Үзбәкстан товар әйләнешенең 50 процентка артып, 290 миллион АКШ долларыннан артып китүе дә үзара аңлашуның ныгый баруын дәлилләли. Агымдагы елның беренче яртыеллыгында үзара сәүдә күләме тагын өчтән бер өлешкә артты.

– Алга таба да үзара товар әйләнеше күләмен һәм номенклатурасын арттыру, инвестицион проектларны гамәлгә ашыру юнәлешендә эшләячәкбез, – диде Рөстәм Миңнеханов. – Моның өчен кирәкле барлык шартлар да бар: хезмәттәшлек турында килешү; 1992 елдан Үзбәкстанда вәкиллегебез эшли, Казанда республиканың Генераль консуллыгы уңышлы эшчәнлек алып бара; Казан белән Ташкент, Сәмәрканд һәм Фирганә арасында турыдан-туры авиарейслар ачылды.

Хезмәттәшлек ысулларының кайсылары трендта булуы турындагы фаразларым пленар утырышта саллы раслану тапты. Бүген Үзбәкстанда, аерым алганда, КАМАЗ, «Химград», «Алабуга», Казан федераль университеты эшли. Мәсәлән, Ташкентта – КАМАЗ автоүзәге, Сәмәркандта җыю линиясе ачылган. Соңгы ике елда «Химград» технополисы ярдәме белән Ташкент һәм Җизәк өлкәләрендә технопарклар эшли башлаган. Бохара һәм Навои өлкәләрендә сәнәгать мәйданчыклары булдыру буенча эш алып барыла. Мәгариф өлкәсендәге хезмәттәшлек тәэсирләндерә: Җизәктә КФУ филиалы эшли һәм Симуляция медицинасы үзәге ачылган. Өстәвенә, Казан югары уку йортларында өч меңгә якын үзбәк студенты югары белем ала.

ТӨБӘКЛӘРГӘ ИГЪТИБАР

Ташкент өлкәсе хәкиме Зойир Мирзаевны форумда Россия субъектлары башлыклары аерым игътибар белән тыңлады. Ул атап үткән саннар нәкъ менә төбәкара хезмәттәшлекнең никадәр зур потенциалга ия икәнлеген күрсәтте.

Төбәкара форум: вертолёт кабинасыннан күренеш.

АлАЗның экспорт бүлеге башлыгы Айназ Гарипов.

– Узган ел безнең Россия субъектлары белән үзара сәүдә-икътисадый хезмәттәшлек 62 процентка артты, бу 210 миллион долларны тәшкил итә, – дип хәбәр итте Зойир Мирзаев. – Ә быелның 9 аенда Россия Федерациясеннән экспорт һәм күрсәтелгән хезмәтләр күләме 190 миллион долларны тәшкил итте, бу 2021 елның шул ук чорына карата 149 процент!

Сүз уңаеннан, Татарстан белән Ташкент өлкәсе арасында 2018 елда имзаланган Хезмәттәшлек турында килешү нигезендә җайланган аерым мөнәсәбәтләр бар. Бу үз нәтиҗәләрен бирә. Мәсәлән, Татарстан тәҗрибәсен исәпкә алып, узган ел Чирчикта чит ил һәм җирле компанияләр җитештерүләрен локальләштерү максатында индустриаль парк эшли башлады. «Чирчик» технопаркында барлык кирәкле инженерлык инфраструктурасы эшләнгән, анда теләсә кайсы җир кишәрлегеннән һәм бинадан энергия белән тәэмин итү челтәренә тоташу ноктасы кул сузымында гына. 30 дан артык чит ил компаниясе резидент булып теркәлгән инде.

Икенче мисал: «Татнефть» ягулык салу станцияләре челтәрен төзү проектын тормышка ашырды, шулай ук Үзәк Азиядә автомобиль шиннары җитештерү буенча бердәнбер заводның хуҗасы булды.

Татарстан компанияләре Ташкентның иң эре биш предприятиесе инвесторлары булып тора. Шул ук вакытта үзбәк компанияләре Татарстан территориясендәге проектларга инвестицияләр кертә. Әйтик, форум кысаларында Казанда җиләк-җимеш, яшелчә, эчетелгән сөт продуктлары һәм башка авыл хуҗалыгы товарларын саклауга, эшкәртүгә һәм сатуга махсуслашачак күмәртәләп бүлү үзәген ачу турында килешү имзаланды. Аның төп күләмен Үзбәкстаннан кертү планлаштырыла. Проектның бәясе – 80 миллион АКШ долларыннан артыграк.

Кызыксынырлык нәрсәләр шактый. Үзбәкстан Республикасының энергетика министры Журабәк Мирзамәхмүдов (уңда).

– Татарстан күп нәрсә тәкъдим итә ала. Гомумән, төбәкара хезмәттәшлек үсеше бик яхшы темплар белән бара, безнең төбәкләрнең күбесе Үзбәкстан белән турыдан-туры элемтәләргә ия, – диде РФ Президенты Владимир Путин үзенең коллегасы Шәүкәт Мирзиеёв белән очрашуда. Исегезгә төшерәбез: очрашу Үзбәкстан Президенты Татарстан башкаласындагы форумда булганнан соң ук узды.

Чыннан да, бүген Россия бу Урта Азия республикасы базарында чит илләр арасында беренче урында тора. Россия бизнесы Үзбәкстанда европалыларны һәм хәтта Кытайны да кысрыклады, ул анда күптәннән һәм ныклы рәвештә төп инвестор позицияләрен биләп тора. Илебез икътисадын какшату өчен уйлап чыгарылган Көнбатыш санкцияләре нәтиҗәдә Россия бизнесына яңа базарларга юнәлергә һәм анда үзләрен ышанычлы хис итәргә булыша.

Вертолёт белән танышу.

МИЛЛИ

2023 ЕЛДА РОССИЯ ТӨБӘКЛӘРЕНДӘ ИНВЕСТИЦИЯЛЕ КЛИМАТНЫҢ ТОРЫШЫ*

1
Мәскәү

2
Татарстан

3
Мәскәү өлкәсе
Түбән Новгород өлкәсе
Төмән өлкәсе

4
Башкортостан
Тула өлкәсе
Сахалин өлкәсе

5
Новгород өлкәсе
Краснодар крае

6
Санкт-Петербург
Чечен Республикасы

7
Калуга
өлкәсе

ИНТЕГРАЛЬ ИНДЕКС ҮСЕШЕНЕҢ ИҢ ЗУР ДИНАМИКАСЫН КҮРСӘТКӘН ЛИДЕР ТӨБӘКЛӘР:

Забайкалье крае, Чечен Республикасы, Мәскәү, Түбән Новгород өлкәсе, Төмән өлкәсе һәм **Татарстан**

* *Ел саен айдап баручы эшлекле берләшмәләр белән бергә Стратегик инициативалар агентлыгы тарафыннан формалаша.*

РЕЙТИНГ

Төбәкләрдә инвестицияле климат торышының милли рейтингы бизнес алып бару өчен уңайлы шартлар тудыру юнәлешендә РФ субъектлары хакимиятенең нинди тырышлык куюын бәяли һәм иң уңышлы тәҗрибәләрне ачыклый, ә **рейтинг нәтиҗәләре төбәк дәрәҗәсендә инвестицияләр өчен ярышта көндәшлекне арттыра.**

МИЛЛИ РЕЙТИНГНЫҢ НӘТИҖӘЛӘРЕ ДҮРТ ЮНӘЛЕШ БУЕНЧА ФОРМАЛАША:
«ҖАЙЛАУ МОХИТЕ», «БИЗНЕС ӨЧЕН ИНСТИТУТЛАР», «ИНФРАСТРУКТУРА ҺӘМ РЕСУРСЛАР», «КЕЧЕ ҺӘМ УРТА ЭШКУАРЛЫККА ЯРДӘМ».

МИЛЛИ РЕЙТИНГ ЮНӘЛЕШЛӘРЕ БУЕНЧА ЛИДЕРЛАР:

«Җайлау мохите»

- Мәскәү өлкәсе
- Сахалин өлкәсе
- Тула өлкәсе
- Мәскәү
- Якутия

«Бизнес өчен институтлар»

- Смоленск өлкәсе
- Новгород өлкәсе
- Краснодар крае
- Кырым
- Калуга өлкәсе

«Инфраструктура һәм ресурслар»

- Мәскәү
- Төмән өлкәсе
- **Татарстан**
- Ростов өлкәсе
- Самара өлкәсе

«КУЭка ярдәм»

- Мәскәү
- **Татарстан**
- Санкт-Петербург
- Мәскәү өлкәсе
- Новосибирск өлкәсе

Фотолар Аида Демьяновадан алынды. РЕКЛАМА. 16+

КЫТАЙ БЕЛӘН БИЗНЕСНЫ НИЧЕК ДӨРЕС ОЕШТЫРЫРГА?

Николай Крушинин

Бу сорауга җавапны «ВАНМЕЙ ГРУПП» консалтинг агентлыгына нигез салучы, Казандагы өч кытай ашлары рестораны хуҗасы, Кытай белән бизнесны оештыру буенча эксперт Аида Демьянова белә. Бүген ул – «Татарстан» журналының кунагы һәм безнең укучыларыбызны кытай бизнес-менталитетының бөтен нечкәлекләренә төшендерергә әзер.

БЕР КҮРҮГӘ ГАШЫЙК БУЛУ

– Аида, син нишләп Кытайны шулай яратасың? Һәм нигә нәкъ менә Кытайны?

– Кытайга мин бер күрүгә үк гашыйк булдым: университетта укыганда беренче тапкыр баруымда ук бу илне үз иттем. Миңа анда бөтен нәрсә ошады: кешеләре, теле, ризыклары, һәркайда һәм һәр җирдәге җете төсләре, тормыш темпы, алга киткән икътисады... Һәм эле ул шопоголиклар өчен чын оҗмах та, кызлар өчен бигрәк тә мавыктыргыч ягы. Хәзерге чынбарлыкта бусы тагын да мөһимрәк.

КФУның Көнчыгыш телләре институтында кытай телен өйрәнгәндем, белемем тормышымда да, эшемдә дә бик кирәк булып чыкты. Университетны тәмамлагач, мин алда ике юл бар иде: укытучы булу яки эксперт буларак мөстәкыйль үсү. Мин икенче вариантны сайладым һәм моңа бер тапкыр да үкенмәдем, чөнки эшемдә бик зур тәҗрибә тупладым: нәтиҗәдә ул минем бизнесым өчен нигезгә әйләнде.

Хәзер минем берничә бизнесым, үземнең «ВАНМЕЙ ГРУПП» консалтинг агентлыгым бар – анда без Кытайдан йөк ташу, килешүләрне башыннан азагына кадәр башкарып чыгу, товар сатучыларны эзләү һәм тикшерү белән шөгыльләнәбез, Кытайда үз җитештерүеңне ачу һәм үз брендың белән товарлар чыгаруны җайларга булышабыз. Бөтен Россия буенча кече һәм урта бизнес нигездә безнең белән эшли.

Шулай ук күптән түгел генә без ирем белән (ул кытай, Юй исемле) Казан үзәгендә ике яңа кытай ашлары рестораны ачтык. Аларның берсе «Китайский дворик» дип атала һәм Шаньдунь, Төньяк-Көнчыгыш һәм Сычуань төбәкләре ризыкларын тәкъдим итә. Юл аша гына урнашкан икенчесендә исә чын кытай токмачы һәм кулдан бөгелгән пилмән белән сыйланырга була.

Безнең «Китайская утка» дип аталган беренче кафебыз вакытлыча ябык: интерьерны яңартабыз, аның тагын да яхшырак булуын телибез.

Мин әле тәрҗемә эшчәнлеген дә дәвам итәм, чөнки бу эшемне бик яратам.

ИҢ ЗУР ИХТЫЯҖ

– Сезнең эшчәнлек бик төрле, шулай да һәркайсы Кытай белән бәйле. Кытайда үз эшен башларга җыенучы эшкуарларның иң еш мөрәҗәгать иткән сораулары нинди булуын әйтегез әле...

– Мөгаен, иң еш очрый торган сорау – Кытайда билгеле бер товарны табу, табу гына да түгел, аны сатучының ышанычлы булуын тикшерүдер. Ул кирәк кадәр товарны җитештерә алачакмы, вакытында өлгертәчәкме, үз йөкләмәләрен үтәячәкме...

Аннары Кытайдан йөк кайтару һәм аны таможняда рәсмиләштерүгә бәйле ихтыяҗлар торадыр. Без боларның барысын да башыннан алып азагына кадәр үзебез башкарып чыгабыз. Шулай ук клиентның Кытайда үз бренды белән товар җитештерүенә кагылышлы сораулар да күп, чөнки бу, бик күп детальләрдән торганга һәм кытайларның менталитетын белүне таләп иткәнгә, бик катлаулы бурыч.

Мәсәлән, без бик еш клиентларның товар эзләү өчен техник биремне дөрес тутырмавын күрәбез. Һәм бу очракта клиент бик күп вакытын югалтырга мөмкин. Без исә мондый хәл килеп чыкмасын өчен тырышабыз, барлык детальләрне алдан ук тикшерәбез. Биремне җитештерү белән килештерәбез, клиент нәкъ менә үзе теләгән товарны алырлык итеп кирәкле төзәтмәләрне кертәбез. Шуннан соң гына эшкә керешәбез...

КИЛЕШТЕРҮДӘН СОҢ – ТИКШЕРЕП ТОРУ

– Бизнес турында килешкәннән соң, сезнең вазыйфагыз нидән гыйбарәт?

– Клиенттан техник бирем алганнан соң, ул сораган сыйфат, вакыт, бәя һәм түләү шартларына туры килгән товар сатучыны табабыз һәм клиент белән Кытайдагы сатучы арасында турыдан-туры килешү төзибез. Товар өчен акча түләнгәч, җитештерү процессын контрольдә тотабыз, шулай ук, кирәк булганда, сыйфатны тикшерү өчен җитештерүгә баруны да оештырабыз. Аннары товарны кайтаруны һәм таможня аша үткәрүне көйлибез.

Сүз дә юк, клиент югарыда саналганнарның барысын да мөстәкыйль башкарып карый ала, әмма, кагыйдә



буларак, кытай партнерлар белән хезмәттәшлек итү процессында әллә никадәр проблема килеп чыга. Бу үзенең бизнес-менталитеты булган бөтенләй башка ил икәнне онытырга ярамый, аларда бизнес алып бару безнекеннән шактый аерыла. Һәм нәтиҗәдә клиентлар килешүнең төрле этапларында безгә мөрәҗәгать итәргә мәҗбүр була – үзләре генә хәл итә алмый торган проблемалар килеп чыга. Тагын шунысын да барыбыз да бик яхшы аңлый: вакыт – акча ул, товар кайдадыр тукталып кала икән, димәк, акча да югала, дигән сүз.

КЫТАЙЛАРНЫ ҮПКӘЛӘТМӘСКӘ ТЫРЫШЫРГА КИРӘК

– Кытайларның бизнес-менталитеты безнекеннән нәрсә белән аерыла? Кытай вәкилләре белән килешүләр төзегәндә нәрсәгә игътибар итәргә кирәк?

– Кытайлар белән эшләгәндә бөтен нәрсә мөһим: мәсәлән, үз компаниягезнең презентациясен ничек үткәрәсез, сөйләшүләрне ничек алып барасыз, килешүләрне ничек үтисез, нинди бүләкләр бирәсез һәм уртак табында нинди темаларны тикшерәсез.

Кытайлар товарны төяп җибәрүне кичектерергә ярата, шунлыктан вакытны һәр этапта контрольдә тоту зарур.

Яки, мәсәлән, җитештерүдә ниндидер проблема пәйда булса, кытайлар аны, клиентка әйтеп тормыйча гына, мөстәкыйль хәл итәргә тырыша.

Кытай мәдәниятендә туклану, ризык темасы аеруча әһәмияткә ия, шунлыктан, әгәр бергә төшке яки кичке аш ашаудан баш тартсагыз, партнерларыгыз үпкәләргә һәм бу килешүгә дә зыян китерергә мөмкин. Чөнки күп кенә мөһим мәсьәләләр нәкъ менә табында хәл ителә дә инде.

КЫТАЙ ДӨНЬЯСЫНА ЮЛАМАН

– Кытайларның тормышын һәм менталитетын, кытай телен бик яхшы белгәнгә, сез Кытай дөньясына юл күрсәтүче, юламан булып торасыз икән ләбаса. Мөгаен, сезне эксперт сыйфатында төрле чараларга еш чакыралардыр?

– Соңгы вакытта Кытай белән кызыксыну арта бара. Сәүдә ягыннан гына түгел, мәдәният, менталитет, бизнес алып бару үзенчәлекләре ягыннан да. Хәзер мин эшкуарларның төрле бизнес-бергәлекләрендә еш чыгыш ясыйм, осталык дәресләре дә үткәрәм.

БУ ЮЛНЫ ҮЗЕМ ҮТТЕМ

– Барыбызга да мәгълүм: бүген бөтен товар диярлек Кытайдан сатып алына һәм маркетплейслар аша кайтартыла. Сезнең практикада бу ничек башкарыла?

– Чыннан да, маркетплейслар өчен товарларга заказлар көн саен килә. Биредә спецификаны аңлау кирәк – бу зур контейнерларда китерелә торган йөк түгел, ә карго-компанияләр җибәрә торган җыелма йөкләр. Без әлеге хезмәтне дә күрсәтәбез, һәм минем әлеге юлны да башыннан азагына кадәр үтәсем килгән иде. Чөнки бу турыда ишетү – бер хәл, ә инде үз юнәлешен сайлап алган, үз сатучысын тапкан, үз товарын маркетплейста урнаштырган клиент юлын үтү – бөтенләй башка. Быел мин моны эшләдем һәм «Вайлдберриз»да үз кибетемне ачтым: бу турыда тәфсилләбрәк үземнең aida_pro_china телеграм-каналымда сөйлим.

САЙТТА ОЧРАШЫРБЫЗ! ЙӘ РЕСТОРАНДА

– Хезмәттәшлек итү өчен, сезне ничек табарга була?

– Безнең компаниянең сайты бар. Товар сатучы табасыгыз яки Кытайдан йөк кайтартасыгыз килә икән – анда гариза калдырырга була, менеджерлар сезнең белән элемтәгә керәчәк. Шәхсән минем үзем белән эшләргә теләсәгез, шәхси сайтыма языгыз – барысын да күрәм һәм тиз арада җавап бирәм. Һәм инде, әлбәттә, сезне Казандагы ресторанннарыбызда күрергә һәрвакыт бик шатбыз – чын кытай ризыкларыннан авыз итәргә килегез. Иманым камил: сезгә ошаячак!

Фото: Алсу Шакирова

ПАРТНЁР ФИНАНСЛАРЫ ИМИНЛЕГЕ

Әскәр Сабиров

Россиядә ислам банкингы экзотика булудан туктый. Берьюлы дүрт республикада – Башкортостанда, Дагыстанда, Татарстанда һәм Чечняда партнёрлык финанславы буенча экспериментны башлап җибәргән закон күптән кабул ителгән иде, һәм ул, уен кагыйдәләрен билгеләп, эшне башлап җибәрде. Базарда шәригать нормалары һәм ислам этикасы нигезендә төзелгән нинди финанс продуктлары тәкъдим ителә соң? Алар без – гади гражданнар өчен никадәр кызыклы булырга мөмкин? Бу сорауларга «Татарстан» журналындагы түгәрәк өстәлдә катнашучылар җавап бирә.

ТҮГӘРӘК ӨСТӘЛДӘ КАТНАШУЧЫЛАР

Айдар Шаһимәрдәнов, РФ Мөселман эшкуарлары ассоциациясе президенты

Рөстәм Сәгъдиев, «Амаль» Финанслар Йорты директоры

Руслан Хәлиуллин, Россия ислам институты каршындагы Россия ислам икътисады һәм финанслары үзәге эксперты

Рөстәм Шәфигуллин, «Жилищные традиции» ТТК директоры

Рамил Батыршин, «Жилищные традиции» ТТК координаторы

Лилия Муллахмәтова, «Аль-Варис» медицина косметологиясе һәм трихологиясе клиникасы директоры

Рәшит Хәйретдинов, «Татарстан» журналының башкарма директоры

Әскәр Сабиров, «Татарстан» журналы шеф-редакторы

ИСЛАМ БАНКИНГЫ – РУБИК КУБИГЫ ТҮГЕЛ

Айдар Шаһимәрдәнов, РФ Мөселман эшкуарлары ассоциациясе президенты:

– Гади сораудан башлыйк. Бүгенге көндә ислам финансларына ихтыяҗ бармы?

– Безнең ассоциация – Россия мөселман эшкуарларын берләштерә торган мәйданчык. Шуны әйтә алам: безнең җәмгыять вәкилләре өчен ислам финанслары турындагы законның пәйда булуы озак еллар көткән вакыйгага тиң. Эшкуарлар арасында ислам финансларына ихтыяҗ баштан ук бар иде, өстәвенә, икътисад кагыйдәсе дә эшләп китәргә тиеш: тәкъдим сорау тудыра.

– Бу бүгенге көндә ислам финанс инструментларына ихтыяҗ артык зур булмавын аңлатамы?

– Болай диик: ихтыяҗ зур, ләкин ул әле зур теләк булып формалашмаган. Мисалда аңлатыйм. Әйтик, һәркем Рубик кубын алырга тели, ди. Әгәр дә Бауман урамына Рубик кубиклары тутырылган машина килеп туктаса, кубикларны шунда ук алып бетерәчәкләр. Әгәр дә ниндидер компания ислам финанс продуктын тәкъдим итә башлый икән, мөселманнар аны шунда ук Рубик кубигы кебек сатып алырга ашыкмаячак. Алар тәкъдимне шикләнеп кенә кабул итәрләр. Башта карарлар, өйрәнерләр, дөреслеген тикшерергә тырышырлар. Гаҗәп түгел – монда үз үзенчәлеге бар. Әлеге продуктны кем хәләл дип әйткән? Кем бәяләгән? Кем аудит үткәргән? Ниһаять, кем үз имзасын куйган? Потенциаль кулланучының барлык сорауларына ислам продуктын тәкъдим итүче ышандырырлык итеп җавап бирергә тиеш булачак.

> ПОТЕНЦИАЛЬ КУЛЛАНУЧЫНЫҢ БАРЛЫК СОРАУЛАРЫНА ИСЛАМ ПРОДУКТЫН ТӘКЪДИМ ИТҮЧЕ ЫШАНДЫРЫРЛЫК ИТЕП ҖАВАП БИРЕРГӘ ТИЕШ БУЛАЧАК.

– Бизнеста партнёрның дөреслегенә ышаныр өчен, еш кына бренд исемен белү дә җитә...

– Безнең күптәнге партнёрыбыз бар, ул күп еллар дәвамында ислам кануннары буенча бизнесны финанслау белән шөгыльләнә. Бу чыннан да күптән танылган бренд, компания продуктларына карата шик юк. Ләкин икенче як – потенциаль клиентның әзерлек дәрәҗәсен дә исәпкә алырга кирәк. Еш кына мөселман эшкуарлар үзләре дә бизнесларына нинди капитал кертергә әзер булуларын аңлап бетерми. Еш кына: «Кая инде безгә «Амаль»га барырга, анда шундый шартлар... Миңа N банкына барып, 9 проценттан кредит алу яхшырак...», – дигән сүзләрне ишетергә туры килә. Ләкин процентка акча алу – хәрәм. Пәйгамбәребез Мөхәммәд (с.г.в.) рибачылыкны гөнаһ дигән, ягъни кредит бирү яки алу зур гөнаһ санала. Ләкин кешеләр, берни уйламыйча, кредит алырга бара...

– Эшкуарларга арзан акча әхлакый принциплардан мөһимрәкме?

– Зур арзан акчалар – бизнес өчен беренчел ихтыяҗ. Бу минем фикер түгел, Мөселман эшкуарлары ассоциациясе президенты буларак: «Безгә арзан акча кирәк», – дигән сүзләрне шактый күп ишетәм. Әгәр гадәти банклар акчаны 10 процентка бирә икән, «Амаль» күпкә артыграк итеп бирмәсен. Бер-ике процент аерманы клиент кабул итәргә әзер, кубрәк икән, гафу итегез, – юк! Әмма «Амаль» кредит акчасы бирми бит! Бу принципиаль аерма. Һәм проблема шунда ки, барлык эшкуарлар да партнёрлык финансларының үзенчәлеген һәм файдасын аңламый.

Лилия Муллахмәтова, «Аль-Варис» медицина косметологиясе һәм трихологиясе клиникасы директоры:

– Шәхсән мин партнёрлык финанслары пәйда булуга бик шат. Минем клиника кредитка мохтаҗ түгел, безнең хезмәтләрнең сыйфаты гарантияле керем бирә. Ләкин үсеш өчен акча кирәк булса, мин партнёр буларак ярдәм итә торган финанс структурасына гына мөрәҗәгать итәр идем. Кредитор-рибачының хәрәм акчасын беркайчан да алмаячакмын. Әгәр дә мин инвестор буларак эш итәм икән, үз акчамның кая салыначагына да битараф түгелмен. Нинди генә шартлар тәкъдим ителсә дә, хәрәм саналган тармакларга инвестицияләр кертмәячәкмен, чөнки бу бик зур гөнаһ. Минем клиника «Аль-Варис» дип атала. Бу Аллаһның 99 исеменең берсе.

– Аңлап эш итүче эшкуарлар күбрәк булсын өчен нишләргә?

Айдар Шаһимәрдәнов:

– Карагыз, бездә танылган банк тантаналы рәвештә ислам финанслау үзәген ачты. Мин аларга болай дим: «Егетләр, бу урын чын мәгънәсендә җанлансын һәм эшләп китсен өчен, аны ислам эшкуарларын җәлеп итү үзәге итәргә кирәк. Монда мөфтине, мөселман галимнәрен чакырыгыз, алар ике атнага бер яисә атнага бер тапкыр дәресләр үткәрсен, лекцияләр укысын, ислам банкингының, партнёрлык финансларының төп принципларын аңлатсын. Тагын әле бу урынны кешеләр яратырлык итәргә дә кирәк. Ислам нормалары буенча бизнесны күптәннән һәм уңышлы финанслаучы оешмада барысы да тиешенчә куелган: лекторий эшли, көн саен очрашулар оештырыла, клиентларны матурлап кабул итәләр. Кешеләргә партнёрлык финанслары кирәк булганда, алар нәкъ менә бу финанс йортын сайлар. Ни өчен башкаларның үз клиентларына шундый ук игътибар күрсәтмәүләрен мин аңлый алмыйм. Сүз уңаеннан, мин әлеге банк җитәкчелеге белән күп тапкырлар сөйләштем, ләкин, кызганычка, бернәрсә дә үзгәрми.

Нинди нәтиҗәләр ясарга мөмкин? Әйе, эшкуарларга ислам акчалары бик кирәк, алар ислам банкларында исәп-хисап счетларын ачачак. Һәм, әлбәттә, шәригать кануннары нигезендә партнёрлык финанслары кирәк, ислам инвестицияләре дә сорала. Әгәр дә вакыт узу белән миллиардлар, дистәләрчә миллиардлар салына икән, базар аны йотар, дип уйлыйм. Ләкин ислам банкингы, кабатлап әйтәм, бу һәркем алырга теләгән һәм һәркем яраткан Рубик кубигы түгел. Теләсә кайсы шәп идея, кеше акылын биләп алсын өчен, популярлаштыруны таләп итә. Без үзебезнең ассоциациядә бу эш белән күп еллар дәвамында шөгыльләнәбез. Үз чыгышларыбызда, әңгәмәләр вакытында, аралашканда мөселман эшкуарларын хәрәм кредитлардан баш тартырга, хәләл акча гына алырга чакырабыз. Әгәр ислам банкингы нормага әйләнсә, минемчә, ул мөселманнар өчен генә түгел, гомумән ил өчен бик зур файда китерер. Кешеләр ислам икътисады һәм банкингының тәмен сизеп алгач, аларның тарафдарлары арасында төрле конфессия вәкилләре булыр, дип уйлыйм. Чөнки партнёрлык финанслары нигезендә гаделлек ята, ә һәр кеше гаделлекнең өстенлек итүен тели.

БИЗНЕС ДВИГАТЕЛЕ БУЛАРАК ГАДЕЛЛЕК ПРИНЦИБЫ

Рөстәм Сәгъдиев, «Амаль» Финанслар Йорты директоры:

– Ислам финанс продуктлары кайчаннан бирле халык һәм бизнес өчен эшли?

– Без ислам финанс продуктларын 2010 елдан бирле бирәбез. Чынлыкта, бу юнәлештәге бушлык үз вакытында безнең компанияне оештыруга сәбәп булды, гәрчә мондый структураны төзү омтылышы безгә кадәр дә булган булса да. Мәсәлән, 2008 елга кадәр Мәскәүдә мондый хезмәтләр күрсәтүче банк эшләгән, кызганычка, ул кайбер сәбәпләр аркасында ябылган. Шул ук вакытта ислам финанс продуктларына халык тарафыннан билгеле бер ихтыяҗ һәрвакыт булган. Башта без Татарстан территориясендә генә эшләдек, бүген инвестицияләр ягыннан – клиентлар бөтен илдән, ә финанслау ягыннан – Төньяк Кавказ һәм Ерак Көнчыгыштан кала, бөтен ил. Казанда һәм Мәскәүдә офислар эшли.

Без үзебездә ислам банкингының кайбер принципларын тормышка ашырырга тырыштык. Димәк, бер яктан, без, теләсә кайсы банк кебек, инвестицияләр җәлеп итәбез, икенче яктан – финанслыйбыз. Нигездә кече һәм урта бизнесны финанслыйбыз.

– Сезнең уртача клиентыгыз – кем ул?

– Ул – автомобильләр, махсус техника, җиһазлар, торак яки коммерцияле күчемсез милек, кыскасы, күреп, үлчәп, санап чыгарып була торган теләсә кайсы матди активны сатып алу өчен акча (гадәттә 40–60 миллион сумлап) кирәк булган эшкуар. Статистикага караганда, безгә инвестицияләр кертүче клиентлар исә, кагыйдә буларак, физик затлар. Алар – акчаларын сакларга, арттырырга, төрле өлкәләргә инвестицияләр кертергә омтылучы кешеләр. Һәм без алар өчен үз продукция линейкасын эшләдек. Бездә инвестицияләргә һәм ай саен яисә туплап билгеләнгән срок ахырында керем алырга мөмкинлек бирә торган продуктлар эшләнгән. Хәйриячелеккә юнәлтелгән максатчан продуктлар да бар. Мәсәлән, «Яхшылык кайта» кебек. Бу очракта инвестор алган табышның бер өлеше автомат рәвештә хәйриячелеккә китә. Аерым алганда, Казанда инде берничә ел «Ярдәм» фонды белән эшлибез. Табышның бер өлеше бу хәйрия оешмасына күчә. Хаҗга яки өмрәгә барырга теләүчеләргә исәпләнгән тариф бар – бу очракта табышның бер өлеше тупланып бара. Хәтта балаларга юнәлдерелгән тариф та бар, ул «Яшь инвестор» дип атала. Кешеләр балаларны финанс грамоталылыгына, инвестицияләргә өйрәтергә кирәклеген аңлый һәм бу счетны рәхәтләнеп ача, чөнки керү өчен чагыштырмача кечкенә сумма таләп ителә – биш мең сум.

Продукция линиясе киң, әмма Айдар Равильевич белән килешәм, ислам финансларына ихтыяҗ бик зур. Бездә барысын да финанслау өчен элементар ликвидлык, акча җитми. Кайвакыт клиентларыбызны көтәргә сорарга туры килә. Бу елларда безнең портфель күп тапкырларга артты, ләкин ихтыяҗ тагын да тизрәк үсә.

– Ә алдагы спикер әйткәнчә, клиентлар белән махсус эш кирәклеге чыннан да шулкадәр мөһимме?

– Бүген монда җыелган кешеләр, үзләре дә мөселманнар, идеяле кешеләр. Безнең компания дә шундый кешеләр ярдәмендә төзелгән. Шуңа күрә без клиентларга хезмәт күрсәтүгә дә җитди карыйбыз. Безнең эшнең нигезендә ислам финанслары китергән бәрәкәтне аңлау, гаделлек принцибы ята. Хәләл базарга якынаерга тырышкан яки анда керергә теләгән банкларның карашы бераз башкачарак, коммерциялерәк, дип уйлыйм. Шуңа күрә теге яки бу клиент белән ничек аралашырга кирәклеген аңлауда да аерма бар.

– Аңлаудагы бу аерма ислам продуктлары базарын үстерүгә тоткарлык ясамасмы?

– Минемчә, бу базар үсәчәк кенә. Ниһаять, партнёрлык финанслары өлкәсендә экспериментны регламентлаштыручы закон кабул ителде, ул гамәлдә, Үзәк банк реестрында мондый компанияләр саны да арта. Хәзерге вакытта иң беренче бурыч – ислам финансларының гадәти финанслардан өстенлекләре нәрсәдә булуын аңлату. Һәм аерым мөселманнарга рибаның никадәр авыр гөнаһ икәнлеген исләренә төшерү. Кызганычка, аларның барысы да хәзерге вакытта бөтен җирдә кулланылган риба процентларының куркынычын аңлап бетерми.

– Билгеле булганча, 12 ел эчендә бер генә инвесторыгыз да үз акчасын югалтмаган. Моңа ничек ирештегез?

– Консерватив сәясәт мәсьәләсе бу. Без стартапларны финансламыйбыз. Безнең клиентлар – ким дигәндә бер ел тәҗрибәсе булган эшкуарлар. Өстәвенә, без һәрвакыт ликвидлы залог сорыйбыз: автомобильләр, махсус техника, җиһазлар – җиңел генә сатыла торган нәрсәләр. Әлбәттә, күп нәрсә портфельне диверсификацияләүдән тора: йомыркаларны бер кәрзиндә тотмыйбыз.

> ХӘЗЕРГЕ ВАКЫТТА ИҢ БЕРЕНЧЕ БУРЫЧ – ИСЛАМ ФИНАНСЛАРЫНЫҢ ГАДӘТИ ФИНАНСЛАРДАН ӨСТЕНЛЕКЛӘРЕ НӘРСӘДӘ БУЛУЫН АҢЛАТУ.

– Партнёрлык финанслары өлкәсендә сез атап киткән ликвидлыкның җитмәве потенциаль клиентларның ышанмавы нәтиҗәсе түгелме?

– Күпмедер дәрәҗәдә инвесторлар тарафыннан ышанып җитмәү бар, әлбәттә. Бу эшчәнлек өлкәсе лицензияләнми. Эксперимент башлану белән Үзәк банк реестры барлыкка килде, бу, һичшиксез, потенциаль инвесторларның ышаныч дәрәҗәсен арттырачак.

– Сезнең иң зур инвестор – ул күпме инвестиция салды? Якынча санын әйтә аласызмы?

– Дистәләгән миллион сум.

– Ә сез финансларга батырчылык иткән иң зур проектны?

– Бу да дистәләгән миллион сумнар.

ФАТИР МӘСЬӘЛӘСЕ. ИПОТЕКА ТӘКЪДИМ ИТМӘСКӘ!

Рөстәм Шәфигуллин, «Жилищные традиции» ТТК директоры:

– Әгәр дә кеше торак сатып алырга тели һәм аның акчасы җитми икән, бездә гадәттә нәрсә тәкъдим итәләр? Традицион ипотека. Ләкин Коръәндә шундый аять бар: Аллаһы Тәгалә сәүдәне рөхсәт итте һәм рибаны тыйды. Исламда процентка акча бирү һәм алу тыела. Әлеге кагыйдә безне торак базарында тыюларны бозмыйча, шул ук вакытта арадашчыга түләмичә, торак сатып алырга мөмкинлек бирүче продукт булдырырга һәм гамәлгә кертергә этәрде.

Рөхсәт ителгән ысул торак кооперативы базасында уңышлы гамәлгә ашырыла. Безнең продукт нигезендә «мушарака» контракты ята. Мушарака, аңлатып киткәндә, проектны гамәлгә ашыручы яклар арасындагы эшләрдә яки милектә партнёрлык. Торак базарында безнең продуктның башкалардан аермасы шунда: ул үзара ярдәм кассасы принцибы буенча эшли. Ягъни кооператив – пайчылар үз взносларын кертә торган фонд, бу фатир бәясенең 30 яки 50 проценты. Әлеге акчалар берләшә, һәм тупланган акчаларга пайчылар өчен этаплап фатирлар сатып алына. Үзенчәлек шунда ки, клиент арадашчылык өчен артыгын түләми, чөнки финанслау банк катнашыннан башка гына гамәлгә ашырыла.

– Торак сайлау чикләнгәнме?

Рамил Батыршин, «Жилищные традиции» ТТК координаторы

– Әлегә кулланучының торакны билгеле бер торак комплексларында һәм яңа төзелешләрдә генә сатып алу мөмкинлеге бар. Әлеге схема буенча иске торакны сатып алып булмый – өстәмә бәя чыгармыйча, үзара ярдәм кассасының эшен саклап калу мөмкин түгел: без рөхсәт ителгән контрактлар аша шулай ук икътисадка файда китерергә омтылабыз. Шулай да, сез торак базарында банклар кулланган тагын бер ислам продуктын беләсез дип уйлыйм: банк фатирны сатып ала, аннары, сату бәясе өстәп, рассрочка аша ул торакны бирә. Бездә, кабатлап әйтәм, башкача: кешеләр үз активларын берләштерәләр һәм төзелешкә кертәләр: пайчыларның акчалары өстәмә кыйммәт булдыру өчен эшли.

– Ә торакны алар Татарстанда гына сатып ала алалармы?

– Безнең продукт ярдәмендә иң күп фатир Казанда сатыла. Ләкин Екатеринбург, Санкт-Петербург, Тольятти, Уфа да катнаша. Күп төбәкләрдә ихтыяҗ бар, аерым алганда, әлеге продуктка бик зур сорау, мәсәлән, Пермьдә күзәтелә. Әмма Татарстандагы сату күләмен башка төбәкләрдәге белән чагыштырып булмый – бездә күп тапкырларга артыграк сатыла. Эш шунда ки, без девелопер артыннан барабыз, аңардан башка эшләү авыр. Бу – бизнес үзе клиентларына өстәмә түләү варианты бирә торган ислам продуктын сату моделе, сатып алырга теләгән һәр кешегә, диненә бәйсез рәвештә.

– Әйтик, сезнең кооперативның пайчысы фатирның теркәлгән бәясенең 50 процентын керткән, ә калган өлешен берничә ел эчендә салып бетерергә тиеш. Һәм кинәт инфляция... Нишләргә? Контрактны яңадан караргамы?

– Квадрат метрларны сату базар бәясенә карап билгеләнә. Димәк, сез квадрат метр бәясенең 50 процентын түләдегез – бәя теркәлде, ул инде үзгәрмәячәк. Ә калган өлеше, тигезләп, әйтик, җиде ел дәвамында урнашкан бәядән сатып алына. Индексация базардагы бәяләргә карый, ә бәяне бәйсез бәяләү компаниясе билгеләргә ярдәм итә. Квадрат метр бәясе, теория буенча, күтәрелергә генә түгел, кимергә дә мөмкин. Шунысын билгеләп үтәргә кирәк: инфляция очрагында фатирыгызның түләнгән һәм теркәлгән өлеше дә базарда арта бит. Бу арту пайчы файдасына – ул үз акчаларын инфляциядән саклап кала.

– Сатып алучы өчен куркыныч аңлашыла: ихтимал, күбрәк түләргә туры килергә мөмкин. Ә сатучы өчен куркыныч нәрсәдә?

– Кооператив үзара ярдәм кассасы принцибы буенча эш итә: үз взнослары белән керүче пайчылар квадрат метрларның кыйммәтләнү куркынычын да үзара бүлешә. Башкача була алмый: безнең икътисад, кызганычка, әлегә инфляциягә бирешә. Мондый контракт безгә бүгенге шартларда үсәргә мөмкинлек бирә.

Хәзерге заманның танылган мөселман галимнәре безнең контракт төре рөхсәт ителә, ул ислам нормаларына каршы килми, дип раслый. Әле 2018 елда ук без продуктыбызга шәригать бәяләмәсен алдык. Ә безнең принципның гаделлеген һәм кирәклеген ихтыяҗның булуы раслый. 2018 елның апреленнән кооператив аша меңләгән гаилә узды, шулвакыт эчендә сатып алынган активларның гомуми әйләнеше 2 млрд 563 миллион сум тәшкил итте. Өстәвенә, без девелопер компаниясенең гомуми әйләнешенең ике процентыннан башладык, ә хәзер егермегә җиттек.

ИКЪТИСАДТА ХӘЛӘЛ

Руслан Хәлиуллин, Россия ислам институты каршында Россия ислам икътисады һәм финанслары үзәге эксперты:

– Алдагы спикерлар белән килешәм, ислам финанс инструментларын кертүдә проблемалар бар. География төрле – проблемалар бер үк. Алардан башлыйм. Халыкның финанс грамоталылыгы. Ул нульгә якын. Дини белем шул ук дәрәҗәдә. Бер проблема икенчесенә өстәлә. Хәлдән килгәнчә моңа каршы көрәшәбез. Бүген кеше күп нәрсәне бер аршын белән үлчи: монда – отышлы, ә менә монда отышсыз. Беренче урында: хәләл яки хәләл түгел булырга тиеш. Моны аңлар өчен кешенең иманы, эчке таянычы булырга тиеш.

Гомумән, ислам финанслары, гади генә әйткәндә, – кыйммәтле кәгазьләр, иминият һәм банк ул. Кыйммәтле кәгазьләр төп компонент. Кыйммәтле кәгазьләр булмаса, без пенсия фондын булдыра алмыйбыз. Аларсыз ислам нормалары буенча эшләүче инвестиция фондын, иминият компаниясен оештыра алмыйбыз. Ахыр чиктә банк та ача алмаячакбыз. Алга таба хәрәкәт булмаса, дистәләгән миллионнар диапазонында гына эшләячәкбез, гәрчә ихтыяҗның күпкә күбрәк икәнлеген күрсәк тә.

– Алга таба хәрәкәттә Россия ислам икътисады һәм финанслары үзәгенең роле нинди?

– Без нәкъ менә партнёрлык ислам продуктларына экспертиза үткәрәбез, аларның аталган принципларга ни дәрәҗәдә туры килүен бәялибез. Бүгенге көндә дистәләгән банк, финанс институты ислам финанславына кызыксыну күрсәтә. Еш кына бу турыда бик аз беләләр, ләкин катнашырга телиләр. Алдагы спикер дөрес әйтте: әгәр банкирлар файда күрмәсәләр, аларга бу өлкә кызык түгел. Шуңа күрә дә тайпылышлар бар. Без шуны күзәтәбез: банк офисы ачыла, белгеч кызлар яулык япкан, ә хәләл дип игълан ителгән продуктлар ислам нормаларына берничек тә туры килми. Өстәвенә, экспертизаны Африка кешесе ясый. Ул безнең базарның үзенчәлеген аңлыймы? Үзәк банкның безне ничек контрольдә тотуын, финанс оешмаларыбызның ничек эшләвен беләме? Бездә иминият нәрсә ул? Юк, аңлап җиткермидер. Банкның кечкенә булмавын исәпкә алсак, мондый ялган старт ислам финанслары идеясенең абруен төшерә ала.

Ислам финансларының кыйммәте нәрсәдә? Бездә кешеләр шикле схемаларга, ниндидер пирамидаларга эләгеп алданулардан арыдылар. Алар, ниһаять, кешегә йөзе белән борылган банкны күрергә телиләр, шикләнмичә килеп, алданудан курыкмаслык булсын. Җәмгыятьтә намуслы бизнес һәм гадел мөнәсәбәтләргә ихтыяҗ бар. Ислам финанслары, минемчә, менә шушы гаделлек күрсәткече булырга мөмкин һәм тиеш тә.

– Үзәк экспертизасын уңышлы узган һәм базарда югалмаган продуктлар бармы?

– 2019 елда Россия ислам институты, аерым алганда, нәкъ менә безнең Үзәк һәм «Ак Барс Капитал» ИК тарафыннан «Ләлә» фонды оештырылды, ул бишенче ел уңышлы эшләп килә. Шул ук елда фонд илдә керем буенча 11 нче урынны алды – бу мәгълүмат ислам финанслары турында бары тик хәйриячелеккә бәйләп – килде, бер капчык акча калдырды һәм китте дип, ялгыш фикер йөртүчеләр өчен. Әйтик, узган ел фонд Россиядә Ачык пай инвестицияләре фондлары арасында 4 нче урынны алды. Шул ук вакытта без, әлбәттә, хәмерле продукциягә дә, тәмәкегә дә акча салмыйбыз.

2021 елда Россиядә беренче Вакыф эшли башлады, ул закон кысаларында эш йөртә, бу – эндаумент-фонд. Әлмәттәге 1 нче интернат-лицее өч миллион ике йөз мең сум күләмендәге әлеге фондны формалаштырды, аның белән «Ак Барс Капитал» ИК идарә итә. Бүгенге көндә фонд акчалары алты миллион сумнан артып китте. Хәйриячелек гадәттә ничек эшли? Мәсәлән, кешеләр мәчет өчен акча җыя – хәзрәт сарыф итә. Коммуналь түләүләргә, хезмәт хакына, сакчыга һ.б. Акча ай саен ком кебек ага. Ә фонд акчаны туплый һәм акча эшли. Һәм бары тик эшләп тапкан – өстә яткан акчалар гына көндәлек ихтыяҗларга сарыф ителә. Карагыз, иң бай саналмаган илләр дә, әйтик, Мисыр мәчет, мәдрәсә, институт бюджетларын тулысынча формалаштыра. Ә без нәрсә? Ифтар уздыру, хөрмә сатып алу өчен генә акча җыярга сәләтлеме? Мин тәнкыйтьләмим, беренче чиратта үземне күздә тотам. Оят, дусларым, оят. Без сезнең белән мәчет-мәдрәсәләрне һәм институтларны тулысынча тәэмин итәргә тиешбез.

Тагын яңа компанияләр турында берничә сүз. Бездә «Сахих инвест» дигән компания бар. Алар июль аенда, Казахстандагы ITS Халыкара финанс биржасына мөрәҗәгать итеп, бергәләп, аларның ярдәме белән советлардан соңгы киңлектә беренче тапкыр ислам индексын эшләтеп җибәрделәр. Фонд базары, әлбәттә, үзгәрүчән нәрсә, ләкин иминияткә, банкларга этаплап килү өчен безгә мондый корал кирәк.

Хәзер экспертиза пенсия фонды документларын карый, күчемсез милек фондлары, алтын фондлары буенча запрослар бар. Продукция күп, алар белән эксперимент башланганчы ук эшләдек, нәтиҗәләрнең нинди генә булуына да карамастан, алга таба да эшләячәкбез.

– Фондларда катнашучылар – диндәге кешеләрме, күбесенчә мөселманнармы?

– Җитмеш процент – исламнан ерак кешеләр. Безгә сезнең консерватив стратегиягез ошый, без мөселманнарга ышанабыз, дип аңлаталар алар үзләре. Сездә экспертиза бар, без сезне алдамассыз дип ышанабыз, диләр. Ләкин шуны аңлау мөһим: бер начар хәл күп кешеләрне бездән читкә этәрергә мөмкин. Шуңа күрә барлык катнашучыларның да экспертиза үтүе бик мөһим.

– Димәк, җәмгыятьнең ислам финансларын гамәлгә кертү буенча экспериментка әзер булмавы миф?

– Әгәр сез ислам финанслары белән шөгыльләнәсез икән, билгеле бер югары планка булырга тиеш. Ул отышлы, ачык, законлы булырга тиеш, мобиль кушымтагыз эшләсен – хәзер барысы да электрон форматта. Һәм тагын бер өстәмә: барысы да хәләл булырга тиеш. Бездә кайвакыт киресенчә дә була. Эшләре уңышлы бармаган компанияләр үз продуктын хәләл дип тәкъдим итә – экспертизасыз гына. Һәм аларга кешеләр тартылыр дип көтә. Менә бу дөрес түгел. Без билгеле бер продуктларны һәм озын акчаларны көтәбез.

– Сөйләшүебез ахырында... «Лалә» фонды әгъзасының портретын тасвирлагыз әле.

– Бу, кагыйдә буларак, яшь кеше – 20 дән 45 яшькә кадәр. Финанс ягыннан грамоталы, инвестицияләрне яхшы белүче зат, гади кеше түгел. Базар үсә, ничек эш йөртергә кирәклеген аңлаучы белемле кешеләр дә күбәя бара. Ләкин мин һәрвакыт шуны искә төшерергә тырышам: бөтен акчагызны монда алып килмәгез, барлык йомыркаларны бер кәрзингә салмагыз. Мөгаен, бер генә инвестиция компаниясендә дә мондый әйбер юктыр. Без клиентлар өчен җаваплылык тоябыз.

Әйе, диверсификацияләргә кирәк. Продуктлар күбрәк булган саен, уенчылар да арта барачак. Гомумән, һәр проект артында – уңышлымы ул, юкмы – һәрвакытта да конкрет шәхес тора. Үз идеяләре белән рухландыручы зат. Ислам банкингы буенча экспериментта катнашучылар арасында андый шәхесләр җитәрлек. Шуңа күрә ышаныч та зур: эксперимент нәтиҗәсе һичшиксез уңышлы булачак.

ТОРМЫШТА ҺӘМ ФИНАНСЛАРДА БӘРӘКӘТ

Рөстәм Сәгъдиев, «Амаль» ФЙ генераль директоры

Безнең республикада «бәрәкәт» сүзен еш кына хәләл кафелар, кибетләр һәм компанияләр исемнәрендә очратырга мөмкин. Бу төшенчә ни белдерә? Мөселманнар еш кына бер-берсенә бәрәкәт тели, бу алар өчен ник шулкадәр мөһим?

Бәрәкәт – илаһи нигъмәт, нәрсәдә дә булса Аллаһ ризалыгы ул. Ул мөселманны чолгап алган һәрнәрсәне – милек, гаилә, ризык, бизнес һәм башкаларны колачлый.

Кешенең муллыкка омтылуы – табигый күренеш, дин күзлегеннән караганда да монда һичбер начарлык юк. Әмма бары Аллаһы Тәгалә индергән нигъмәтләр генә хәләл булып санала һәм кешегә чын бәхет китерә.

Без тормышта бәрәкәт күренешләре белән еш очрашабыз. Әйтик, бер күршебезнең машинасы бик иске кебек, ләкин ул беркайчан да ватылмый диярлек. Эшкуар дустыбызның криптовалюталар дөньясыннан һәм модалы әйберләрдән хәбәре юк, әмма аның инвестицияләре уңышлы эшли, кризислар аңа бер дә кагылмый. Илаһи арифметика ничек корылган соң? Ни өчен «Амаль» Финанс Йорты клиентлары инвестиция кертемнәренең параметрларына һәм финанс күрсәткечләренә генә карамый?

Иң элек, алар, Аллаһы Тәгалә кушканнарны үтәп, Ул тыйганнардан тыелып, аннан бик зур әҗер алуларын аңлыйлар. Эш принцибы акчаны процентка биреп торуга нигезләнгән гадәти банкны сайлаган мөселман акчалата кертем шартларында бераз отышта кала. Ләкин бу очракта бәрәкәт югала, акчада гына түгел, ә аны киләчәктә куллану вариантларында да (мәсәлән, әгәр ул акчаларны балаларны укытуга дип җыеп барган булса). Сүз уңаеннан, риба алу башка кайбер диннәрдә дә тыелган. Рус телендәге «лихва», «лихоимство» сүзе үзе үк тискәре төсмергә ия.

Шулай ук акчаның нинди юл белән алынуы да мөһим. Әгәр дә акчалар хәмер сата торган кибеттән яки комарлы уеннар оештыра торган букмекерлык конторасыннан кергән булса, бәрәкәт турында сүз кузгату да урынсыз. Ә гадәти банк системасында синең акчаңны кайсы тармакка салганнарын ничек тикшерергә? Берничек тә тикшереп булмый. Нәтиҗәдә, «акчаның исе юк» дигән принцип эшкә җигелә.

«Амаль» Финанс Йорты партнерлык банкингы принципларына нигезләнгән. Акча акчага алыштырылмый, ә матди активларга салына, аларны чынлап та тикшереп, карап-капшап була, шуңа күрә ислам финанс операцияләре сәүдә операцияләренә якынрак. «Амаль» Финанс Йорты кертемчеләре компанияләргә медицина җиһазлары, кешеләргә көн саен файда китерә торган җитештерү линияләре һәм станоклар сатып алырга булыша. Акча әлеге финансларны кабул итеп алган компанияләр өчен дә, кертемчеләрнең үзләре өчен дә керем чыганагы була. Узган эш тәҗрибәбездә шундый очраклар булды: кеше безнең аша товар ала, ә бераздан үзе безнең белән инвестор буларак хезмәттәшлек итә. Клиентлар үзләре билгеләп үткәнчә, ике очракта да алар бәрәкәткә тиенә. Рөхсәт ителгәнне сайлаган һәм шикле нәрсәдән тыелган кешегә Аллаһы Тәгалә юлларны һәрвакыт җиңеләйтә һәм яңаларын ача: «ничек түләп бетергәнемне сизми дә калдым», «эшләр югары үрләде, алган йөкләмәләрне вакытыннан алда түләргә мөмкинлек туды», «капиталны арттырдым, акчаны чыгардым һәм бизнес үсә башлады» дигән сүзләр нәкъ шундый очракларны белдерә. Система нәкъ шулай эшли дә. Партнерлык банкингында файда һәм бәрәкәт әйләнешен аңлатып бирү өчен, без хәтта «благономика» дигән термин да (бәрәкәт һәм икътисад – ред. иск.) уйлап таптык.

Бәрәкәт математика законнарына һәм акчаларның эшләве турындагы безгә таныш кагыйдәләргә буйсынмый. Акча, милек, белемдәге бәрәкәткә даими үсеш һәм арту хас. Аз булган нәрсә бәрәкәт ярдәмендә күбәя, ә күп булганы файдалыга әйләнә.

«Амаль» Финанс Йорты 2010 елда эшли башлады. Дүрт елдан соң без Татарстаннан читкә дә чыктык, хәзер бөтен Россия буенча эш алып барабыз. Кризис һәм икътисадый тетрәнүләргә карамастан, без ныгыдык, көчәйдек; әле ислам банкингы турында законнар да булмаган вакытта (закон проекты быел гына кабул ителде) Мәскәүдә офис ачтык – болар бәрәкәтнең чагылышлары түгелме?

Клиентларыбызга да, инвесторларыбызга да, барлык укучыларга да үзегез тели алган барлык илаһи нигъмәтләргә ирешүегезне телибез. Мөлкәттә, бизнеста, белемдә һәрвакыт бәрәкәт юлдаш булсын. Бәрәкәтле эш иткәндә, балаларыгыз да тәүфыйклы һәм сәламәт булачак!

Фото «Амаль» Кулланучылар җәмгыятеннән алынды. РЕКЛАМА. «АМАЛЬ» КЖ

ТАТАРСТАНДА УКЫЙСЫҢ –
«ТАТАРСТАН»НЫ УКЫ

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАНДА ҖИҢӘСЕҢ –
«ТАТАРСТАН»НЫ УКЫ

ТАТАРСТАНДА ЭШЛИСЕҢ –
«ТАТАРСТАН»НЫ УКЫ

ТАТАРСТАНДА ЯШИСЕҢ –
«ТАТАРСТАН»НЫ УКЫ

Реклама 16+

WWW.PROTATARSTAN.RU

«ВАМИН» СЫРЫН ГАРӘБСТАНДА ДА БЕЛӘЛӘР!

Россиядә җитештерелгән тәмле, сыйфатлы сыр безнең кибет киштәләрендә көннән-көн күбәя бара. Көнбатыш чикләүләренә җавап итеп, илдә сыр җитештерә торган кечкенә генә хосусый компанияләр дә, зур предприятиеләр дә ачыла. Алай гына да түгел, иң кыюлары инде чит ил базарларын да яуларга җыена. Шулардан берсе – «Вамин Татарстан».

2021 елда «Вамин Татарстан» үз продукциясен Казахстан, Беларусь һәм Кыргызстанга җибәрү буенча беренче килешүләрен төзегән иде. Әлеге илләргә 100 тоннадан артык сыр сатылды.

Башка җитештерүчеләрдән артта калмас өчен, гаять зур тырышлык куярга туры килә – импорт белән кызыксынучыларны продукция белән таныштыру, аларның теләкләрен исәпкә алу, сыр кайнатудагы бөтен нечкәлекләрне күрсәтү, бары тик сыйфатлы чимал гына файдаланылганны эш белән дәлилләү зарур.

Мөселман илләренең иң мөһим шарты – продукциянең шәригать кануннарына тәңгәллеге, хәләл булуы.

– Без үз продукциябезнең хәләллегендә ышандырганда, аны җитештерүдә кулланылган бөтен чимал, ингредиентларның да хәләл булуын дәлиллибез, – ди Балтач май-сөт комбинаты технологы Раил Гарипов. – Бу бары тик үсемлек һәм диңгез продуктлары, шәригать кануннары буенча, дога укып чалынган хайван ите. Сыр җитештергәндә сөтне әчетү өчен хайваннардан алынган фермент кулланыла. Аның хәләллек статусы шулай ук тиешле сертификатлар белән раслана. Безнең компания хәләл стандартлары буенча аккредитацияне РФ мөселманнары Диния нәзарәте каршындагы халыкара «Хәләл» стандартлаштыру һәм сертификатлар бирү үзәгендә үтте һәм халыкара «Хәләл» нормаларына тәңгәл килә.

Фотолар «Вамин Татарстан» ҖЧҖтән алынды. РЕКЛАМА

Табигый ки, «Вамин» продукциясен сайлауга бик күп башка факторлар да йогынты ясый. Гадәттә алар товар җибәрелә торган төбәккә бәйле рәвештә бераз аерыла. Әйтик, БДБ илләрендә Россия сырларын яхшы беләләр һәм алар өчен төп критерий – сыйфат, яраклылык вакыты һәм бәя. Анда бик күп төрле Беларусь, Литва, Финляндия сырлары тәкъдим ителә, шунлыктан кайбер сәүдә челтәрләре Россиядәге партнерыннан алар өчен файдалы акцияләр үткәрүләрен яки кайбер очракларда түләүне кичектереп торуларын сорарга мөмкин.

Фарсы култыгы илләрендә Россиядә ясалган сыр әлегә әллә ни танылмаган. Шунлыктан анда партнерлар табу җиңел түгел, чөнки сәүдә челтәрләренең күпчелеге өчен сатып алучының продукция белән таныш булуы мөһим. Әмма, тырышкан табар, диләр бит. Күптән түгел Согыд Гарәбстанында уздырылган күргәзмәдә дистрибьюторлар Татарстан сырларының табигый тәмен мактады һәм аны өйдә ясалган сырга тиңләде. «Вамин» продукциясенең дегустациясе үткәрелгән һәр җирдә аны авыз итеп караучыларга сырларның үзенчәлекле тәме ошады.

Бүген халыкара базар импортерлары хайван азыгы сыйфатында кулланыла торган продукция белән дә кызыксына. Мәсәлән, сыр кайнатудан соң калган эремчек суын киптерү юлы белән ясалган порошокка БДБ һәм ерак чит илләр базарларында ихтыяҗ зур. Биредә клиентлар өчен иң мөһиме – продукциянең импортер ил таләпләренә җавап бирүе. Әйтик, кытайлар үзләренә кертеләчәк сөт җитештерелгән фермаларда кулланыла торган препаратларга көчле контроль үткәрә, Вьетнам исә продукцияне Россия таләпләрендә каралмаган күрсәткечләр буенча тикшерүне сорый. Ерак чит илләргә җибәрү өчен төргәкләр озын юл үтәрлек нык һәм температура сикерешләренә чыдам булырга тиеш.

Импорт турында карарны иң әүвәл потенциаль сатып алучы кабул итә. Бу дистрибьютор, сәүдә челтәре яисә күпләп сату компаниясе яки җитештерүче предприятие (эремчек суы турында сүз барган очракта) булырга мөмкин. Әмма Россиядән экспортка чыгаруга рөхсәтне «Россельхознадзор» бирә, аны аудитны уңышлы үткән очракта гына алып була.

– Потенциаль сатып алучыны бер дә көтелмәгән урында да табарга мөмкин. Без Әр-Рияд шәһәрендә ел саен үткәрелә торган Saudi Agriculture 2023 күргәзмәсендә Россия павильоны составында катнашкан идек, ул илебез экспортлык үзәге химаясендә оештырылды, – дип мисал китерә «Вамин Татарстан» ҖЧҖ директоры Айрат Мөхәммәдиев. – Согыд Гарәбстанының ашамлыклар буенча дистрибьюторлары һәм төп сәүдә челтәрләренең күпләп сатып алучылары белән сөйләшүләр үткәрелде. Продукциябез сыйфаты: тәме һәм тышкы кыяфәте буенча югары бәя алды. Ерак чит илләр белән эштә иң кыены – сырның куллану вакыты чикләнгән булуы, шуңа хәзер логистиканы яхшырту вариантларын өйрәнәбез.

Согыд Гарәбстанында иң зур пиццерияләр челтәренең берсе саналган компаниянең чакыруы буенча аның үзәк офисында булдык. Персонал әзерләү һәм яңа рецептуралар эшләү үзәгендә бер сырыбызның эрүчәнлеге һәм әзерләү процессында тәмен ничек саклавы сыналды. Без Согыд Гарәбстаны компаниясе технологларыннан югары бәя алдык һәм инде якын арада ук үзара хезмәттәшлекне башларга ниятлибез. Гомумән, продукцияне Согыд Гарәбстаны базарына чыгаруның кыенлыгы әлеге илгә продукция кертү өчен рөхсәт алу процедурасының катлаулы булуына һәм Россия җитештерүчеләре белән эшләү тәҗрибәсе җитмәүгә бәйле.

«Вамин» компаниясенең иң популяр сырлары өчлегенә «Голландский», «Российский» һәм «Гауда» керә. «Голландский» сырының йомшак тәме аның белән сыйлануны ләззәткә әйләндерә. «Российский» сырының, җитештерүчегә һәм рецептурага бәйле рәвештә, тозлылык дәрәҗәсе төрлечә була ала. «Гауда» сырының ымсындыргыч бай тәме озаграк өлгергән саен яхшыра гына бара. Сырның әлеге сортлары еш кына югары сыйфатка һәм җитештерүнең традицион ысулларына да ишарә булып тора һәм әлеге ризыкны яратучыларны җәлеп итә.

Ике ел эчендә генә дә «Вамин Татарстан» ҖЧҖ үз сырларын Таҗикстан, Азәрбайҗан, Төрекмәнстан, Грузия, Монголия, Филиппин, Вьетнамга экспортка чыгара башлады. Шулай ук Кытай һәм Согыд Гарәбстаны белән килешүләр төзелде. Компания продукциясенең сыйфаты халыкара нормалар буенча аккредитацияләнгән Бөтенроссия хайваннарны яклау фәнни-тикшеренү институты лабораторияләрендә даими тикшерү үтә.

Халыкара базарларда көндәшлек көчле булуга карамастан, «Вамин Татарстан» ҖЧҖ ышанычлы адымнар белән алга бара. Чөнки «Вамин» сырлары – горурланырлык продукция ул: телеңне йотарлык чын тәм һәм мактауга лаек югары сыйфат.

КАДРДА – БӘБИ:
ИҢ БЕРЕНЧЕ МИЗГЕЛЛӘРНЕ ИСТӘЛЕККӘ КАЛДЫРУ СӘНГАТЕ

Оксана Бирюкова

Елена Росси – хәзер бик популяр newborn юнәлешендә Казанда гына түгел, башкалабыздан читтә дә танылган топ-фотограф, ул яңа туган сабыйлар тормышындагы иң садә мизгелләрне профессиональ гәүдәләндерә белә. Аның эшләре – хис һәм эмоцияләр дулкыны тудырырга сәләтле чын сәнгать ул. 26 ноябрь – Россиядәге Әниләр көне алдыннан фотограф «Татарстан» журналына җылылык тулы кадрларны ничек төшерү һәм үзенең бәбиләр белән ничек уртак тел табуы хакында сөйләде.

– Елена, фотограф буларак сезне newborn юнәлешенә нәрсә җәлеп итте?

– Мөгаен, балаларны яратудыр. Бәләкәй чагымда энекәшемне карарга бик ярата идем, бик җаваплы апа булдым. Аннары Австралиядән танылган фоторәссам Анне Гендес эшләре таң калдырды – ул кәрзиндә йоклап ятучы бәбиләрне шулкадәр матур итеп төшерә. «Ничек шулай булдыра икән? Минем дә шулай төшерәсем килә бит», – дип уйлый идем мин. Җиде ел элек исә үзем дә шул юлга кереп киттем. Бүген бик рәхәтләнеп бәбиләрне генә түгел, клиникада бәби табу вакытын да, йөкле хатыннарны да төшерәм. Әмма иң яратканы барыбер newborn жанрыдыр, мөгаен.

– Сезнең фотосессияләрнең үзенчәлеге нидә?

– Бу һәрвакыт гаилә өчен бик мөһим вакыйга, аны әниләр түземсезлек белән көтеп ала. Бик тиз уза торган гомеребездә тормышның иң бәхетле чорларын хәтергә мәңгегә сеңдерәсе килә. Учка сыярлык кына бәбинең самими сурәте кадәр гүзәл тагын ни бар соң бу дөньяда?!

– Эшегез һәрвакытта да уңышлы гына барамы? Сабыйларның кәефе бик тиз үзгәрүчән бит.

– Минем иҗат портфолиосында 700 дән артык сабыйның фотосы бар. Казан спортчылары, эшкуарлары һәм артистлары, Россия эстрадасы йолдызлары миңа үз бәбиләрен ышанып тапшыра. Кагыйдә буларак, миндә фотога төшү өчен берничә ай алдан чиратка басарга кирәк, шунлыктан булачак әниләр фотосессиягә йөкле вакытта ук язылып куя. Мин үзем дә күп балалы ана, шунлыктан теләсә кайсы бәби белән уртак тел таба алам. Минем яныма фотога төшәргә килгән әниләрне бу вакытта булса да бераз ял иттерәсем килә. Шуңа миңа кунакка килгән сабыйларны мин үзем киендерәм, тирбәтәм. Без бәләкәч белән, тәүге һәм иң самими фотоларга төшеп, гүзәллек тудырабыз, ә эти-әниләр янәшәдә карап кына тора.

– Фотога төшерү процессы ничек оештырыла, анда иң кыены нәрсә?

– Мин эшемне һәрвакыт төгәл сценарий буенча оештырам. Нинди әзлеклелектә, нинди локация һәм образларда төшерәсемне, утны кая куясымны, бәбине кайчан ашатасын алдан ук уйлап куям. Бу бик мөһим: newborn – фотографиядә иң катлаулы жанрлардан берсе, әмма иң мавыктыргычы да! Профессионалның бурычы – матур сурәт тудыру гына түгел, бәбигә иң уңайлы шартлар булдыру да. Иң соңыннан бөтен гаилә бергә фотога төшә. Әлеге кадрларны мин бик яратам, алар фотокитапларда бик матур чыга. Казанда да, аннан читтә дә минем фотокитапларымны күргән һәркем шакката. Минем эшемнән бик канәгать әниләрдән инде йөзләрчә рәхмәт ишеткәнем бар.

– Фотографны ничек сайларга, киңәш бирегез әле?

– Иң мөһиме, ул сезгә ошарга тиеш, чөнки сез аңа иң кадерле кешегезне ышанып тапшырасыз бит. Икенче урынга мин иминлекне куяр идем. Сезнең фотографның һичшиксез медицина кенәгәсе, тәҗрибәсе һәм махсус курсларда укуы турында сертификатлары булырга тиеш. Биредә бит бөтен нечкәлекләрне белеп эш итү зарур. Хәзер социаль челтәрләрдә белгечне эзләп табу һәм күзәтү, эшләрен карау мөмкинлеге бар, шулардан чыгып, әлеге кешенең сезнең зәвыкка туры киләме-юкмы икәнен ачыкларга була.

– Newborn-фотография гаилә кыйммәтләрен ныгыта, дигән фикер бар. Сез бу хакта нәрсә уйлыйсыз?

– Безнең илдә гореф-гадәтләрне хөрмәт итә, буыннан-буынга тапшыра, гаилә кыйммәтләрен һәм реликвияләрен, шул исәптән фотосурәтләр, открыткалар, хатларны саклый беләләр. Россиядә бу юнәлеш нәкъ менә шуңа күрә киң таралгандыр да әле. Бәлки бик купшы да яңгырар, әмма мин фотография сәнгате бала-чагалы нык гаилә образын формалаштыруга булыша, дип саныйм. Минем миссиям исә – әлеге процесста юл күрсәтүче булу.

Елена Росси фотосы. РЕКЛАМА

скандинавия
ИГЪТИБАРЛЫ МЕДИЦИНА КЛИНИКАСЫ

(843) 200-10-65

«Скандинавия» клиникасының бала тудыру йортында ислам кануннарына туры китереп бәби табарга була

Клиникабыз Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенең «Хәләл» стандарты комитеты тарафыннан бирелгән таныклыкка ия, ул ислам кануннары нигезендә бәби таптыру мөмкинлеген раслый.

- Палатада кеше һәм хайван сурәтләре, шулай ук исламның әхлакый-этик нормаларына каршы килгән предметлар һәм рәсемнәр юк.
- Намаз уку өчен кирәкле атрибутлар (Коръән, намазлык, тәсбихләр) бар. Изге Кәгъбә юнәлеше билгеләнгән.
- Туалет бүлмәләрендә тәһарәт алу өчен кирәкле һәрнәрсә бар.
- Хатын-кыз табиблардан гыйбарәт махсус бригада оештырылган.
- Хәләл ризык бирелә.
- Дарулар һәм дәвалау максатларында кулланыла торган әйберләрнең ислам кануннары буенча медицина хезмәтләре күрсәткәндә файдалануга рөхсәте һәм шуны раслаган документлары бар.
- Хатын-кыз бала табу бүлегендә йөргән чакта, махсус кагыйдәләр үтәлә: аны чит кешеләр һәм клиника хезмәткәрләре күрми.

Татарстан мөселманнары Диния нәзарәтенең «Хәләл» стандарты комитеты» продукция сыйфатын контрольдә тоту шәхси учреждениесе.

Бала тудыру йорты сайтына күчү өчен, QR-кодны сканерлагыз.

ТАБИБ БЕЛӘН КИҢӘШЛӘШҮ ТАЛӘП ИТЕЛӘ

ЛИЦЕНЗИЯ БЕЛӘН КЛИНИКА САЙТЫНДА ТАНЫШЫРГА БУЛА. РЕКЛАМА

ТАТМЕДИА

ТАТМЕДИА ГАЗЕТА-ЖУРНАЛЛАРЫ ҺӘМ ОТКРЫТКАЛАРЫ — МАРКЕТПЛЕЙСЛАРДА

shop.tatmedia.ru

WILDBERRIES

OZON

Я Маркет

«ТАТМЕДИА» АЖ. Адрес: 420066 Казан ш., Декабристлар ур., 2. ГРН 1071690057834

16+

Реклама

акыллы гамәлләр

игелекле эшләр

мәңгелек кыйммәтләр

Бу санда тәкъдим итәбез:

Мәктәптә һөнәр сайлау **ничек** оештырылган

Апас якташлык җәмгыяте **нинди** эшләр эшли

Аюлар Татарстан урманнарын **нигә** үз иткән

Евгения Чеснокова

Бүген мәктәпләрдә һөнәри юнәлеш бирү эше ничек оештырылган? Урта белем бирү йортларына вузлар һәм предприятиеләр ничек ярдәм итә? Нигә ата-аналар өчен дә тест үткәрергә кирәк? Бу турыда без Татарстан мәгариф һәм фән министры урынбасары Минзәлия Заһри кызы Закирова белән сөйләштек.

ҺӨНӘРИ ЮНӘЛЕШ БИРҮ – КИЛӘЧӘККӘ ЮЛ КҮРСӘТҮ

– Минзәлия Заһриевна, шулай итеп, мәктәптә һөнәри юнәлеш бирү дәресләре укытыла башлады...

– Сүзебезне шуннан башлыйк: урта белем бирү системасында һөнәри юнәлеш бирү дәресләре һәрвакыт булды. Документлардан күренгәнчә, 1980 нче елларда ук, «укучыларны хезмәткә өйрәтү һәм һөнәри юнәлеш бирү эшен тамырдан яхшырту» дәүләтнең беренчел бурычларыннан берсе саналган. Совет елларында, мәсәлән, атаклы физика-математика мәктәпләре ачыла башлады. Ә барлык югары сыйныф укучылары мәҗбүри рәвештә нинди дә булса бер һөнәргә өйрәнергә тиеш иде. Без моны хәтерлибез, һәм хәзерге чынбарлык нәкъ менә шушы нигезгә таяна да.

– Ә бүген мәктәпләрдә һөнәри юнәлеш бирү эше ничек оештырыла?

– Россия Мәгариф министрлыгының методик киңәшләре бар, анда һәр мәктәптә мондый эшне оештыруның җиде форматы билгеләнгән. Беренчедән, бу, әлбәттә, дәрес форматы, һөнәри юнәлеш бирү һәр предмет буенча дәреснең бер өлеше булып тора. Быелгы яңалыклар турында сөйләсәк, «Россия – минем горизонтларым» дип аталган дәрестән тыш курс пәйда булды, ул 6-11 сыйныфларга атнасына бер сәгать керә. Бу программаның нигезен Татарстанда «Киләчәккә билет» проекты тәшкил итә. Проектта яшүсмерләргә һөнәри юнәлешле диагностикалар үткәрү, икътисадның төрле тармакларын, хезмәт базарының төбәк үзенчәлекләрен өйрәтү, мәшгульлек һәм социаль яклау хезмәтләренең эше белән таныштыру каралган.

Шулай ук һөнәри юнәлеш бирү кысаларында җитештерү предприятиеләренә экскурсиягә бару, һөнәри юнәлеш бирү күргәзмәләре белән танышу, һөнәри сынап карауларда, һөнәр ярминкәләрендә, югары уку йортлары, көллият һәм техникумнар үткәргән «Ачык ишекләр» көннәрендә катнашу, укучыларның проект эшчәнлеге дә оештырыла.

«Кем булырга?» дигән сорауның һәр заманда мөһим булуын һәм һөнәри юнәлеш бирү эше һәр баланың һөнәр сайлавында, омтылышларын һәм талантларын ачуда һәрвакыт башлангыч этап булып торуын ба-

Фото: tatar-inform.ru

рыбыз да аңлый. Моннан тыш, бу эш илнең кадрларга ихтыяҗы һәм технологик бәйсезлеге мәсьәләләрен дә хәл итәргә тиеш...

– Ә бу, үз чиратында, грамоталы һөнәри юнәлеш бирү белән мәктәп кенә кызыксынырга тиеш түгеллекне аңлата...

– Әлбәттә, бередә предприятиеләр дә, төрле иҗтимагый һәм һөнәри институтлар да үз өлешен кертергә тиеш, чөнки бу безнең уртак киләчәгебез.

– Ә мәктәп һәм көллиятләр, югары уку йортлары, предприятиеләрнең һөнәри юнәлеш бирү эшендә уңышлы хезмәттәшлек мисаллары бармы? Әйтик, минем белүемчә, медицина университеты кайбер мәктәпләрдә үз сыйныфларын ачкан...

– Бүген 17 мәктәптә укучылар белән эшләүче медицина университеты гына түгел, әлбәттә. 114 уку йортында агрокласслар ачылган. КМТТУ-КХТИның «Промхимтех» алдынгы инженерлык мәктәбе ярдәме белән 22 мәктәптә һөнәри юнәлеш бирү эше оештырылган. Безнең мәктәпләрдә IT, энергетика секторына, булачак нефтьчеләр һәм инженерларны әзерләүгә юнәлдерелгән сыйныфлар бар – болар барысы да төрле предприятиеләр ярдәме белән эшләнә.

Полилингваль белем бирү (алты мәктәпне үз эченә ала) һәм кадет белем бирү (бер кадет корпусы, унбер интернат-мәктәп һәм өч кадет мәктәбе) системалары – аерым тема.

Укучыларга һөнәри юнәлеш бирү методлары һәм технологияләре өлкәсендә укытучылар өчен квалификация күтәрүне бушлай оештырган югары уку йортларының эшен билгеләп үтәсе килә. Мәсәлән, быел көзге каникуллар вакытында «Агрокласс» проектында катнашучы укытучыларны аграр университет һәм ветеринария академиясе базасында укыту оештырылды. КФУ, медицина университеты, КМТТУ-КАИ, энергоуниверситет тарафыннан кызыклы проектлар гамәлгә ашырыла. Битарафлыкның булмавы бик сөендерә.

– Һөнәри юнәлеш бирү, мөгаен, мәктәп укучысының теге яки бу эшчәнлеккә омтылышын, сәләтен тикшерүне дә күздә тотадыр...

– Әлбәттә. Моның өчен федераль күпфункцияле мәгълүмати-хезмәт күрсәтүнең онлайн-платформасыннан (https://bvbinfo.ru/) файдаланабыз. Анда укучының кызыксынуларын ачыкларга мөмкинлек бирә торган методика ярдәмендә онлайн-диагностика үтәргә һәм шуның нигезендә укучыга уку профилен тәкъдим итәргә мөмкин. Бу эш алты яшь төркемендә башкарыла, 6-11 сыйныфлар өчен. Тест нәтиҗәләре буенча платформада автомат рәвештә конкрет киңәшләр белән индивидуаль отчет формалаштырыла, шул исәптән белем баскычын сайлау һәм БДИ тапшыру өчен тәкъдим ителгән предметлар исемлегенә карата да. Отчет мәктәп укучысына, аның әти-әнисенә яисә законлы вәкилләренә дә бирелә. Аерым отчет мәктәпкә тапшырыла, бу уку профильләре буенча бүлгәндә укучыларның кызыксынуларын исәпкә алырга булыша.

– Нәкъ менә әти-әниләр белән эшләү турында сорыйсы идем, чөнки баланың һөнәр сайлавында аларның роле бик зур бит...

– Дөрес. Без аларга тест нәтиҗәләре турында хәбәр итеп кенә калмыйбыз, тематик ата-аналар җыелышлары үткәрәбез, аларны төрле һөнәр вәкилләре буларак һөнәри юнәлеш бирү эшендә актив катнашуга җәлеп итәбез, алар белән хезмәт базарының актуаль һөнәрләре, кадрлар ихтыяҗын фаразлау турындагы мәгълүмат белән уртаклашабыз.

> «КЕМ БУЛЫРГА?» ДИГӘН СОРАУНЫҢ ҺӘР ЗАМАНДА МӨҺИМ БУЛУЫН ҺӘМ ҺӨНӘРИ ЮНӘЛЕШ БИРҮ ЭШЕ ҺӘР БАЛАНЫҢ ҺӨНӘР САЙЛАВЫНДА, ОМТЫЛЫШЛАРЫН ҺӘМ ТАЛАНТЛАРЫН АЧУДА ҺӘРВАКЫТ БАШЛАНГЫЧ ЭТАП БУЛЫП ТОРУЫН БАРЫБЫЗ ДА АҢЛЫЙ.

Хәтта ата-аналар өчен тест та бар. Тест бер үк критерийлар буенча баланың үз-үзен күзаллавы белән ата-ананың баласы турындагы күзаллавы никадәр туры килүен ачыкларга ярдәм итә. «Ата-ана сценарийлары» дигәне аерым игътибарга лаек, чөнки ул өлкәннәрнең һөнәри эшчәнлекне сайлау ысуллары турында үз балаларына трансляцияләгән карашларын ачыкларга һәм, ихтимал, төзәтергә ярдәм итә.

– Мәктәпләрдә һөнәри юнәлеш бирүнең көчәюеннән без нинди нәтиҗәләр көтә алабыз?

– Һөнәр сайлауда аңлы компетентлылык формалаштыру гаять мөһим. Ә моның өчен белем бирү практикага юнәлдерелгән булырга тиеш, һәр дәреснең яки дәрестән тыш чараның эчтәлеге дә шуңа йөз тотуы зарур.

Ахыргы нәтиҗәләр төбәк икътисадының кадрларга булган ихтыяҗын тәэмин итүгә бәйле булырга тиеш. Төбәк һәм муниципаль хакимият органнарының, төрле баскычлардагы мәгариф оешмаларының, педагогик һәм ата-аналар берләшмәләренең тыгыз хезмәттәшлеге әлеге нәтиҗәләргә ирешүнең нигезе булып тора. Безнең көчебез, барыбыз өчен уртак уңыш формуласы нәкъ менә шундый бердәмлектә.

5 «Б» СЫЙНЫФЫНДАГЫ ИЛОН МАСКЛАР, ЯКИ «МӘКТӘП БИЗНЕС-СТАРТЫ» ПРОЕКТЫНЫҢ ФАЙДАСЫ НИДӘ?

Наилә Хәйретдинова

Кайсы эшкуарның – өчле капчыгыныңмы, әллә инде мәктәпне гел бишлегә генә тәмамлаучыныңмы – уңышлырак булуы инде риторик сорауга әйләнә бара. Дөрес җавап юк моңа, чөнки бу үзгә фикерли белүгә һәм сәләтләргә бәйле, алар исә географиядән яки рус теленнән белемле булуыңнан гына тормый һәм һәркемгә дә бирелми. Ә менә эшкуарлык куәсенә ия балаларны кечкенәдән үк ачыкласаң ничегрәк икән? Татарстанда республика Рәисе Рөстәм Миңнеханов күрсәтмәсе буенча «Мәктәп бизнес-стартлары» проекты эшли. Аның стратегик бурычы – бизнес-лидерларның яңа буынын тәрбияләү. Тыңдашсез проект хакында аның җитәкчесе **Елена Тихонова** сөйли:

– Эшкуарларга ихтыяҗ теләсә кайсы дәүләттә бар, чөнки нәкъ менә алар икътисадны һәм техник прогрессны тәрәккый итә, камилләштерә. Балаларга эшкуарлык нигезләрен мәктәптә үк төшендерү юнәлешендә Татарстанда инде күптәннән эшлиләр. Әмма без гаммәви проектны чын-чынлап гамәлгә кертү белән хәзер генә шөгыльләнә башладык, ул бик күп баланы, шул исәптән республика авылларындагы һәм кечкенә шәһәрләрендәгеләрне дә колачлаячак.

Әлбәттә, бу бөтен бала да шундук яки киләчәктә эшкуар була дигән сүз түгел. Әмма аларга эшкуар һөнәре турында аңлату, хосусый бизнеска аңлы мөнәсәбәт тәрбияләү, бизнесның төп терминологиясенә төшенергә ярдәм итү – катлаулы бурыч. «Мәктәп бизнес-стартлары» программасын ТР Икътисад министрлыгы белән ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы оештыра. Программа ике илкүләм проект химаясендә тормышка ашырыла. Беренчесе – максаты бизнесның оештырылуыннан башлап, аның киңәюенә һәм экспортка чыгарылуына кадәр булган барлык этапларында ярдәм итүгә юнәлтелгән «Кече һәм урта эшкуарлык» проекты, икенчесе – «Замана мәктәбе», ул, баланың кайда яшәвенә карамастан, аңа заманча таләпләргә җавап бирә торган шартларда сыйфатлы гомуми белем бирү мөмкинлеген булдыруга йөз тота.

Программаны эшләтеп җибәрү өчен, иң әүвәл аны мәктәп тормышына җайларга кирәк иде. ТР Мәгарифне үстерү институты эшләгән методологияне беренче чиратта педагоглар өйрәнде. Мәктәпләрдә эшкуарлыкка өйрәтүче махсус педагоглар юк, шунлыктан, кагыйдә буларак, проектта энергиясе, вакыты һәм – иң мөһиме – балалар белән өстәмә шөгыльләнергә теләге булган төрле фән укытучылары катнаша.

Былтыр проектта республиканың 12 мең баласы катнашты, быел исә эшкуарлык күнекмәләрен алган балалар саны тагын 11 меңгә

«Мәктәп бизнес-стартлары» проектының матбугат хезмәте фотолары. РЕКЛАМА

ишәйде. Баштарак бу сайлап алынган мәктәпләр генә булса, быел инде проектка гади мәктәпләр дә кушылды. Иң мөһиме шул: нәкъ менә Татарстан Рәисе куйган бурыч тормышка ашырыла – эшкуарлыкка кечкенә шәһәрләр һәм авыл балалары җәлеп ителә. Моны күрергә кирәк – әлеге балалар бик актив һәм һәр яңа нәрсәне шундук үзләштерә бара, тема алар өчен бик кызыклы.

2023 елның октябрендә мәктәп бизнес-стартының беренче этабы төгәлләнде, анда республиканың 28 районыннан 11,1 мең бала катнашты. Көн саен Татарстан районнарына һәркайсы бер тренердан һәм дүрт тьютордан торган ун бригада барды. Әлеге бригадалар дүрт сәгатьлек эшлекле уеннар үткәрде, анда балаларга эшкуарлык һөнәренең асылы аңлатылды. Кайберәүләр өчен бу инде хәзер үк файдалы була ала, чөнки Россиядә 14 яше тулучылар үзмәшгуль эшкуар булып теркәлә ала. Кемгәдер исә бу белем киләчәктә кирәк булачак әле.

Тагын бер тапкыр кабатлап әйтәм, киләчәктә бөтен бала да эшкуар булмаячак, әлбәттә. Әмма һәркайсы һичшиксез әлеге һөнәрне ихтирам итә башлаячак һәм эшкуарлар командасында тирән белемле нык буынга әйләнәчәк.

Программада 14–16 яшьлекләр катнашканга, беренче этаптагы эшлекле уен вакытында ук без эшкуарлык миссиясенә игътибар бирәбез. Үз эшең аша дөньяны үзгәртү, халыкны – эш, ә үз авылың яки калаңны – сыйфатлы ризык һәм хезмәт белән тәэмин итү зарурлыгы хакында сөйлибез.

Икенче этапка нибары 600 кеше үтә. Бу классик 5–7% – безнең планетабызда эшкуарлар саны нәкъ шулкадәр. Проектта чыннан да сәләте булучылар һәм хосусый бизнес темасы белән кызыксына башлаучылар гына кала. Шулай ук мәктәпнең һәм ата-аналарның кызыксынучанлыгы да исәпкә алына – аларга уку елы дәвамында бергәләп тырышырга кирәк булачак бит.

«Бизнес-проектлаштыру» дип аталган икенче этапта инде укучылар чын эшкуарлар янында өч көнлек практика үтә. Нәтиҗәдә үсмерләр үзләренең бизнес-проектларын ачыклый. Инде субординацияле һәм вазыйфалар бүленгән команда формалаша – кемдер продуктны булдыру, кемдер – рекламалау, кемдер сату өчен җавап бирә, кемдер исә лидер була.

Декабрьдә Яңа ел хәйрия ярминкәсендә исә яшь эшкуарлар үзләренең көндәшләре һәм продуктларын кулланучылар белән очраша. Ярминкә Яңа ел алдыннан КидСпейс балалар шәһәрчегенең бөтен параметрларга туры килгән мәйданчыгында уздырыла. Проектта катнашучылар республиканың төрле почмакларыннан менә дигән продукция алып килә, аны арзан бәядән сатып алып була.

Шунысы сөендерә: яшь бизнесменнар җитештерү компанияләре генә булдырып калмый, хезмәт күрсәтү юнәлешендә дә эшли. Мәсәлән, мәктәптә клининг компаниясе яки беренче сыйныф укучыларына эшләргә, дәрес әзерләргә булышу компаниясе. Узган ел финалга чыккан бизнес-команда исә төрле фәннәр буенча белем бирү квестлары эшләгән иде.

Дөресен әйткәндә, мин бик горурланам – безнең проектта «арзанга алып кыйммәткәрәк сат» сериясеннән булган бер генә компания дә юк, без яшүсмерләрне иҗади бизнеска рухландырабыз. Моннан тыш, балалар инде проектның беренче көннәреннән үк эшкуарга хәйриячелек белән шөгыльләнүнең никадәр мөһим икәнлеген яхшы аңлый – быелтыр мәктәп ярминкәсендә сатудан кергән акчаның яртысы диярлек (40 мең сум тирәсе) яшьтәшләре булган бер кызга инвалид арбасы алу өчен ярдәм фондына тапшырылды.

Февраль башындагы соңгы этап – бизнес-кейслар чемпионатында укучылар кабат чын эшкуарлар белән очраша. Алар каршына чын бурычлар куела. Катнашучылар аны тикшерергә һәм проблеманы оптималь хәл итү юлларын күрсәтергә тиеш була. Мәсәлән, менюлары якынча бертөрле булган янәшә ике ресторанда клиентлар санының нигә шулай күпкә аерылуын ачыклау һәм тиңдәшсез сәүдә тәкъдиме ясау. Яисә билгеле бер җитештерүдә кадрларның еш алмашыну сәбәпләрен ачыклау һәм моннан котылу юлын табу.

Шул рәвешле, сентябрьдә укый башлап, ноябрьдә бизнес ачкан командалар март-апрельдә инде ниндидер күрсәткечләргә ирешә, алар инде шактый юл үтә, хаталарын таба һәм төзәтә, яңа офыклар билгели. Кайберләре хәтта үз бизнесы өчен инвесторлар да таба. Мәсәлән, былтыр мәгълүм бер компания мәктәп командасына җимеш-яшелчә чипслары җитештерү өчен җиһазлар бүләк итте.

Күргәнегезчә, проект шактый җитди. Проектның финалына 120 укучы сайлап алына, 30 кеше җиңә – барлыгы өч мәктәп командасы, өч бизнес-компания. Аларны искиткеч бүләк көтә.

Былтыр бу Мәскәүгә ике көнлек сәяхәт иде. Алар «Сколково» технопаркында булды, Горький исемендәге киностудиядә чын профессионаллардан реклама төшерергә өйрәнде.

Дөресен әйткәндә, бу проектта җиңелүчеләр юк һәм була да алмый – һәр катнашучы үз эшен ачу өчен җитәрлек белем туплап кала, аннан ничек файдалануы исә аның үзеннән генә торачак. Ике елда 23 мең яшүсмер эшкуарлык күнекмәләрен үзләштерде, алардан файдаланырга өйрәнде, киләчәктә алар ил иминлеге өчен хезмәт итүче гражданнар булырлар.

ТР Рәисенең стратегик яктан көчле карары һәм ике министрлык белән хосусый бизнес синергиясе республиканың көчле позицияле, финанс грамотасына һәм эшкуарлык күнекмәләренә ия яңа гражданнарын тәрбияләү мөмкинлеген бирә. Нәтиҗәдә бу һәркемгә дә файдалы булачак.

редакция кухнясы

ЧЫН ЧАЯННАН НОЯБРЬ ДЕСЕРТЫ

Татьяна Вафина

Салкын ноябрьдә «Татарстан»ның «Редакция кухнясы»на эссе яратучан Чаянны нинди җилләр ташлагандыр, инде беркем дә хәтерләми. Ә менә ул Чаянның бик сөйкемле-чибәр һәм уңган ханым булып чыгуын һәркем хәтерләп калды. Чөнки әлеге Чаян «Татарстан» моңарчы беркайчан да ишетмәгән-күрмәгән-татымаган десерт әзерләп шаккатырды.

КИРӘК БУЛАЧАК:

- Попкорн – 200 г
- Катык – 0,5 л
- Куертылган татлы сөт – 100 г
- Бал – 100 г
- Чикләвек – 100 г
- Җиләк (яңа өзелгәне дә, консервланганы да ярый) – уч.

КЫЗ КҮРКЕ – ЧӘЧ

Ноябрь аенда туучылар явыз, үчле, тешләк дисәләр, ышана күрмәгез тагын. Акыллы, чибәр, 2022 елда Татарстанның гүзәл ханымнары конкурсында икенче урынны яулаган Алинә Мингалиеваны исегезгә төшерегез. Бүген үреп куелган чәче генә бераз хыялыйрак кешеләргә әллә мөгезне, әллә чаян башындагы күзләрне хәтерләтә. Тик әлеге «мөгез»гә Алинә үзенең рекордлы – 1 метр да 40 сантиметрлы толымын яшергән бит! Безнең «Рапунцель» чәчен бала чагыннан бирле үстерә икән!

КҮП БАЛАЛЫ РАПУНЦЕЛЬ

Әмма Алинәгә мондый мактаулы титул матурлыгы һәм озын толымы өчен генә тәтемәгән шул – конкурс биреме буенча, аның социаль проблеманы хәл итүгә багышланган программасы иң яхшы дип табылган. Әлеге программа күптән инде аның яшәү рәвешенә әйләнгәнгә, башкаларны таныштыру да бик уңышлы килеп чыккан.

Фото: Ната Смирнова



1
– Минем 603 балам бар, – ди, күзен дә йоммыйча, Татарстанның гүзәл ханымнары конкурсында икенче урынны яулаган Алинә.

2
Алинәнең чәче озын – 1 метр да 40 сантиметр! Безнең «Рапунцель» чәчен бала чагыннан бирле үстерә икән!

– Нинди программа соң бу?

Өстәлгә десерт өчен кирәкле ингредиентларны бушата-бушата, Алинә безгә ничек итеп үзенең... күп балалыга әйләнүе хакында сөйли.

– Минем 603 балам бар, – ди, күзен дә йоммыйча, Татарстанның гүзәл ханымнары конкурсында икенче урынны яулаган Алинә.

Шаккаткан «Татарстан» әлеге мәгълүматны аңларга тырышкан арада үзе үк төшендерә дә башлый:

– Үземнең өч балам һәм 600е – балалар йортларыныкы. Эш шунда ки, мин ТЯГ каналында үземнең «Забери меня, мама!» дигән программамны алып барам. Без төшерү төркеме белән балалар йортларына барабыз, видеорепортажлар төшерәбез һәм, программабызда күрсәтеп, аларга яңа гаилә эзлибез. Бәләкәйләрне, сау-сәламәт сабыйларны болай да тиз арада тәрбиягә алганга, программабызда инде өлкәнрәк яшьтәге һәм үсешләрендә нindидер тайпылышлар булган балалар белән таныштырабыз.

ФАЙДАЛЫ КҮНЕКМӘЛӘР

– Тапшыруларыгыз геройларына яңа гаиләләрне еш табасызмы соң?

– Әлеге программа ярдәмендә инде балаларның 40 проценты үзләрен яраткан ата-ананы эзләп тапты. Әлегә тәрбиягә алынмаган балаларны без программабызда ашарга пешерергә, тегү, маникюр ясау кебек һөнәрләргә, төрле файдалы күнекмәләргә өйрәтәбез – балалар йортыннан чыгып киткәндә, алар мөстәкыйль тормыш алып баруга әзер булырга тиеш.

АМЕРИКА-ФРАНЦИЯ-ТАТАРСТАН...

Алинә суыткычтан катык ала.

– Катыкны башта туңдырырга, аннары исә марля белән дуршлагка куеп, эретергә кирәк. Суы аккан арада, попкорн алабыз да...

– Нindидер бик сәер ризыкка охшап тора бит әле бу: татар авылы катыгы һәм американнарның шәһәр попкорны...

– Әле тагын бал белән чикләвек тә кирәк... – дип өсти Алинә. – Кинотеатрлардагы кебек пластик попкорн түгел, бәлки файдалы десерт әзерлибез без.

Табада җылынган балга Алинә попкорнны бушата.

– Балны тулысынча сеңдереп бетергәнче болгатып торырга кирәк, – дип аңлата Алинә. – Без бу ризыкны балалар белән шактый еш әзерлибез: үземнекеләр белән дә һәм... тагын үземнекеләр белән дә. Барысына да ошый әлеге десерт. Әзерләнүе дә тиз, балаларның да хәленнән килә. Хәзер попкорнны тәлинкәгә түгел – анда ябышачак! – пергаментка бушатабыз һәм бераз суынганын көтәбез. Үзебез бу вакытта крем әзерлибез: катыкка куертыл-

ган сөт кушып болгатабыз. Менә, кабып карагыз! Француз кремыннан бернәрсәсе белән дә аерылмый!

Ә инде бер кашык какао да өстәсәң, ул шоколад төсенә керәчәк һәм тагын да хуш ислерәк булачак...

ТАТУ АШ ТАТЛЫ БУЛА

– Сез аш-су остасыдыр, мөгаен...

– Алай дип әйтсәң дә була, – дип елмая Алинә. – Чынлыкта мин журналист, һәм «Татарстан – Яңа гасыр» каналында, үз проектымнан тыш, аш-су әзерләүгә багышланган тапшыруны да алып барам.

– Аңлашылды. Димәк, журналистларның төп проблемасы – өйдә ашарга әзерләргә дә, кайчагында исә ашарга да өлгермәү – сезгә кагылмый булып чыга?

– Мин эшемдә ашарга әзерлим бит, – дип көлә ашчыбыз. – Әмма өйдә дә пешерергә яратам. Еш түгел, тик сыйфатлы итеп. Эшемә бәйле рәвештә вакыт ягы гел кысан булганга, мин аш-су әзерләүдән, балаларым, туганнарым белән аралашудан һәрвакыт бәйрәм ясарга тырышам. Ял көннәрендә күп итеп ашарга әзерлибез дә, туганнарны, һичшиксез, минем әбиемне чакырабыз. Хәтта әбиемнең туган көнен дә бездә үткәрәбез. Кая да булса ял итәргә барабыз икән – шулай ук бергә. Мин, гомумән, балалар һәм картлар белән аралашырга яратам, чөнки алар миңа ихласрак, самимирәк тоела.

Балалар йортларында тәрбияләнүчеләр өчен дә бәйрәмнәр оештырабыз. Бу вакытта минем үз балаларым да булыша.

ЕЛАУДАН ФАЙДА ЮК

– Кайчак үз ата-аналарына да кирәк булмаган балалар яныннан мәхәббәттә һәм ата-ана назында яшәгән үз сабыйларыгыз янына өйгә кайткач аеруча кыендыр... Бу трансформацияне ничек кичерәсез?

– Баштарак мин елый идем. Аннары үземне кулга алдым. Күз яшемне агызып кына мин алар өчен бернәрсә дә эшли алмаячакмын, проектым урыныннан да кузгалмаячак бит. Шунлыктан алар янына барам, аралашам, эшлим, аларны кызыксындырырга, кәефләрен күтәрергә тырышам. Үземнең балалар белән нишлим, алар белән дә шулай ук шөгыльләнәм. Асрамага алынган балаларны да күз уңыннан югалтмыйм, элемтәдә торам.

«КАДЕРЛЕМ, БЕЗНЕҢ ТАГЫН БЕР БАЛАБЫЗ БУЛАЧАК. Ә БӘЛКИ, ИКЕДЕР...»

– Балалар йортындагы сабыйларны тәрбиягә алу хакында уйланганыгыз булмадымы?

3

– Менә, кабып карагыз! Француз кремыннан бернәрсәсе белән дә аерылмый!

4

– Чынлыкта мин журналист, һәм ТЯГ каналында, үз проектымнан тыш, аш-су әзерләүгә багышланган тапшыруны да алып барам.

1 Сөзәбез

2 Сыгабыз

3 Җылытабыз

4 Салабыз

5 Өстибез

6 Кыздырабыз

7 Бушатабыз

8 Кушабыз

9 Буйыйбыз

10 Бизибез

– Даими уйланам. Моңа әзерләнәм дә. Хәзер минем ике балам пубертат чорында. Мин үзем дә нигездә шул яшьтәге балалар белән эшлим. Шунлыктан, әгәр нәкъ менә хәзер балалар йортыннан уллыкка йә кызлыкка алсам, балалар арасында ниндидер кыенлыклар килеп чыгачагын яхшы беләм.

Балалар бит тиз үсеп җитә һәм туган ояларыннан очып та китә. Ата-аналар исә үзләре генә кала. Нәкъ менә шул мәлдә: «Безнең тагын бер балабыз булачак!» – дип әйтү урынлы да инде. Ә бәлки әле, икедер дә, кем белә!

АЛЛАҺ ТӘГАЛӘ ШӘФӘГАТЕ

– Татар халкы тарихын искә төшерсәк, анда балалар йортлары булмавын беләбез... Ятим калган баланы һәрвакыт туганнары үзләре тәрбияләргә тырышкан...

– Алай гына да түгел әле, ятим баланы тәрбиягә алу бәхет саналган. Бигрәк тә авыру баланы – димәк, бу сезгә Аллаһ Тәгаләнең шәфәгате, аның оҗмахка юл күрсәтүе. Күп кенә ислам дәүләтләрендә бу хәзер дә шулай.

Әмма социаль ятимнәр бар бит, аларның ата-анасы исән, тик ниндидер сәбәпләр аркасында сабыйларын тәрбияләргә теләмиләр. Тарих шуны күрсәтә: сугышлар, революцияләр, репрессияләрдән соң тәрбиячесез калган, гарип балалар саны бик ишәя. Бу вакытта дәүләт кайгыртуыннан башка бернишләп тә булмый. Әйе, мин дә казна йортының гаиләне алыштырмавын яхшы беләм. Шуңа да анда килеп эләккән балаларга ничек тә яңа гаилә табарга тырышырга кирәк.

Мәсәлән, менә бу сабыйларга:

Артём, 10 яшь.

Кассандра, 6 яшь.

Ярослав, 7 яшь.



ЯРДӘМ ҮЗӘГЕ

– Сезнең Лаеш районы Олы Кабан авыл җирлегеннән депутат булуыгызны беләм. Бу сезгә эшегездә булышамы?

– Депутатлык кына түгел, минем икенче һөнәрем дә булыша. Минем икенче югары белемем – халыкара гаилә психологы-сексологы.

– Болар бер-берсе белән ничек яраша соң? Әллә..?

– Барысы да яраша. Мин балачакта җәбер күргән хатын-кызлар белән эшлим. Чынлыкта, бу җитди проблема. Һәм аны хәл итәргә кирәк. Депутат буларак, мондый кешеләр өчен ярдәм үзәге булдырырга телим. Бу ниятем дә тормышка ашар, дип өметләнәм.

ТӘМЛЕ БУЛСЫН!

Әзер ризыкны Алинә җиләк һәм чикләвек белән бизи – бик матур һәм тәмле килеп чыга.

АПАС ЯКТАШЛЫК ҖӘМГЫЯТЕ: 30 ЕЛЛЫК ТАРИХ

Руфия Фазылова

Татарстанда якташлык җәмгыятьләре шактый. Казанда гына да алар – 38. Шулар арасында аеруча актив эшләүчеләре бар. Апас якташлык җәмгыяте әнә шундыйларның берсе. Күптән түгел ул үзенең 30 еллык юбилеен зурлап билгеләп үтте. Казанның Ленин исемендәге мәдәният сарае шыгрым тулы иде.

Фотолар Нурислам Исмагыйлевтән алынды

АЛДЫНГЫЛАР

Апас якташлык җәмгыятен оештыру идеясен үз чорының атаклы журналисты Хәлим Гайнуллин күтәреп чыга. Туган җире өчен җан атучы берничә ир-егет бу ниятне хуплый. Тормышта үз урыннарын тапкан Апас егет-кызлары әнә шул рәвешле Казанда бер оешмага берләшә. Утыз ел эчендә җәмгыять алты тапкыр җитәкчесен алмаштыра. Бүген аны РФ Дәүләт Думасы депутаты Марат Габделхәй улы Нуриев җитәкли.

Апас якташлык җәмгыяте актив эшли. Чарага кунак итеп чакырылган «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Советы» Ассоциациясе рәисе Әгъзам Самат улы Гобәйдуллин да шуны билгеләп үтте:

– Соңгы елларда якташлык җәмгыятьләре арасында республикакүләм бәйге уза. Һәм апаслылар анда гел 3 нче яки 2 нче урыннарны алып килә. Миңа калса, беренче урынны алырлыклары да бар. Чынлап та алар бик тырышып эшли. Алга таба да зур уңышлар телим, – диде ул.

ҖЫЕЛЫР УРЫН БАР...

Шунысын әйтергә кирәктер: якташлык җәмгыятьләре арасында бары тик апаслыларның гына үз офислары бар. Анда ай саен кабул итү көннәре оештырыла. Төрле һөнәр ияләре – юрист, табиб, журналист һәм башкалар якташларының теге яки бу сорауларына җавап бирәләр.

ШӘХЕСЛӘР ҮСТЕРГӘН РАЙОН

Апас татар дөньясына зур шәхесләр биргән район. Композитор Сара Садыйкова, опера җырчылары Фәхри Насретдинов, Бану Вәлиева, актриса Асия Хәйруллина, Татарстанның халык шагыйре Шәүкәт Га-

лиев, бертуган рәссамнар Фәһим һәм Фариз Фәсхетдиновлар, хәйрияче Әсгать Галимҗанов – бу атаклы якташларыбызның берничәсе генә әле. Якташлык җәмгыяте аларның каберләрен барлап, карап торуда үз өлешен кертә.

ХӨРМӘТ КҮРСӘТҮ

Инде Казанның Ленин исемендәге мәдәният сараенда узган чарага әйләнеп кайтыйк. Әлеге күркәм чарада иң актив якташларны бүләкләделәр. Апас якташлык җәмгыятенең өч хөрмәтле ветераны ТР Премьер-министры Алексей Песошинның Рәхмәт хатына ия булды. Шулай ук якташлык эшенә иң күп көч кертүчеләр дә искә алынды. Берәүләр РФ Дәүләт Думасы депутаты Марат Нуриевтан, икенчеләр «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Советы» Ассоциациясе рәисе Әгъзам Гобәйдуллиннан Рәхмәт хатлары алды. Шулай ук Апас муниципаль район башлыгы Айрат Җиһаншин да, хөрмәтләп, Рәхмәт хатлары тапшырды.

– Соңгы елларда якташлык җәмгыятьләре арасында республикакүләм бәйге уза, – дип билгеләп үтте «Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре Советы» Ассоциациясе рәисе Әгъзам Самат улы Гобәйдуллин. – һәм апаслылар анда гел 3 нче яки 2 нче урыннарны алып килә. Миңа калса, беренче урынны алырлыклары да бар. Чынлап та алар бик тырышып эшли. Алга таба да зур уңышлар телим.

ЯШЛӘР БЕЛӘН БЕРГӘ БУЛУ

Кичәдә якташлык җәмгыяте эшендә актив катнашкан кешеләр белән беррәттән, яшьләр дә зурланды. Эш шунда ки, якташлык җәмгыяте Апас үсмерләре, яшьләре өчен ике конкурс оештырды. Аның берсе туган якка багышлап язылган шигырь һәм хикәяләр, икенчесе шәҗәрәләр бәйгесе иде. Җиңүчеләргә акчалата бүләкләр һәм дипломнар тапшырылды. ТРнда Милли мәдәниятләр һәм гореф-гадәтләр елына багышланган иҗат бәйгесенең гомуми приз фонды – 78 мең сум, ә шәҗәрәләр конкурсыныкы 54 мең сум иде. Әнисе ягыннан егерме ике буынны барлаган Фәнзия Хәлиуллина шәҗәрәләр конкурсында беренче урынга лаек булды.

Апас якташлык җәмгыятенең иң актив вәкилләренә ТР Премьер-министры Алексей Песошин, РФ Дәүләт Думасы депутаты Марат Нуриев, Ассоциация рәисе Әгъзам Гобәйдуллин, шулай ук Апас муниципаль районы башлыгы Айрат Җиһаншиннан Рәхмәт хатлары тапшырылды.

Фойеда ярминкә гөрләде: Апаста үстерелгән, апасларча пешерелгән тәм-томнарны халык яратып алды. Якташлар җырлап-биеп, рәхәтләнеп күңел ачты. Мондый очрашулар янә булсын дип, якташлар күтәренке кәеф белән өйләренә таралышты.

– Яшьләр арасында мондый бәйгеләр оештыру күркәм традициягә әйләнде, – диде Марат Нуриев. – Гомумән, якташлык җәмгыяте әдәбият, сәнгатькә зур игътибар бирә. 2019 елда «Гасырлар сагындагы манаралар. Апас районы мәчетләре» китабын эшләдек. Анда бөтен район мәчетләренең тарихы теркәлде. Ул китаплар Казан, Мәскәү, Санкт-Петербург, Хабаровск шәһәрләренә, АКШ, Берләшкән Гарәп Әмирлекләренә кадәр барып җитте. Шулай ук без районда узган бер генә чарадан да читтә калмыйбыз: Сабан туе, Уңыш бәйрәме, Җиңү көне, 1 сентябрь, 8 март, Яңа ел бәйрәмнәре... Кыр батырларын, алдынгы терлекчеләрне тәбрикләү, өлкәннәр, сугыш һәм тыл ветераннарының хәлен белү, балаларны беренче сыйныфка озату һ.б. Кайчандыр үзе әз ярып башлаган оешмага хәзер, тәҗрибә уртаклашырга дип, башка районнардан да киләләр...

Казанның Ленин исемендәге мәдәният сарае ул көнне гөрләп торды. Мондый очрашулар янә булсын дип, якташлар күтәренке кәеф белән өйләренә таралышты.

КЕШЕЛӘР ҺӘМ АЮЛАР

Евгения Чеснокова

Сентябрь көннәренең берсендә Кукмара районы Оштырма Юмья авылы янында аю катнашында юл һәлакәте була. «Кинәт каршыга кап-кара бер нәрсә килеп чыкты да машинага килеп бәрелде – мин тормозга бастым, – дип сөйли зыян күрүче шофер. – Машинам юлга аркылы борылды. Үзем дә, машинам да шок хәлендә...»

Соңгы вакытта Татарстанда кешеләр һәм аюларның юллары еш кисешә башлады.

«Лада Калина»ны йөртүче аварияда зыян күрмәгән, машинасы исә шактый җимерелгән. Аюның язмышы исә аянычрак булып чыккан: ул машинага бәрелүдән җан тәслим кылган. Татарстанда көрән аюлар Кызыл китапка кертелгән, һәм аны үтергән өчен (хәтта ихтыярсыздан булса да) штраф каралган...



БЕЗ СӘЕР ОЧРАШТЫК...

Аю булса инде...
Ни дисәң дә, сасы көзән түгел...
«Обыкновенное чудо», Е.Шварц

«Ашыгыч хәбәр! Мишә елгасы буенда, Зимняя Горка, Бима авыллары тирәсендә, бүген бик зур аю күргәннәр. Уяу булыгыз!» Күптән түгел Лаеш районы коттедж бистәләренең берсендә мессенджерларда әнә шундый игълан пәйда була.

«Кама елгасында балык тотканда аю күрдек. Балык Бистәсе районы, Николаевка авылы янында. Машина кычкырткангa игътибар бирмәде». Бу игъланны исә җәй азагында социаль челтәрләрдә еш күрергә мөмкин иде.

«Республикабызда язгы кыр эшләренең торышын карарга дип очтым – юлда аю очраттым!» Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов апрельдә үзенең телеграм-каналында әнә шундый пост һәм сүзләренә дәлил буларак видео урнаштырган иде.

– Аю белән очрашу – хәзер безнең өчен гадәти хәл инде, – дип сөйләде Биоресурслар буенча республика дәүләт комитетының Балык Бистәсе буенча районара бүлеге башлыгы Айнур Хәбибуллин. – Без даими рәвештә урманнарга чыгабыз һәм соңгы елларда аюларны яки аларның эзләрен еш күрә башладык. Төнлә тепловизор белән барганда аюларны очратырга мөмкин, чөнки төнлә алар кукуруз, солы чәчелгән кыр-

Фото: tatar-inform.ru, Виталий Николаенко, Евгения Чеснокова, Александр Малёв архивыннан, ТР буенча ЭЭМ ЮХИДИ Идарәсеннән алынды.

ларга азык эзләргә чыга... Карау-тикшерү рейдларына корал белән барабыз, әлбәттә. Гадәттә, үзем белән этне тә ияртәм. Аюлар оста яшеренә белә, һич көтмәгәндә-уйламаганда, аның белән күзгә-күз очрашасы килми. Эт исә хайванны сизеп ала да, өрә башлый, шул вакытта аю, гадәттә, читкә китә. Гомумән алганда, аюлар кешеләр белән очрашмаска тырыша, контактка бармый.

...СӘЕР АЕРЫЛЫШЫРБЫЗ ДА

Аю... Әйтүе генә кызык.
Минем исә бер яклаучым да юк.
«Обыкновенное чудо», Е.Шварц

Билгеле, төрле очраклар була. Биоресурслар буенча дәүләт комитетының Хайваннар һәм үсемлекләр дөньясын саклау идарәсе башлыгы Ринат Чиспияков әйтүенчә, беренче чиратта балалары белән бергә очраган ана аю куркыныч тудырырга мөмкин.

– Бервакыт дача күршеләрем Биектау районы Гәр авылы янындагы урманга йөрергә чыга, – дип күптән түгел булган бер вакыйга турында сөйләде журналист Александр Латышев. – Сукмакта ике аю баласын күрәләр. Озак та үтми, агачлар арасыннан ана аю килеп чыга. Һәм, балаларына ул-бу булмагае дип, кешеләргә ташлана. Бәхетләренә, үзләре белән спаниель була. Эт өрә-өрә аюга ташлана, тәпиләренә ябышырга тырыша. Ә кешеләр шул арада качып өлгерә. Спаниель үзе дә елгыр булып чыга – аю тырнакларыннан оста котыла.

Латышев үзе дә, гөмбә җыярга урманга баргач, аю очрата (сүз уңаеннан, бу юлы да җанвар урман юлында очрый, Александр машина белән чыккан була, бәхеткә, исәнимин котыла). Әлеге хәл шулай ук дачасы урнашкан авыл янында була.

Боларны ничек аңлатырга? Татарстанда Кызыл китапка кертелгән җанвар безгә ник көннән-көн ешрак очрый һәм ни өчен ул, уяулыгын югалтып, авыллар, кешеләр тирәсендә чуала?

– Аю кеше янына килми, бәлки, кеше үзе аю янына барадыр? – ди Ринат Чиспияков. – Без яшәү даирәсен һаман киңәйтәбез, элек кыргый җәнлек-җанвар гына яшәгән җирләрдә йортлар төзибез.

Юлда булган хәлне генә искә төшерик. Бүген асфальт җәелгән трасса урынында элек җәнлекләрнең юллары узган булуы ихтимал. Алар бу сукмаклардан әллә ничә гасырлар йөргәндер, бәлки. Инстинкт аларны кабат шушы юлга чыгара, зур тизлек белән өсләренә ыжгырып килгән куркыныч «тимер җанварны» күреп, алар куркып, югалып кала. Ешайган сәер очрашуларны шулай аңлатыргадыр, бәлки...

НИ САКЛАСАК, ШУҢА ИЯБЕЗ

Ә аюның көче? –
– Хайванны котыртмыйлар аны.
«Обыкновенное чудо», Е.Шварц

– 1995 елда Татарстанда күрән аю Кызыл китапка теркәлгән вакытта бөтен республикада нибары алты-сигез аю бар иде, – дип искә ала Ринат Чиспияков. – Бездә урманнар чагыштырмача күп түгел, аю исә урманда яши... Ләкин Россиянең башка төбәкләрендә, мәсәлән, аюлар шактый күп иде, аларны саклау чаралары да күрелмәде, ягъни аларны аулау да тыелмаган иде.

– Шул ук вакытта, – дип сүзен дәвам итә Биоресурслар буенча дәүләт комитеты хезмәткәре, – аю – хәйләкәр һәм сак хайван. Шуңа күрә ауларга рөхсәт ителгән лимиттан нибары өчтән бер өлешен генә атып үтерү мөмкин. Нәтиҗә буларак, соңгы ун елда илдә аюлар саны бер ярым тапкырга артты. Илдә арткан икән, бездә дә үрчегән дигән сүз. Татарстан урманнарга бай Киров өлкәсе, Мари Эл, Удмуртия белән чиктәш... Кукмарада булган хәлне генә искә төшерсәк, анда Киров өлкәсе урманнары якын.

– Аю – бик акыллы хайван, – ди Казан зоопаркының зооветеринария буенча директор урынбасары, биология фәннәре кандидаты Александр Малёв. – Кызыл китап турында белмәсә дә, кайда аучы мылтыгыннан җан тәслим кылу ихтималы булуын, кайда исә бернидән курыкмыйча яшәү мөмкинлеге барлыгын бик әйбәт чамалый. Куркынычсызрак урыннарга юл тотулары табигый. Өстәвенә, олы яшьтәге аюга яшәү өчен шактый зур мәйдан кирәк, икенче бер олы аюны ул бу җиргә

Әлегә Кызыл китапка кертелгән җанвар (дөресрәге, аның карачкысы) ТР Биоресурслар буенча республика дәүләт комитетының холлында тора.

кертмәячәк. Нәтиҗәдә, аулаучы юк, популяция үсә (тыныч шартларда ана аю ике-өч ел саен ике-өч бала тудыра ала), һәм яшьрәк аюлар яңа урманнар эзләп китә.

Өстәвенә, Татарстанда авыл хуҗалыгы тармагы алга киткән. Димәк, талымсыз аю халкына ризык һәрвакыт бар (югарыда билгеләп үткәнчә, аю кукуруз, солы белән сыйланырга ярата). Кешегә якынаю димәктән исә...

– Яңа йортлар төзү генә җитмәгән, кешеләр еш кына әле генә пәйда булган бистәләр янында рөхсәтсез чүп өемнәре калдыра, – ди Ринат Чиспияков. – Аюларга чүплектә сыйланып алу тыләүсез ашханәгә кереп чыгу кебек җайлы һәм кулай.

Биоресурслар буенча комитет белгечләренең исәпләвенә караганда, хәзер республикабызда 70 кә якын аю бар. Аларның бер өлеше бездә даими яши, калганнары күрше төбәкләрдән килгән. Әмма исәпләү методикасы камил түгел, ди Чиспияков. Хайваннар санын кыш көнне тәпи эзләре карда ап-ачык күренгән чакта исәпкә алу хәерле. Ләкин кыш көне аю халкы ояларында тәмләп йоклый, шуңа күрә сан алганда башка күрсәткечләргә: яңгыр явып үткәч, юлда – тәпи, агач кайрыларында тырнак эзләренә, җимерелгән умарталыкларга, кырмыска ояларына, кырларда тапталган уңышка игътибар итәргә туры килә...

Ничек кенә булмасын, Кызыл китапка кертелгән аюларның хәзер Татарстанда шактый артуы күзәтелә. Комитетта көрән аюны республикабызда аеруча сакланырга тиешле хайваннар исемлегеннән төшереп калдыру турында дәлилләп язылган таныклык әзерләгәннәр. Ринат Чиспияков әйтүенә караганда, карар ярты ел дәвамында кабул ителергә тиеш.

БӨТЕНЛӘЙ КУРКУ ХИСЕН ЮГАЛТКАНЧЫ...

Йөзенче аюны үтерергә телисезме? –
– Кызыктырырлык бу...
«Обыкновенное чудо», Е.Шварц

Аюны Кызыл китаптан төшереп калдыралар икән, аны аулау рөхсәт ителәчәк. Хайваннарны яклаучылар ничек кенә каршы чыкса да, белгечләр фикеренчә, аюлар популяциясен тәртипкә китерүнең бүтән чарасы юк.

– Аюлар санын тикшереп, тәртипкә китереп тормасак, алар бервакыт авыллар буенча йөри башлаячак, сан арта, мәйдан кысыла, бүтән барыр урыннары юк, – дип аңлата Александр Малёв. – Аулау рөхсәт ителгәч тә, кулыңа мылтык алып урманга чыгасың да, бөтен аюларны кырып бетерәсең, дигән сүз түгел бит әле. Лицензияләр билгеле бер күләмдә генә бирелә, егерьләр кагыйдәләр сагында тора. Әмма урман хуҗасы булса да, аю кешедән куркырга тиеш. Курку хисен югалта икән, аю кешене корбан, азык дип белә башлаячак.

Малёв үзе дә кайчандыр аю белән чак кына күзгә-күз очрашмый калган. 1979 елда ветеринария институтын тәмамлагач, Башкортостанның Авыл хуҗалыгы министрлыгында эшләгәндә була бу хәл. Бер көнне урман сукмагы буйлап бер авылдан биш километр чамасы ераклыктагы икенчесенә барганда, Александр яңгырдан соң йомшарган туфракта фуражкасы зурлыгындагы аю эзен күрә. Тайгада кычкыру, ярдәмгә чакыру файдасыз, аюдан качу да мәгънәсез (ул – бик җитез хайван).

– Үзем белән пәке бар иде. Аны ачтым да юлымны дәвам иттем. Иплән кенә барам, ашыкмыйм, – дип искә төшереп сөйли Малёв. – Күпмедер вакыттан соң тагын бер эз күренде... Минем белән бер тирәдә бара, махсус эзләр калдыра, димәк... Шул ук вакытта үзе күренми, зур булса да, аю, тавыш-тын чыгармыйча, шыпырт кына йөри – агачлар артыннан янәшәдә

генә үтеп китсә, күрми дә калачаксыз. Шулай итеп атлый-атлый кирәкле җиргә барып җиттем. Куркуга бирелеп йөгерсәм, ул мине, куып тотып, ботарлап аткан булыр иде, дип уйлыйм. Шуннан соң аю халкына хөрмәтем артты, бу урман хуҗасының ике аяклы затлар белән күрше булып яшәүгә каршы түгеллеген, бер кирәксезгә кешегә ташланмаячагын аңладым.

Казан зоопаркында Малёв нәкъ менә аюлар белән эшли. Һәм үз вакытында алар көрән аюлар буенча Россиядә зур белгеч Валентин Пажетнов белән зоопаркларда

дөньяга килгән аю балаларын табигый шартларга күчерү методикасын эшлиләр. Аулау рөхсәт ителгән төбәкләрдә бу популяцияне тиешле тәртиптә тоту өчен шәп тәҗрибә булып чыга ул.

ҖЫР КАЙДА ДА ЯРДӘМГӘ КИЛӘ

Урманнан барам, карасам: аю.
Маңгае зур, күзләре акыллы.
Ошады күңелемә...

«Обыкновенное чудо», Е.Шварц

– Безнең урманнарда көрән аюның Европа төре яши, – дип сөйли Александр Малёв. – Гадәттә, алар агрессив түгел. Урал артыннан Себер төренә караган берәр аю кунакка килсә исә, эшләр яман, куак артыннан карап кына калмас, өстеңә ташланып, ботарлап атуы да бар. Һәр очракта да, урманга барырга җыенганда, аның хуҗасы белән очрашу ихтималын онытырга ярамый, һәм бик уяу булу сорала.

– Гомумән алганда, аю йөри икән, урман сәламәт дигән сүз, – дип, сөйләгәннәренә нәтиҗә ясый Александр Малёв. – Бу хайван кая туры килсә шунда яшәми. Республикабызда экология әйбәт, димәк!

Гөмбә җыючыларга белгечләр куе чытырманлыкларга керергә киңәш итми. Әмма аюны кеше аягы басмаган урман эчләрендә генә түгел, авыллар янында да очратырга мөмкин, шуңа күрә урманда, гомумән, ялгыз йөрүдән тыелырга кирәк.

– Урманга җиләк, гөмбә, чикләвек җыярга җыйнаулашып барганда исә мөмкин кадәр ешрак һәм кычкырыбрак сөйләшергә кирәк, – дип киңәш итә Ринат Чиспияков.

– Кешедән курку аюның канына сеңгән, – ди Александр Малёв. – Бервакыт Хабаровск краенда шундый бер хәл була. Пенсиядәге әби, урманга мүк җиләге җыярга баргач, аю белән очраша һәм берничә сәгать туктамыйча «улый». Аю улаучы билгесез зат янына якын килергә кыймый, әбинең тавышын ишетеп исә, тирәк-як авыллардан кешеләр аны коткарырга килә. Шуңа күрә, ул-бу була калса, кычкырып-кычкырып җырлап карагыз, зыяны булмас...

Алда әйткәнебезчә, аю күргәндә йөгерү яисә качу файдасыз. Җырлый-җырлый кулларны өскә күтәрергә була, шулай итеп аю күзенә кеше зуррак күренергә мөмкин, ул исә үзеннән зурлар белән булышмаска тырыша. Тулаем алганда, аюлар үзләре дә кешеләр белән мөгамәләгә керергә атлыгып тормый, табигатькә чыкканда сезне шул коткарса гына. Тагын бер мәртәбә искәртеп узабыз: аю баласы күрсәгез, сыйпый, ярата күрмәгез, бу сезгә кинодагы Паддингтон яки мультфильмдагы Винни Пух түгел, тизрәк бу урыннан табан ялтыратыгыз!

– Гомумән алганда, аю йөри икән, урман сәламәт дигән сүз, – дип, сөйләгәннәренә шатланып нәтиҗә ясый Александр Малёв. – Бу хайван кая туры килсә шунда яшәми. Республикабызда экология әйбәт, димәк!



www.protatarstan.ru
ТАТАРСТАН
Татар авыллары
Сайттагы яңалык
Яңалыклар
Финансовая грамотность

Реклама 16+

мәңгелек кыйммәтләр /

игелекле эшләр

акыллы гамәлләр

Бу санда тәкъдим итәбез:

Сугышта сигез баласын югалткан Фатыйха Әхмәдиевага һәйкәлне **кем** куяр

Әхмәтгәрәй Хәсәни **нинди** мирас калдырган

Кем ул «татарның Островские»

Ташбилгедә **ни өчен** «Татарстан» журналын яратып укыйлар

Быел «Каз өмәсе» **кайда** үтте

БЕР АНАНЫҢ СИГЕЗ УЛЫ...

Руфия Фазылова

Бөек Ватан сугышы турындагы иң популяр җырларның берсе «Торналар» («Журавли») дип әйтсәм ялгышмамдыр. Әлеге җырның тарихы үзәк өзгеч – Төньяк Осетиянең Дзуарикау авылыннан Газдановлар гаиләсендә җиде ир-егет була. Алар барысы да бер-бер артлы фронтка китә. 1941 елда бер уллары, 1942 елда тагын ике уллары һәлак була. Бу кайгыны ана кеше күтәрә алмый, аны да җирлиләр...

Соңрак ата кешегә тагын өч улының мәрхүм булуын җиткерәләр. 1945 елда Газдановлар гаиләсенә кара мөһер сугылган җиденче хат килә. Почта ташучы бердәнбер оныгы белән яшәүче ата кешенең өенә барудан баш тарта. Нәтиҗәдә, авылның аксакаллары кара мөһер сугылган хатны илтергә үзләре бара. Бу хәбәрне ишеткәч, үсмер оныгы белән бусагада утырган ата кешенең йөрәге ярыла...

1963 елда авылда кайгылы ана һәм җиде очар кош рәвешендә һәйкәл ачыла. Әлеге фаҗигале тарихны Дагыстан шагыйре Рәсүл Гамзатов ишетеп ала. Авылга килә, һәйкәлне күрә. Һәм озакламый авар телендә «Торналар» дип аталган шигырь иҗат итә. Тиз арада аңа көй языла, җыр сүзләре исә берничә телгә тәрҗемә ителә.

Ә бит бездә дә шундый үзәк өзгеч язмышлы гаилә булган. Төньяк Осетиядә ата белән ана сугышта җиде улын югалтса, Мамадыш районы Урта Кирмән авылында яшәүче Әхмәдиевләрнең сигез баласы фронтта һәлак була...

САБЫР КАНАТ ТА СЫНА...

Сугыш афәте Әхмәдиевләрнең капкасын 1919 елның язында ук шакый – ике улларын хәрби хезмәткә алалар. Нәкъ шул чорда Нократ яры буена көнчыгыштан Колчак гаскәрләре килә. Бертуган Исмәгыйль һәм Ибраһим Фәттаховлар (малайлар әтиләре исеме белән йөри) кулларына корал ала. Егетләр, дошманга каршы көрәшеп, Себергә кадәр бара. Каты бәрелешләр вакытында Исмәгыйль һәлак була. Абыйсын чит җирдә җирләп, Ибраһим туган йортына ялгызы гына кайта. «Сиңа дип атап алган идек, абыйның төсе итеп сакларсың», – дип, Ибраһим, кечкенә яшел сандыкка салып, энисенә Коръән китабы тапшыра. Ул чагында әле ана кеше бу беренче югалтуның соңгысы түгел икәнлеген башына да китерми...

1941 елның июнь ае. Илдә булган зур үзгәрешләрдән халык азмы-күпме сулу алган вакыт. Урта Кирмән авылында «Алга» колхозы оеша, халык шунда эшли. Тугыз бала – сигез ул, бер кыз атасы Фәттах Әхмәдиевне баш тегермәнче итеп билгелиләр. Тирә-юньдә оста тукучы булып танылган Фатыйха апа да җиң сызганып эшли, башка авыл хатыннары кебек үк, кырдан кайтып керми. Әнә шулай яшәп ятканда, Бөек Ватан сугышы башлана.

Фото: Тимур Яковлев

Көн саен дистәләгән ир-ат фронтка китә. Аңлашыла ки, Әхмәдиевләрнең дә уллары бер-бер артлы сугышка чакырыла.

Авылга кара мөһер сугылган хатлар килә башлый. Август иртәсендә хат ташучы Әхмәдиевләргә дә шундый язу калдырып китә. Хатны иң беренче ата кеше – Фәттах ага укый. Шул көнне аны йөрәк өянәге тота, һәм озакламый ул бакый дөньяга күчә. Ә тугыз бала табып үстергән ана кеше исә азаккача түзә... (Ире мәрхүм булганда Фатыйха апа ике улын, бердәнбер кызын югалткан була. Кызлары Сәлимә уналты яшендә үпкә авыруыннан үлә).

Фатыйха Әхмәдиева азаккача бирешми. Дүрт ел эчендә бер-бер артлы алты улын югалта. Төпчеге Әгъмәлетдин сугыш тәмамланганда исән була. Менә шул хәбәр аның күңелен юатып, яшәргә көч бирә. Төпчегеннән килгән хатларны ул ятлаганчы укый. Ләкин... Әгъмәлетдинне 1945 елның җәендә японнарга каршы сугышка җибәрәләр. Әнә шунда ул батырларча һәлак була. Шул хәбәрне ишеткәч, ана кеше өч айдан үзе дә мәрхүм була. 1945 елның декабрендә авылдашлары 67 яшьлек Фатыйха түтине җирлиләр. Һәм шуның белән ишле гаиләнең олы фаҗигале тарихы тәмамлана...

«КИЧЕР, САКЛАП КАЛА АЛМАДЫК»

Юк, тәмамланмый! Бәхеткә, фронтка киткәнче ике улларының – Мөгътәсимнең бер малае, өч кызы, ә Ибраһимның бер улы һәм кызы кала. Әмма... Мөгътәсимнең җәмәгате Гамилә авырып үлү сәбәпле, 1942 елда дүрт баланы да ятимнәр йортына алып китәләр. Авылда исә Фатыйха түтинең ике оныгы – Ибраһимының балалары була. Бергә яшәмәсәләр дә, оныклар әбиләре янына бик еш барып йөри. Иң сөенечлесе – ул оныкның берсе, Ибраһимның кызы Мәрзия апа бүген исән-сау. Өлкән яшьтә булса да, үз аягында йөри, акылы камил,

күңеле шат. Туган авылында балаларының кадер-хөрмәтен тоеп яши ул.

Танышып, хәл-әхвәл сорашкач та, Мәрзия апага:

– Фатыйха әбиегезне яхшы хәтерлисезме? – дидем.

– Әйе, бүгенгедәй күз алдымда тора. Чандыр гына гәүдәле, җитез карчык иде. Әби мәрхүм булганда миңа унбиш яшь тулган иде. Гомер буе сыер тотты ул. Үләр алдыннан гына сыерын күршеләре алып чыкты. Соңгы көннәрендә үзе дә күршеләрендә яшәде.

– Ә ни өчен сезнең йортка күченеп килмәде? – дим.

– Өен ташлап китәсе килмәде. Әни баштарак гел чакыра иде. Тик әби: «Үз нигеземдә үләсем килә», – дип әйтә килде. Күршеләре гел кереп йөрде. Берсендә әни белән килсәк, күршеләр әбинең сараен утынга сүткән. Әнинең шуның өчен тавыш чыгарганын хәтерлим. Күршеләр сыерын савып, сөтен дә көн саен алып чыгып киткәннәр. Әнә шулай әби күршеләрдә калды да...

Мәрзия апа күңелендә бер истәлек яши. Ул аны бүген дә бик яхшы хәтерли:

– Авылда: «Әгъмәлетдин һәлак булган», – дигән хәбәр таралды. Мин аны-моны уйлап тормыйча, әбинең өенә йөгереп бардым да: «Абыйны үлгән диләр. Су-Елга авылыннан бер солдат кайткан, ул күргән», – дидем. Әби башта таш кебек катып калды, аннан үксеп елый башлады. Мин үземчә юаттым инде аны. Ләкин ул чакта әбинеңниләр кичергәнен аңлар дәрәҗәдә булмаганмын, әлбәттә.

Икенче көнне иртән Фатыйха әби килененең йортына килә. Оныгы Мәрзияне алып, унбиш чакрым ераклыктагы Су-Елга авылына китәләр. Фронттан яраланып кайткан солдат Мәгъсүмҗан Юнысов яшәгән йортны эзләп табалар. Фатыйха әби улы белән бер полкта булган егеткә турыдан-туры сорау бирә:

– Мәгъсүмҗан, өзмә үзәкне. Дөресен сөйлә... Мин инде озак та яшәмәм. Көтүдән дә авыр нәрсә юк. Әгъмәлетдинем исән түгелме?

1
Иң сөенечлесе – ул оныкның берсе, Ибраһимның кызы Мәрзия апа бүген исән-сау.

2
Урта Кирмән зиратында, агач рәшәткәләр белән тотып алынган урынга, кечкенә генә кәгазьгә Фатыйха Әхмәдиева турында өч-дүрт җөмлә язылган.

3
Фатыйха Әхмәдиеваның нәсел дәвамчылары.

4
Фатыйха Әхмәдиеваның улларына багышлап тукыган сөлгесе.

5
Музей хезмәткәрләре кулында инде булачак һәйкәлнең кечерәйтелгән варианты бар.

Мәгъсүмҗан күз яшьләрен сөртә:

– Без аны сазлыклы урында җирләп калдырдык… Кыйблага каратып гәүдәсен бордым, белгән догаларымны укыдым, Фатыйха апа. Аның батырлыгы хисабына без исән калдык… Менә аның пилоткасы, истәлеге дип башыннан салдырып алдым. Эх, Фатыйха апа, Әгъмәлетдиннең бик тә синең янга кайтасы килде. «Мине әни көтә», – дип көн дә әйтә иде. Кичер, саклап кала алмадык, кичер…

Мәрзия апа Фатыйха әбисе белән болыннар аша сүзсез генә авылга кайткан сентябрь кичен яхшы хәтерли. Шул көннән соң сигез улын югалткан ананың хәле тагын да начарлана. Йөри алмас хәлгә килә. Күршеләрендә ике айдан артык яшәп, бакыйлыкка күчә.

– Укчы-автоматчы Әгъмәлетдин Фәттахов Советлар Союзы Маршалы Р. Я. Малиновский җитәкчелегендәге Забайкалье фронты гаскәрләре сафында дошманның Квантун армиясенә каршы хәлиткеч-җитди һөҗүмдә катнаша. Хинган-Мукден операциясе барышында 36 нчы армия сугышчылары японнарның җиңелмәс дип исәпләнгән алты мең кешелек Хайлар гарнизонын «тез чүктерәләр». Шул армиянең гади бер сугышчысы Әгъмәлетдин Фәттах улы, украин егете – егерме дүрт яшьлек ефрейтор Владимир Прокопьевич Бульба белән бергә, 18 августта дошман дзотының үлем укларын чәчүче амбразурасын күкрәге белән каплап, Үлемсезлеккә атлый…

Шаһинур Мостафинның
«Ядрәләрне эреткән йөрәкләр» китабыннан

«ӘТИНЕ ОЗАТЫРГА БАРДЫМ»

Исмәгыйль, Ибраһим, Мөгътәсим, Мөхлисулла, Мәгъсүмҗан, Габделбарый, Мисбахетдин, Әгъмәлетдин… Бер ананың сигез улы, һәм берсененң дә кабере билгеле түгел. Ни кызганыч, Фатыйха әбинең дә төгәл күмелгән урыны юк. Әйе, Урта Кирмәндә әбигә бик тыйнак кына каберлек ясап куйганнар, әмма ул якынча гына…

– Әбинең каберен төгәл хәтерләмим, – диде Мәрзия апа. – Ул чагында таш куюлар бик юк иде бит. Аның әле зәмһәрир суыкта кабер казуы да бик катлаулы эш: авылда ирләр юк дәрәҗәсендә, булса да, сугыштан яраланып кайтучылар иде. Әбине юл кырыенарак җирләгәнне хәтерлим. Ул чорда бөтен мәрхүмнәрне шунда җирләделәр…

Мәрзия апа әтисен фронтка озаткан көнне дә яхшы хәтерли. Атка утырып, район үзәгенә кадәр бара ул.

– Әтиләрне военкомат ишегалдында тезеп бастырдылар, – дип истәлекләре белән уртаклашты Мәрзия апа. – Без, озатучылар, урам якта тора идек. Газиз кешемне күргәч, тиз генә военкомат коймасы аша сикереп, әтинең алдына килеп бастым. Ул мине кочагына алды. Хәрби киемле кеше нәрсәдер сөйли, ә әти кулы белән башымнан сыйпап-сыйпап ала. Ул чагында аның сугышка киткәнен белсәм дә, соңгы күрешүебез дип кем уйлаган… Әти мине бик ярата иде. Хәер, абыйга карата да бик рәхимле иде. Әти хушлашканда кулына күтәреп алды да: «Кызым, әниеңә йорт эшләрендә булыш. Мәктәптә яхшы укы. Ә мин сиңа хатлар язып торырмын», – диде.

Ибраһим Фәттах улы кызына сүз бирә – озак тормас, туган ягына тиз әйләнеп кайтыр. Әммә… бер елдан соң ата кешедән хатлар килүдән туктый. Соңрак, 1955 елда гына, очраклы рәвештә ачыклана – Ибраһим Яңа Комазан авылыннан Вәзыйх исемле егет белән бергә булган. Снаряд төшеп, гәүдәсе теткәләнеп беткән полкташын Вәзыйх үз куллары белән җирләгән…

Мәрзия апа үзе мәрхүм җәмәгате белән җиде бала – алты кыз, бер ул тәрбияләп үстергән. Бүген улы һәм килене тәрбиясендә кадерле әни, дәү әни булып яши. Иң сөенечлесе – балаларының барысы да исән-сау, тормышлары матур. Ике кызы авылда яши, калганнары читтә икән. Туксан ике яшен тутырган әбинең әлегә 14 оныгы, 15 оныкчыгы бар. Сигез оныгы армия сафларында булган. Мәрзия апа моны аеруча бер горурлык белән әйтте.

ҺӘЙКӘЛ КИРӘК!

Фатыйха Әхмәдиеваның фаҗигале язмышы хакында киң җәмәгатьчелек 1990 нчы елларда гына белә. Якташлары, эзтабар язучы Шаһинур Мостафин очраклы гына ишетеп ала. Шуннан соң ул Фатыйха апаның сугышта үлгән уллары турында мәгълүмат туплый башлый. Шаһинур Мостафин район үзәгендә Ана һәйкәле ясауны башлап йөрүче дә була. Бүген Мамадыш шәһәренең «Хәтер паркы»нда балаларын сугышта югалткан аналарга мемориаль такта һәм Ана һәйкәле бар. Ә Мамадыш туган төбәкне өйрәнү музеенда Фатыйха Әхмәдиевага багышлап аерым экспозиция ясаганнар.

– Безнең теләк, хыял – Фатыйха Әхмәдиевага багышлап махсус һәйкәл ясату, – диде Мамадыш туган төбәкне өйрәнү музееның фәнни хезмәткәре Гөләндәм Давыдова. – Әйе, 1997 елда шәһәребездә Ана һәйкәле эшләнде. Әмма ул бөтен аналарга багышлана. Ә Фатыйха Әхмәдиева кебек анага аерым һәйкәл булырга тиеш! Сигез ир бала тәрбияләп үстереп, аларның барысын да сугышка озаткан, ә иң аянычлысы – шуларның берсе дә кире әйләнеп кайтмаган. Андый каһарман аналар ил күләмендә күп түгел. Без белештек: рус, украин, белорус, осетияле, чуваш, удмурт халкында да шундый фаҗигале язмышлар булган. Һәм ул аналарның һәрберсенә шәхси һәйкәл куелган. Алар моңа лаек та. Ә татарның юк...

Музей хезмәткәрләре кулында инде булачак һәйкәлнең кечерәйтелгән варианты бар. Аны Россия Рәссамнар берлеге әгъзасы, Мамадыш егете, скульптор Артур Давыдов эшләгән. Каһарман ананың тормыш юлын өйрәнеп, Мәрзия апа белән очрашып сөйләшкәннән соң, Артур бик үзенчәлекле сын күзаллаган. Булачак һәйкәлдә Фатыйха апа эскәмиядә утыра. Аның сәбәбен Гөләндәм ханым Давыдова болай аңлатты:

– Бездә Фатыйха апаның оныгы Мәрзия белән өйләре каршындагы эскәмиядә утырып төшкән фотосурәте бар. Булачак сын әнә шул фотоны күзаллап эшләнсен иде, дибез. Гомумән, авыл халкы өчен эскәмия элек-электән дөнья белән бәйләнеш чарасы булып торган: ул анда авыр эштән соң азрак хәл алган, күрше-күлән белән аралашкан, дөнья хәлләрен сөйләшкән. Сугыштан соңгы чорда исә аналар, шунда утырып, бәлки кайтырлар дип, һәлак булган улларын көткән. Шуңа да эскәмия һәйкәлдә символик көчкә ия.

– Һәйкәлне куйдырырлык иганәчеләр юкмы? – дим.

– Әлегә табып булмый. Артур һәйкәлнең бронзадан булуын тели. Фотога утырып төшү өчен дә урын кирәк. Район администрациясе бу хакта белә, эмма, әлеге дә баягы, бөтен сәбәп акча юклыкка кайтып кала.

...Фаҗигале язмышлар була, эмма Фатыйха Әхмәдиева кебекләре бик сирәк... Дүрт елда җиде улын, бер кызын югалткан ана нәрсәләр кичерде икән? Күз алдына да китереп булмый. (Башка берәүгә дә бу олы фаҗигане күрергә язмасын!) Иң аянычлысы – шуның кадәр хәсрәт кичкән ана бик күп еллар күләгәдә калган. Хәер, аның исемен бүген дә данлыйлар дип әйтеп булмый. Урта Кирмән зиратында, агач рәшәткәләр белән тотып алынган урынга, кечкенә генә кәгазьгә (!!!) Фатыйха Әхмәдиева турында өч-дүрт җөмлә язылган. Миңа калса, зиратта ким дигәндә таштан матур истәлек тактасы торырга тиеш. Район үзәгендә исә махсус һәйкәлгә акча табылмый. Илгә сигез ул биргән ана исән вакытында да бер көн кадер-хөрмәт күрмәгән. Хәзер дә юк. Эх, егетләр... Т

– Мамадыш туган төбәкне өйрәнү музеенда каһарман ана һәм аның улларына багышланган экспозиция бар. Иң кадерле ядкарьләрнең берсе булып Фатыйха Әхмәдиеваның улларына багышлап тукыган сөлгесе һәм Коръән китабы саклана. Фатыйха апа уллары рухын мәңгеләштерергә теләгәнме, очраклылыкмы, әмма татар халкының милли символы – кызыл башлы сөлгедә 8 бизәк ярылып ята! Ил азатлыгы өчен шәһит киткән сигез улының төсе... Шуңадыр, сөлгене тетрәнмичә кулга алу мөмкин түгел, йөрәкнең асты өскә килә...
1904 елда Кәримовлар типографиясендә басылган, Фатыйха апаның шәхсән үзенеке булган, укый-укый таушалыбрак киткән Коръән китабының урыны да түрдә. Сабыр ананың кешегә күрсәтергә теләмәгән күпме күз яше түгелгәндер аңа... Кул җылысы, бармак эзләре калган...

Мамадыш туган төбәкне өйрәнү музееның фәнни хезмәткәре Гөләндәм Давыдова

4

5

ХӘСӘНИ САЛГАН СУКМАК

Айдар Шәйхин

Иң алдынгы нәшрият, иң прогрессив татар журналы, кыю һәм тирән фикерләр, кабатланмас иҗат экспериментлары – болар барысы да Әхмәтгәрәй Хәсәни турында. Аның язмышы фаҗигале тәмамлана. Әмма аның очрагында үлемне үлем дип кенә бәяләп булмый. Без әле дә Хәсәни салган сукмактан атлыйбыз шикелле.

Әхмәтгәрәй һәм Зәйнәп Хәсәниләр. 1903 ел. ТР Милли музее фондыннан.

СӘҮДӘГӘРЛӘР КАНЫ

Әхмәтгәрәй моннан 140 ел элек, 1883 елның 15 декабрендә хәзерге Татарстанның Әтнә районына кергән Олы Әтнә авылында туа. Аның этисе Сибгатулла Гайнулла улы сәүдәгәрлек белән шөгыльләнә һәм, 1888 елны гаиләсен Казанга күчереп, мануфактура сәүдәсен дәвам итә. Башкалада Хәсәниләрнең йорты Печән базары тирәсендә, Каюм Насыйриның күршесендә генә була. Бөек мәгърифәтченең янәшәсендә генә үсү дә Әхмәтгәрәйгә йогынты ясамый калмагандыр. Истәлекләрдә аның әле үсмер чагында ук Каюм бабай янына йөрүе һәм аралашуы теркәлгән.

Булачак нәшир сыйфатлы белем алу бәхетенә дә ирешә: этисе башта өйгә укытучылар чакыртып укыта, ә аннары – данлыклы «Мөхәммәдия». Белем алуының нәтиҗәле булуы һичшиксез, чөнки Әхмәтгәрәй рус телен дә, гарәп, алман һәм француз телләрен дә яхшы үзләштерә. Алга таба үзе нигезләгән «Аң» журналында псевдоним белән чыгарачак мәкаләләреннән аның төрле мәдәниятләрне белүе, дөньякүләм фәлсәфә, әдәбият һәм сәнгать тарихы белән таныш булуы бик яхшы аңлашыла. Димәк, алдыбызда шул чорның эталон вәкиле: сәүдәгәр гаиләсендә туган, сыйфатлы белем алган һәм прогрессив карашларга ия егет.

20 яшьлек чагында бу егетнең тормышында иң әһәмиятле вакыйгаларның берсе була. Ул сәүдәгәр хаҗи Ногман Габделкәримовның кызы Зәйнәпкә өйләнә. Татар тарихында Зәйнәп Хәсәния исеме дә могтәбәр бер урында тора. Ул – иренең даими ярдәмчесе һәм киңәшчесе, хезмәттәше һәм фикердәше. Зәйнәп ханымнан башка Әхмәтгәрәйнең уңышлары да, бәлки, мөмкин булмас иде. Ә бит бик тиздән аларның, заман теле белән әйткәндә, зур проектлары башланачак...

Фотолар автордан алынды

ЯҢА ДӘВЕРНЕҢ ҮЗ «ГАСЫР»Ы

1907 елның 25 февралендә Әхмәтгәрәй Хәсәни китап нәшер итү эшен башлый. Ул нәшриятын әлегә рәсми рәвештә теркәп тә тормый, чөнки эш масштабларын зурайту турында бик уйламый да. Бер ел эчендә яңа нәшрият 13 китап бастырып чыгара. 1908 елның 26 февралендә үк, төгәл бер ел узгач, Хәсәнинең «Сарай» номерларында урнашкан «офис»ына полиция килә һәм тентү уздыра. Бу хакта документларда теркәлгән мәгълүмат та бар. «При осмотре найдены книги на татарском языке, частью беллетристического, частью же популярно-научного содержания, связанные кипы и назначенные по словам самого Ахмеда-Гарея Хасанова к отправке иногородним заказчикам. Все книги оказались изданным самим Хасановым с ведома Казанского Комитета по делам печати. Кроме означенных произведений, найдены два сочинения (одно по математической географии, другое по пчеловодству) в корректурных оттисках, по-видимому еще не изданные в свет. В помещении на Екатерининской улице, кроме печатных книг, оказались кипы несброшюрованных листов тех же изданий, которые были найдены у Хасанова и в готовом виде». (Әхмәтгәрәй Хәсәнине тентү актыннан, 1908 елның 28 феврале. ТР Дәүләт архивында саклана).

Шик тудырырлык берни табылмаса да, Хәсәниләр эшчәнлекләренең билгеле бер даирәдә зур кызыксыну уятканын һәм аны ничек тә булса рәсмиләштерергә кирәклеген аңлыйлар.

Дусты Габдрахман Рәхмәтуллин белән берлектә, Әхмәтгәрәй Хәсәни 1909 елның 1 гыйнварыннан рәсми рәвештә «Гасыр» нәшрияты эшен башлап җибәрә. Шулай итеп, тулысынча легаль нәшрият һәм китап кибете барлыкка килә.

Танылган галим Әбрар Кәримуллин санап күрсәткәнчә, эшчәнлеге 1921 елга кадәр үк дәвам иткән «Гасыр»да 14 ел эчендә 153 исемдәге китап басылып чыга. Аларның безгә мәгълүм булган өлешенең гомуми тиражы – 437 500 данә. Башка татар нәшриятлары белән чагыштырсак, ул кадәр зур сан да түгел сыман. Әмма Хәсәнинең нинди китаплар чыгарганын карасак, «Гасыр»да, мөгаен, заманның иң прогрессив басмалары дөнья күргәндер. Ул эшчәнлеген серияләр форматында да алып бара. Нәшрияттa «Театр мәҗмугасы» сериясендә драма әсәрләре басыла. «Әдәбият мәҗмугасы»нда татар әдипләренең әсәрләре дә, русчадан тәрҗемәләр дә чыгарыла. Фәнни-популяр китаплар өчен – «Голум вә фәннун», мәктәпләр өчен – «Дәрес китаплары», балалар әдәбияты өчен «Балалар дөньясы» серияләре барлыкка килә.

Тәрҗемәләр, дәреслекләр, медицина өлкәсенә караган файдалы китаплар – боларның барысы да аңлаешлы, җиңел телдә язылган, сыйфатлы итеп бастырылган хезмәтләр.

Әхмәтгәрәй Хәсәни энесе Габделбарый белән. «Әхмәтгәрәй Хәсәни» фәнни-популяр җыентыгыннан. 2011 ел.

Әхмәтгәрәй Хәсәни, Оренбургтагы Рәмиевләр сыман ук, китап чыгару эшендә полиграфия сыйфатына зур игътибар бирә. Китап зәвыклы булырга тиеш дип саный ул. Шуңа күрә «Гасыр» чыгарган китаплар да, «Аң» журналы да иллюстрацияләргә бай булулары белән аерылып тора. Китапларда титул битләре, тышлыклар, төрледән-төрле бизәлеш элементлары ерактан ук «Бу Хәсәниләрнеке!» дип кычкырып тора сыман. Хәер, бу бер дә гаҗәп түгел. Басмаханә эшендә белемен арттырыр өчен, Хәсәни 1910 елда махсус Швейцария, Польша, Германия һәм Франциягә бара, типографияләр эше белән таныша.

Татар язучылары һәм актерларының портретларын почта открыткалары рәвешендә бастырып дөньяга таратучы да «Гасыр» нәшрияты була. Хәзер тарихи һәм биографик китапларны, музей экспозицияләрен бизәгән бу портретлар татарларны бер мәдәни киңлектә берләштерергә ярдәм итә. Казандагы язучыны Уфада да, Оренбургта да, Мәскәү белән Питерда да таный башлыйлар бит!

Бу зур эшләрне Әхмәтгәрәй сөекле җәмәгате Зәйнәпнең рухи һәм матди ярдәме белән генә башкарып чыга. Нәшриятны оештырганда ук Зәйнәп ханым үзенең бирнә акчасын да бу эшкә тота. Бу хакта аның күп еллар үткәч язучы һәм галим Мөхәммәт Мәһдиевкә сөйләгән истәлеге теркәлгән: «Әти-әни язу эшенә каршы килделәр. Җитмәгән сумманы минем бриллиант, энҗе, йөзекләрне сатып әзерләдек. Башта китаплар бастырдык. Якын иптәшләр әйтәләр: «Әллә берәр журнал чыгарып карыйсызмы?»

ДУСЛАРНЫ САЙЛЫЙ БЕЛ

Хәсәни шул рәвешле иҗат әһелләрен бар дөньяга таныта, үзләрен исә «Гасыр» тирәсендә берләштерергә омтыла. Ә бәлки, аның махсус омтылышы-планы да булмагандыр, ихласлык белән дөньяда гамәл кылып, аны үзгәрткән, матурлык чәчкән нәшир янына Габдулла Тукай, Фатих Әмирхан, Хөсәен Ямашев, Галимҗан Ибраһимов, Гафур Коләхмәтов, Гали Рәхим һәм башка бик күпләр үзләре дә җыелырга тырышкандыр.

Хәлбуки ул чор татар яшьләре нәшриятредакцияләрдә генә түгел, ә аерым клубта да җыелалар. 1907 елның 1 декабрендә ачылган «Шәрекъ клубы»ның башында торучыларның берсе – безнең Әхмәтгәрәй әфәнде. Аңа 24 яшь, ул «яшьләр хәрәкәте» лидерларының берсе, шуңа да мондый берләшмәнең нәкъ менә аның катнашында оешуы табигый.

Әхмәтгәрәй Хәсәни Швейцариядә. 1910 ел. «Әхмәтгәрәй Хәсәни» фәнни-популяр җыентыгыннан. 2011 ел.

Алдынгы татар яшьләрен берләштергән клубта спектакльләр һәм концертлар куела, лекцияләр укыла, «әдәбият ахшамнары» уздырыла. Әхмәтгәрәйнең энесе Габделбарый Хәсәни клубта кыллы оркестр да оештыра. Клубта иҗтимагый һәм сәяси темаларга моназаралар да кубып-кубып тора. Гомумән, «Шәрекъ» яшьләре – үз фикерләре булган һәм актив шәхесләр. Шуңа күрә «Шәрекъ клубы» әгъзаларының һәрберсе турында жандармерия төпченеп мәгълүмат җыя, донослар һәм хәбәрләр сәяси полициягә даими килеп тора.

1908 елда «Шәрекъ клубы» хәзерге Горький урамы, 3 нче йортта урнашкан «Новый клуб» бинасында ике спектакль куйдыра. Аларның берсе Хәсәнинең «Хат болгатты» пьесасы буенча уйнала. Бу елларда Әхмәтгәрәй тәрҗемәче, драматург һәм язучы буларак та үзен сыный башлый. Алга таба туып, үсеп килгән татар театрында «Денщик Гали» спектакле дә куелып, тамашачы мәхәббәтен яулаячак. Бу дәвердә ул Г. Ильяс псевдонимын куллана. Әдәби хезмәтенә ул кыенсынып, чамадан тыш тыйнаклык күрсәтеп карый. «Денщик Гали»нең кереш сүзендә ул болай яза:

«Каләмем тәҗрибәсез, куасез, бу беренче тәхриремдә (әсәремдә) чук нәксаннар (күп җитешсезлекләр) булачагын беләмен. Ләкин нә чара ки, әдәбиятымызга улган зыядә мәхәббәтем мине каләм сарып бул язмая мәҗбүр итте. Хөрмәтле укучыларга түбәнчелек белән тәкъдим итеп, косурлары (кимчелекләре) булса, гафу итүләрен үтенәмен».

Билгеле, шушы иҗади мохиттә Хәсәнинең якын дуслары-фикердәшләре барлыкка килә. Алар арасында Габдулла Тукай да бар. Шагыйрьнең шигырь җыентыклары да «Гасыр»да басылып тора. Ә инде 1912 елда пәйда булачак «Аң»ның тарихы турыдан-туры Тукай–Хәсәни тандемына барып тоташа. Тукай Әхмәтгәрәйнең өендә дә, дачасында да була, гомумән, гаилә дустына әверелә. Ахыр чиктә, Тукай белән Клячкин хастаханәсендә хушлашкан соңгы кешеләрнең берсе дә – Әхмәтгәрәй. Еллар үткәч, Татарстан Дәүләт музеена Тукай һәм замандашлары белән бәйле шактый гына экспонатларны тапшыручы исә Зәйнәп Хәсәния булачак.

«ИНДЕ ЭШЛИК ЧЫН АҢ БЕЛӘН»

Нәшрият бар. Татар яшьләренең җыелу, күңел ачу, аралашу һәм бергә гамәл кылу урыны – клубы бар. Фикерләрне татар дөньясына уртаклашыр өчен матбугат чарасы гына җитми. Анысының чираты 1912 елда килеп җитә.

Журнал Хәсәни тирәсендә формалашкан иҗади түгәрәкнең озак уйланулары нәтиҗәсендә оешып китә. Шулай итеп, «Аң»ның аңлы даирәсенә Габдулла Тукай, Галимҗан

Ибраһимов, Фатих Әмирхан, Гали Рәхим, Җамал Вәлиди, Газиз Гобәйдуллин, Фәхрелислам Агиев, Һади Атласи, Гафур Коләхмәтов һәм тагын бик күпләр керә.

Әзерлек эшләре 1912 елның җәендә башланып китә. Журналга исем табу мәсьәләсе Хәсәниләр дачасында үткән мәҗлестә хәл ителә. Бу рәсми булмаган киңәшмә-мәҗлестә Тукайның да катнашуы, журналга «Аң» исемен тәкъдим итүе билгеле. 15 декабрьдә басылып чыккан беренче сан да Тукайның шигыре белән ачылып китә. Аның соңгы юлы аеруча кызыклы: «Инде эшлик саф, ачык күзләр белән, чын аң белән».

Чынлап та, ул чор матбугатында «Аң» бөтенләй башка дәрәҗәгә күтәрелә. Мөгаен, ул Европа мәдәниятенә иң якын торган журналыбыз булгандыр. «Аң» чын мәгънәсендә халыкның үзаңын тәрбияли торган басмага әйләнә. Журнал сәнгать белән дә таныштыра: Галимҗан Ибраһимов тәкъдиме буенча, күренекле рәссамнарның картиналары тупланган аерым «Альбом» нәшер ителә һәм таратыла. Милли әдәбият белән беррәттән, журнал битләрендә дөнья әдәбияты үрнәкләре, фәнни һәм фәлсәфи тәрҗемәләр дә дөнья күрә. «Аң»дагы дискуссияләрнең шаукымы әле бүген дә сизелә.

Әхмәтгәрәй Хәсәни үзе А. Чеховның «Бәхәсләшү», А. Франсның «Бине Бәшир тарихы», А. Амфитеатровның «Укучы дус», А. Апинянскийның «Сахра» хикәяләрен татар теленә тәрҗемә итә.

Журналда аның «Рух гыйлеменнән бер ләүхә» исемле тәрҗемә трактаты басыла. Бу – татар телендә психология өлкәсендә язылган беренче текстлардан.

«Арган гакылның калебкә ирек белән хөкем сөрергә рөхсәт иткән минутлары да була. Ләкин гакыл тиздән тәүбәгә килергә бурычлы була, чөнки калеб шул минутны форсат улып, үзенең киләчәктә карарга булдыксызлыгы аркасында төзәтмәслек явызлык эшләргә өлгерә һәм гакылга аның авыр нәтиҗәсен җиңеләйтә төшәр өчен күп көч сарыф итәргә туры килә».

123 саны чыгарга өлгергән журналның уңышы – Әхмәтгәрәй белән Зәйнәп Хәсәниләрнең казанышы. Нәшриятның да, журналның да эшен тулысынча диярлек бу ике кеше алып бара. Бу чыннан да эчкерсез, ихлас хезмәтнең гали бер үрнәгедер, мөгаен.

ХУШЛАШУ

Журнал тарихы 1918 елда өзелә. Аны чыгарыр өчен оештырылган типография дә башта дәүләткә арендага бирелә, аннары Рәхмәтуллин белән Хәсәни аны бөтенләйгә дәүләт кулына тапшыра. Бу милек күчеше иректә булган дип санала.

НЭП чорында, 1926 елда, татар язучылары, галимнәре, журналистлары, әдәбиятчылары, шул исәптән Хәсәни тарафыннан «Яңа китап» кооператив нәшрияты оештырыла. Бу елларда Әхмәтгәрәйгә гаиләсен кайгырту шактый авырга төшә. Нәшриятны 1929 елда ябалар. Ә ике елдан, нәкъ шул нәшрият эшчәнлеге аркасында, аны кулга алалар.

1932 елның маенда, «милли буржуазия белән элемтәдә торуда, яшерен әдәбият таратуда» гаепләнеп, 3 елга лагерьга хөкем ителә. Аның төрмәдән гаиләсенә язылган хатлары да сакланган:

«Я жив, не хвораю, но здоровье мое пошатнулось, чувствуется слабость и утомленность, память тоже ослабела, но вместе с тем я не падаю духом, стараюсь быть бодрым, на будущность смотрю оптимистически, думаю о том, что 50-летнему старику, посвящающему почти половины своей жизни к просвещению своего народа, будет дана возможность вновь вступить в социалистическое общество и жить новой, разумной и трудовой жизнью».

Хәсәни Беломор-Балтыйк каналы төзелешенә җибәрелә. Әмма азат ителгәннән соң өйгә кайткан чагында тифтан үлә. Аңа бу вакытта 50 яшь була.

Аны аклау мәсьәләсе 1959 елда гына хәл ителә. 1933 елда ук вафат булган репрессия корбанының хатынына, «ирегез 1961 елның 9 мартында үлде» дип, үлү турында таныклык тапшырыла...

Әхмәтгәрәй Хәсәнинең кара савыты.

Әхмәтгәрәй Хәсәнинең каләме.

«Аң» журналының 1914 елгы бер санынннан.

ТАТАР ТЕАТРЫНЫҢ АТАСЫ ГАЛИӘСГАР КАМАЛ

Илдус Заһидуллин

Күренекле драматург Галиәсгар Камалның 1910 елның 5 ноябрендә «Шәрекъ клубы»нда уздырылган 10 еллык иҗат юбилееннан соң язган мәкаләсен Г. Тукай түбәндәге сүзләр белән тәмамлый: «Минем күңелемдә Галиәсгар әфәнде әсәрләренә моннан әллә ничә еллар элек, ярты сабый вакытымдук, мәхәббәт орлыклары чәчелгән иде. Аның әсәрләрен бу елларда сәхнәдә күрә-күрә вә муаффәкыятьле (уңышлы) чыкканнарына тәгаҗҗеб итә-итә (гаҗәпләнә-гаҗәпләнә), шул мәхәббәт һаман үсә бара, тамыр җәя барадыр. [...] Һәм дә татар тормышының, Казан мещаннарының иң безгә мәҗһүл (мәгълүм булмаган) почмакларын сәхнәдә якты кояш кеби күрсәтергә каләменең көченнән килгәнлегенә хәйрат итәрәк, аны, Галиәсгар әфәндене, «татар Островские» наме мөкәррәм вә мөстәхәккы белән тәгъзим (хөрмәтле вә лаеклы исеме белән олылап) итеп, сүзне бетерәм».

ТЕАТРГА МӘХӘББӘТ

Галиәсгар Камалетдинов 1879 елның 6 гыйнварында Казан каласында мех остасы гаиләсендә беренче бала булып дөньяга килә. Әтисе Галиәкбәр, хәзерге Арча районы Сикертән авылындагы күп балалы ярлы гаилә туып, 12 яшендә Казанга килә һәм бер байда 4 ел йорт хезмәтчесе була, аннары мех белән сату итүче Мамаев фамилияле сәүдәгәргә хезмәткә керә. Анда чүпкә чыккан вак мех кисәкләрен гамәлгә кертү кәсебен үзләштерә. Сәүдәгәр, тырыш егетне югалтасы килмичә, аңа үзенең энесе – Түбән Масра авылы крестьяны Хәбибулланың кызы Мәүгыйзәне димли. Шул рәвешле яңа гаилә корыла.

Укый-яза белмәгән Галиәкбәр улына төпле белем бирергә тырыша. Ул башта 6 яшьлек Галиәсгарны бер елга Түбән Масра мәктәбенә бирә. Аннары Казанга кайтартып төрле мәдрәсәләрдә, шул исәптән 1893–1900 елларда «Мөхәммәдия»дә укыта. Шәһәр мөселманнары арасында шәкерт каллиграфия остасы – хәттат һәм Коръәнне мәкам белән укучы булып танылa.

Галиәсгар шук, җор телле малай булып үсә. Ел саен Май чабу һәм Раштуа бәйрәмнәре көннәрендә шәһәрнең ашлык базарында (хәзерге Колхоз базары урыны) куелган балаганнардагы «кәмит»ләрне һәм курчак театрлары чыгышларын хисләнеп карый, шулардан күреп кайтып, үзе ясаган курчаклар белән чоланнарында «артист» булып уйный. Ел саен җәйге айларда, камчатчы этисенә ияреп, сату-алу белән Мәкәрҗә ярминкәсенә йөри башлагач та, иң яраткан шөгыле буш вакытларда балаганнарда фокуслар карау, цирк артистлары чыгышларын тамаша кылу була.

Гаиләсгарның истәлекләреннән күренгәнчә, яшүсмер дөньяви әдәбият белән кызыксына, В.В. Радловның «Белек» китабын, К. Насыйри әсәрләрен, «Мөхәммәдия»дә укыганда Гаспралының «Тәрҗеман» газетасын укып бара. Бигрәк тә Г. Ильясовның «Бичара кыз», Ф. Халидинең «Рәдде бичара кыз» дигән пьеса китапларын яратып укый. «Рәдде бичара кыз»ны кат-кат укып, ятлап бетерә. Ул да түгел, «китапта язганны сәхнәдә куя торган урын бар» дигән сүз ишетеп, иптәш шәкерте белән шәһәрнең рус театры спектакленә бара. Русча аңламыйча, артистларның хәрәкәтләрен күзәтә. Аларның ни сөйләгәннәренә

Фотолар автордан алынды

төшенү өчен, К. Насыйри сүзлеге ярдәмендә үзлегеннән рус телен өйрәнә башлый. «Мөхәммәдия»дә вакытта Миргаяз Иманаев җитәкләгән башлангыч рус-татар мәктәбендә рус телен үзләштерүен дәвам итә. Мәдрәсәне тәмамлагач, Санкт-Петербургта нәшер ителә торган «Нева» журналын алдыра, аңа кушымта булып килгән Чехов әсәрләренә мөкиббән китә. Мәдрәсәдәге бүлмәдәше Борһан Шәрәф белән якшәмбе көннәрне көндезге спектакльләргә йөриләр.

Аның төрек теле белән кызыксынуына да театрга мәхәббәте сәбәп була. Галиәсгарның кулына Нәмикъ Кәмалның 1873 елда язылган «Зәваллы чуҗык» исемле драмасы килеп керә, шуны аңлар өчен төрек теле һәм әдәбиятын өйрәнергә керешә.

«Мөхәммәдия»не тәмамлагач, Галиәсгарны әтисе туган авылы Сикертәндә мулла итеп куярга тели. Ул бу вазыйфадан баш тарткач, остазы Галимҗан Баруди, шәһәрдә үз тарафдарларын арттыруны күздә тотып, Галиәкбәргә улын, бай кызына өйләндереп, калада мулла итәргә киңәш бирә. Галиәсгар Садыйк байның Бибигайшә исемле кызына өйләнә, мәхәббәткә корылган гаиләдә бер-бер артлы балалар туа.

Ләкин кияү мулла булудан баш тарта. Шуннан соң туганнары аны мех сәүдәсенә кертеп җибәрергә тели. Ахыр чиктә, 1901 елда Галиәсгар «Мәгариф» исемле китап кибете ача. Шул ук елны Истанбулдан яңа төрек телендәге һәм тәрҗемә ителгән матур әдәбият, шулай ук театр китапларын алып кайтып сатуны оештыра. 1904 елны исә кибет нигезендә җитәкчесе үзе булган «Камалетдинов вә шөрякасе» исемле китап бастыру һәм китап сәүдәсе ширкәте оештырып җибәрә.

Галиәсгар радикаль фикерле яшьләр белән аралаша. 1902 елны Мәхмүт Алмаев исемле кеше Германиядән типография эшенә өйрәнеп кайткач, аның белән гектографта «Тәрәккый» исемендә яшерен газета чыгара башлый, аны кибете аша «Мөхәммәдия» шәкертләре арасында тарата. Гомумән, 1905 елда кибет эсерлар һәм социал-демократлар матбугатын саклау урынына әверелә, бирадән аларның листовкалары шәкертләр арасында таратыла.

СҮНМӘС ИҖАТ ЯЛКЫНЫ

Төрек һәм рус әдәбиятын максатчан уку «театр җене» кагылган яшь егеткә канат куеп, олы иҗат юлына чыгара дисәк, ялгыш булмас. Шушы вакыйгалар ахыр чиктә Галиәсгарның пьеса язып карау теләген көчәйтә. Укытучысы Миргаяз Иманаев, аның 1898 елда язган «Бәхетсез егет» исемле беренче әсәрен ошатып, Петербургка, цензорга да җибәрә. Бастырырга рөхсәт килгәнче, Галиәсгар югарыда телгә алынган «Зәваллы чуҗык»ны «Кызганыч бала» исеме белән татарчага тәрҗемә итә. Ул да түгел, «Өч бәдбәхет» исемле өч пәрдәлек пьеса яза. Өч әсәр дә аерым китап булып 1900 елда Казанда дөнья күрә.

Г. Камалның беренче әсәрләрендә үк татар җәмгыятенең иске тормыштан яңа тормышка күчү котылгысызлыгын ассызыклау тоемлана. Татар бай-сәүдәгәрләре, аларның гаилә хәлләре мисалында драматург аталар һәм балалар конфликтын иҗтимагый-сәяси яссылыкка чыгара. Татар тормышындагы искелекне детальләрдә тасвирлау, патриархаль гадәтләрне сурәтләү белән янәшә, драмаларда җәмгыятьнең үзгә үсү юлы күзаллана.

1906 елның 22 декабрендә «Гыйшык бәласе» һәм «Кызганыч бала» пьесалары буенча Казанда беренче мәртәбә ачык спектакль уйнала. Чараны оештыручылар арасында Камал үзе дә була, ул тамашаның афишасын үз кулы белән яза.

Үзенең башлангыч чор әсәрләренә тәнкыйть күзе белән карап, драматург аларның икенче вариантларын эзерли. «Бәхетсез егет» (1907) драмасының яңа вариантында, мәгърифәтчелек карашлары белән янәшә, иҗтимагый тәнкыйть көчле яңгыраш ала. «Өч бәдбәхет» пьесасының кабат эшкәртелгән варианты булган «Уйнаш» драмасы (1910) иске тормышның тагын бер ягын – әхлаксызлык, бозыклыкны сурәтли.

Драматург әсәрләрендә үзе белгән, күргән тормышы вакыйгаларын, аерым шәхесләрнең эш-гамәлләрен, сөйләгән сүзләрен оста файдалана. Бу үзенчәлекне 1908 елны Борһан Шәрәф билгеләп үтә: «Г. Камал – иске тормышның инсанны кыса вә изә торган икәнен татып белгән вә шуны сизә башлаганнан бирле шуңа каршы җиһад (көрәш) илә мәшгуль булган заттыр. Ул үзен газаплаган иске тормыштан үч алырга вә аның эшәкелеген башкаларга да ачык күрсәтеп, аннан яшьләрне биздерергә керешкән...»

Әмма бу сыйфат аның пьесаларында үзләрен «таныган» яки аларны тамашада «танып» кайт-

Г. Камалның әтисе Галиәкбәр.

Г. Камалның әнисе Мәүгыйзә.

М. Гафури, Һ. Такташ һәм Г. Камал. 1924 ел.

каннар сүз җиткергән Казан бай-сәүдәгәрләре арасында зур гауга-тартышларга сәбәп була. Печән базары әһелләре тарафыннан бәддога алган драматург үзе генә түгел, аның туган-тумачасы да ике ут арасында кала. Әмма болар Камалның иҗат ялкынын сүндерә алмый.

Г. Камалның XX гасыр буе сәхнәдән төшмәгән иң күренекле комедиясе – иске-яңа көрәшенә корылган «Беренче театр» (1908) да үз заманы тамашачысын таныла торган прототиплары белән җәлеп итә. Аның сюжеты бик гади: гаиләдә дә, хәтта шәһәрдә дә үзен иң акыллы санаучы Хәмзә бай татарча беренче театрны куйдырмаска йөри. Ә аның үзенең балалары һәм якыннары театрга китеп бетәләр, Хәмзә берни эшли алмый, көлкегә кала. Конфликтның болай чишелеше татар дөньясының яңалык юлыннан тайпылмаячагына ышаныч булып яңгырый. Хәмзә бай образында казанлылар шунда ук Г. Камалның кайнатасын танып ала.

Г. Камалның «Банкрот» (1911) комедиясе дә иске тип татар сәүдәгәрләренең яшәү рәвешен, көнкүрешен, түбән әхлагын сәхнәгә менгерә. Сәүдәгәр Сираҗетдин Туктагаевның, ялган банкротлыкка чыгып, хәйлә юлы белән зур табыш алу вакыйгасында шулай ук ул заманның типик бер күренеше фаш ителә.

Сатирик юнәлешле «Бүләк өчен» (1909) комедиясендә затлы күлмәк өчен улын күрә торып тиң булмаган кәләшкә өйләндерергә әзер Хәмидә образы татар байларының хатыннарын мал-мөлкәт, кием-салым колы буларак көлкегә калдыра.

Татар җәмгыятендәге милләтне кайгыртабыз дип кыланучылар тормышын көлү объектына әйләндергән «Безнең шәһәрнең серләре» (1911) комедиясе төрле катлам вәкилләренең наданлыгын, икейөзлелеген, яңалыкка дошман булуын ача. Шул рәвешле, һәр әсәрендә драматург татар дөньясының яңадан-яңа катламнарын сәхнәгә менгерә, халыкны үз-үзеннән көләргә мәҗбүр итеп, аны әхлакый-мәдәни авыруларыннан терелтергә омтыла.

Аның югарыда саналган әсәрләре «Сәйяр», «Нур», «Ширкәт» татар профессиональ труппалары репертуарларының нигезен тәшкил итә.

Г. Камал, киңкырлы талант иясе иясе буларак, башка жанрларда да каләм сыный. 1900 елны «Сабир хәзрәт» хикәясен яза, аны 1903 елны «Сабир хәзрәт, яки Гыйбрәт» исеме белән китап итеп бастыра. Әдип 1905–1907 елларда шигърият өлкәсендә дә каләм сыный. Милләтне гыйлемле, һөнәрле һәм алдынгы булырга өндәп, «Азатлык» (1905), «Өндәү» (1905), «Безнең кирәк» (1906) кебек мәгърифәтчел шигырьләре шул чор матбугатында дөнья күрә.

1911 елны «Сәйяр» труппасы «Шәрекъ клубы» штатына алынгач, клуб җитәкчеләренең берсе буларак Г. Камал артистларга тамашалар оештыруда, пьесаларны сәхнәдә куюда зур ярдәм итә.

ЖУРНАЛИСТ ҺӘМ НӘШИР

Иҗтимагый актив Галиәсгар 1905 елның октябреннән басыла башлаган беренче татарча «Казан мөхбире» газетасына эшкә урнаша.

Ә 1906 елның февраленнән үз мәсләгенә туры килердәй газетаны мулла Г. Апанаев белән бергә нәшер итә башлый. Атнага өч тапкыр чыга торган «Азат» исемле газетада М. Гафури, Г. Коләхмәтов, М. Максуд, Н. Думави һәм башка шәхесләр язмалар һәм әсәрләре белән катнаша. Мөхәррир Г. Камал белән нашир Г. Апанаев арасындагы сәяси фикер каршылыгы соңгысының газетаны финанслаудан баш тартуына сәбәп була. Шул рәвешле, 56 саны чыккач, «Азат» ябыла.

«Азат» тукталганчы ук Галиәсгар «Азат халык» исемле газета чыгарырга рөхсәт алган була. Аны үзе мөхәррир һәм нәшир сыйфатында гамәлгә куя. Әмма абунәчеләрнең саны аз булу, чыгымнарның зурлыгы Г. Камалны, «Азат халык»ның 15 саны чыккач, басманы ябарга мәҗбүр итә. Сәяси сәбәпләр дә булмый түгел. Әйтик, цензор 15 нче санны хөкүмәткә каршы юнәлтелгән дип таба. Суд мөхәррирне 1 айга гражданский гаупвахтага ябарга хөкем итә. Камал, апелляция биреп, җәзаны 100 сум штрафка алыштыруга ирешә.

Аның 1906 елны «Дөнья» һәм «әл-Бәян» исемле басмаларга рөхсәт алырга тырышып караганы билгеле.

Галиәсгар кабат беркадәр вакыт С. Алкинның «Казан мөхбире»ндә эшләп ала, әмма шәхси мөнәсәбәтләрдә кытыршылык сәбәпле, аннан китеп, Әхмәдһади Максудиның уң либерал юнәлештәге «Йолдыз» газетасы редакциясенә җаваплы мөдир һәм сәркатип булып урнаша.

Г. Камал һәм Бибигайшә Садыйк кызы. 1908 ел.

Биредә Г. Камалның ачык күңелле, кешеләр белән уртак тел таба белүче, җитез фикерле үткер каләм иясе, җәмгыять мәнфәгате белән яшәп, оста оештыручы буларак, яңа проектларга бик җиңел алынучы шәхес икәнен ассызыклап китү мәслихәт. Ул 1908 елны, Ф. Әмирханның фикерен тормышка ашырып, Г. Тукай белән бергә айга ике тапкыр чыга торган сатирик «Яшен» журналын бастыра башлый. Журналның редакциясе Г. Камал өендә урнашкан булып, аның нәшире, мөхәррире һәм рәссамы йорт хуҗасы үзе була. Алар тирәсенә тупланган иҗади төркем, татар тормышының тискәре якларын ачы тәнкыйтьләп, илһамланып иҗат итә. Ләкин матбаганың 10 саны нәшер ителгәч, акча җитмәү сәбәпле, ул да ябыла. Г. Камал кабат «Йолдыз»га әйләнеп кайта. Шул елны китап сату шөгылен калдыра һәм җиң сызганып язу эшенә керешә.

Г. Камалның оста каллиграф икәнен белеп, Кәримов-Хөсәеновларның китап бастыру фирмасы аны Оренбургка эшкә чакыра. 1911 елны ул гаиләсе белән Оренбургка күченә, ләкин шәһәр үзенә дә, җәмәгатенә дә ошамый. Казанга әйләнеп кайткач, Тукай җитәкчелегендә бастырылган «Ялт-йолт» исемле сатирик журналда берара карикатуралар ясап тора.

1912 елда Беренче Балкан сугышы башлангач, әдип ноябрь аенда андагы вакыйгаларны яктырту өчен Истанбулга бара, ләкин журналистларны фронтка җибәрмәү сәбәпле, мәгълүматларны яраланып кайткан хәрбиләрдән җыярга мәҗбүр була. Юлъязмаларын 14 мәкалә рәвешендә «Йолдыз»да урнаштыра. Аның сугыш шартларындагы төрек җәмгыятенең тормыш-көнкүреше һәм фикер сөреше, илдәге сәяси көрәш хакындагы күзәтүләре тарихи чыганак буларак бүген дә әһәмиятен югалтмаган. Салкын һәм юеш һава, төрек гаскәрләренең җиңелүләре эмоциональ Г. Камалның сәламәтлеген какшата. Ул 1913 елның февралендә авырып китә һәм, командировкасын өзеп, Одесса аша Казанга кайта. Атна-ун көннән бөтенләй кул-аяксыз калып, Казанның нерв авырулары клиникасына керә. Ел ярымнан артык түшәктә ятканнан соң, аякка баса һәм үзенең иҗат эшенә кайта, бер үк вакытта «Йолдыз»да сәркатип булып эшли, тәнкыйть мәкаләләре, чәчмә һәм тезмә әсәрләр бастыра.

СОВЕТ ЧОРЫНДАГЫ ТОРМЫШЫ

1918 елның февралендә хатыны Бибигайшә вафат булгач, Галиәсгар 4 бала белән тол кала. Гражданнар сугышын Аракчинода һәм бер авылда яшәп үткәрә. Шул елны Әсма исемле кызга өйләнә. Бу никахтан 4 бала туа.

Совет чорында ул һәрчак театр һәм артистлар белән бергә була. 1919-1921 елларда Казанда татар запас батальоны клубында татар яшьләре труппасы артисты, аннары «Беренче күргәзмә дәүләт труппасы» хезмәткәре булып эшли. 1923–1924 елларда «Сафьян» клубы труппасында хезмәт куя.

Г. Камал һәм Әсма ханым. 1918 ел.

Беренче бишьеллыклар чорында Казан мех комбинаты клубының әдәбият бүлеген җитәкли.

1924 елда драматургның әдәби эшчәнлегенең 25 еллыгын бәйрәм итү уңаеннан Г. Камалга «Хезмәт Батыры» дигән мактаулы исем бирелә. 1926 елда милли театрның 20 еллык бәйрәмендә Г. Камал «Татар халык драматургы» дигән исемгә лаек була.

Мактаулы һәм шәрәфле исемнәр бирелсә дә, театр тарихы белгече Г. Арсланов фикеренчә, милли идеягә хезмәт итәргә алынган Г. Камалның, 1907–1912 еллар белән чагыштырганда, совет чорында иҗат нәтиҗәләренең нык вакланувы, төссезләнүе күзгә ташлана. Гомеренең соңгы дистә елында әдип күбрәк кече формалы сәхнә әсәрләре – 1 пәрдәлек пьеса, скетч, интермедияләр, эстрада дуэтлары, миниатюралар яза. Бу исемлектән чыгарма буларак, 4 пәрдәлек «Хафизәләм, иркәм!» музыкаль комедиясен генә күрсәтергә мөмкин.

Г. Камал совет хакимияте елларында Казанда нәшер ителгән барлык татарча үзәк басмаларда («Эш», «Эшче», «Безнең байрак», «Кызыл көрәшче», «Татарстан», «Кызыл Татарстан» һ.б.) эшли.

Гомумән алганда, драматургның иҗат мирасы гаять бай: анда 20 ләп драма, төрле теллардән тәрҗемә ителгән 100 дән артык әсәр, күпсанлы публицистик, тәнкыйди язмалар, шигырьләр, үзе ясаган афишалар, карикатуралар, типографияләр өчен шрифтлар һ.б. бар.

Әдип 1933 елның 8 июнендә вафат була. 1937 елгы репрессиягә эләкмәве аны татар иҗтимагый фикере тарихына кертергә, иҗатын мәктәптә өйрәнергә һәм әсәрләренең 3 томлыгын бастырырга мөмкинлек бирә.

ДӨНЬЯ ЧЫНМЫ? Ә БЕЗ ҮЗЕБЕЗ?

Луиза Янсуар

Бу юлы киштәдә – яңа гына прокатка чыккан, ел вакыйгасы буларак күтелгән Скорсезе фильмы һәм Америка язучысы, сценаристы, режиссеры Дэвид Скотт Хэйның үзенчәлекле сатирик романы.

ДӘШМӘҮ ХАКЫ ҺӘМ КИЧЕРҮ ХАКЫНДА...

Фотолар: kinopoisk.ru, film.ru, polyandria.ru

«УБИЙЦЫ ЦВЕТОЧНОЙ ЛУНЫ»

Елы: 2023

Иле: АКШ

Жанры: драма, криминал, вестерн, тарихи, детектив

Режиссеры: Мартин Скорсезе

Сценарий авторлары: Эрик Рот, Мартин Скорсезе, Дэвид Гранн

Рольләрдә: Леонардо Ди Каприо, Роберт Де Ниро, Лили Гладстоун, Джесси Племонс, Танту Кардинал, Джон Литгоу, Брендан Фрейзер, Кара Джейд Майерс һ.б.

Дөньякүләм премьерасы: 20 май 2023, Канны фестивале

Россиядәге һәм дөньядагы башка илләрдәге премьерасы: 20 октябрь 2023

Кинопоисктагы рейтингы: 7,5

Скорсезе фильмы журналист Дэвид Гранн китабына, төгәлрәк әйтсәк, аның осейджлар дип аталган индеецлар ыруы халкы арасындагы үтерүләргә – реаль вакыйгаларга нигезләнгән. Американың иң борынгы җирле халкы булган бу ыру Оклахомага кысрыклап чыгарыла һәм, әллә бәхетләренә, әллә бәхетсезлекләренә, нефть чыганагына юлыга. Осейджлар үз заманының иң бай, затлы кешеләренә әверелә. Әмма аларның байлыгына чын-чынлап ау оештырыла. Ак тәнлеләр бу ыру вәкилләрен үз максатларында куллана, алдау юлы белән тарката һәм юкка чыгара башлый. Скорсезе фильмында вакыйгалар Роберт Де Ниро герое Уильям Хейл һәм аның туганнан туган энекәше, Леонардо Ди Каприо герое, Эрнест Беркхарт образлары аша күрсәтелә. Бу реаль кешеләрнең криминал эше ул заманда беренче адымнарын ясап килгән ФБР ның иң гаугалы процессы булып тарихка кереп калган.

Үтә тәэсирләндерә торган «Ирландец»тан соң, Скорсезе инде «соңгы сүзен әйтте» диючеләр дә табылган иде. Әмма бу ашыгыч фараз булган, күрәсең. «Убийцы цветочной луны» фильмы – өч сәгатьтән артык бара торган катлаулы һәм үзгәреп торучан партитуралы эпопея. Гәрчә ул, беренче карашка, искиткеч интим җепселләрдән үрелгән булса да. Ирексездән, Теодор Драйзер романнары, «Американская трагедия» белән «Финансист» хәтердә калка.

Әйе, чыннан да бу фильм кыргый Көнбатышның агониясе һәм XX гасырның ныклы капиталистик адымнар белән үз максатына атлап юл алуы хакында. Биредә без Европаны дер селкеткән һәм мәңгегә үзгәрткән Беренче бөтендөнья сугышы вакыйгаларын кичеп кайткан солдатны очратабыз. Аның максаты икәү генә – хатын-кызлар һәм акча. Бу акылы әллә ни тирәннән уйланырга җитеп бетмәгән герой образы гаҗәеп дәрәҗәдә таныш тоела... заманга да, җәмгыятьтәге җирлеккә дә.

«Убийцы цветочной луны» Лили Гладстоун белән Леонардо Ди Каприо геройлары арасындагы серле дә, киеренке дә мөнәсәбәтләр белән сокландыра. Реаль вакыйгалар яссылыгына кайтсак, Молли Беркхарт суд процессы вакытында ахыргача Эрнест янына килә торган була һәм карар чыкканга кадәр аны ире дип исәпләвен дәвам итә, диелә. Скорсезе Гладстоун героинясы аша безгә бу җирле халыкның ни дәрәҗәдә тамырлары белән бу җиргә, туфракка гына берекканлеген түгел, ә аларның Вакыт һәм Мәңгелек каршында йөзгә-йөз карап торуларына да басым ясый. Йолаларны башкаручы Молли, инде аягында чак кына басып торырдай хәлдә булса да, нык һәм тыныч булып кала бирә.

Син ахыргача аңлый алмый тилмерәсең: нәрсә бу, мәхәббәтме?! Мәхәббәт шундый була аламыни?! Әйе, Ди Каприо белән Гладстоун каһарманнары аша режиссер, әлбәттә инде, борынгы аборигеннары булган Америка белән, Яңа Җирне яуларга дип, бирегә Европадан кыргый кануннарын алып килгән ерткыч, канечкеч зимагурлар токымын каршы куя. Шул башкисәр-зимагурларның ничек итеп, дәрья кичеп, монда урнашуга, акчага гына түгел, ә «яңача затлылык»ка да дәгъва итүләрен күрсәтә ул. Масон ложаларын осейджлар җирлегендә торгызып, алар белән дуслыкны кул бирешеп ныгытып куйган, ә асылда салкын канлы җан кыючы булган Уильям Хейлның үз дөреслеге – ул Американы бу беркатлы исәр бәндәләрдән тартып алып, үзе шикелле булдыклы кешеләргә бүләк итәргә кирәклегенә чын күңелдән ышана.

Фильмның азагы – үзе бер аерым фильм. Дөресрәге, радиоспектакль. Бу бөтен Америкага билгеле процесска йомгак ясап, режиссер Хейл авызыннан бик тә гыйбрәтле һәм, заманыбызга күрә, коточкыч күрәзәчел яңгырый торган сүзләр әйттерә. Канда коенган осейджлар ыруы вәкилләренең күзләренә туп-туры карап ул болай ди: «Кемгә нәрсә кирәк дип уйлыйсыз? Төкерәләр алар... Берничә ел узуга, бу хәлләрне искә дә алмаячаклар...»

Фильмдагы реаль фотолар белән стилизация ясалган сурәтләр бик көчле тәэсир итә. Җир чәчәккә яралган гына чакта тулган айның символы кимегәннән-кими, халкы һәм җирләре тартып алынган, мәсхәрәләнгән саен Молли хәлсезләнгәннән-хәлсезләнә... Әмма азакта без барыбер аның мул һәм тыныч ритуал кылгандай, Эрнестны кочаклавын һәм... ни генә булмасын... кичерүен күрәбез.

Бәлки, кирәкмидер кичерергә, дип бәргәләнә күңелдә нидер.

Бәлки, кирәкмидер...

Һәм кычкырасы килә... йөрәк ярылганчы, күкрәккә сулышны тутырып, кычкырасы килә, бу фильмны караганда.

Нәкъ Молли, ягъни, юк, үрсәләнгән, кимсетелгән, рәнҗетелгән ырулар, халыклар исеменнән.

Дәшмәүнең хакы күпме икәнен белергә теләүчеләр өчен – карарга, һичшиксез.

КЫЗЫКЛЫ ФАКТЛАР:

- Мартин Скорсезе, Дэвид Гранның «Убийцы цветочной луны» китабын укып чыкканнан соң, шунда ук фильм төшерергә карар кыла.
- Скорсезе осейджлар фильм төшергәндә ярдәм итсеннәр өчен Стоящий Медведь исемле ыру башлыгына берничә ай дәвамында ялвара, ахыр чиктә, ялынулары юкка булып чыкмый.
- Леонардо Ди Каприо баштан башка роль уйнарга тиеш була, әмма ул үзенә Эрнест Беркхарт ролен сорап ала һәм сценарийны үзгәртеп язарга туры килә.
- Яңа сценарий фильмны коммерцияле экшн-триллердан психологик драма яссылыгына күчерә, һәм аны башка студиягә тапшыралар.
- Фильм 100 көн буена Оклахомада осейджлар резервациясендә төшерелә.

БЕР ГЕНӘ КӨНГӘ БЕР-БЕРЕБЕЗНЕ ИШЕТСӘК...

«БУ КИТАП ҺӘМ ТАРИХ ҺӘРКЕМ ӨЧЕН ДӘ ТҮГЕЛ. МОНДА ПОСТМОДЕРНИСТИК УЕН ҺӘМ ИРОНИЯ БӨТЕН ӘСӘРНЕҢ ҮЗЕНЧӘЛЕГЕН БИЛГЕЛИ. ТЕМП, ДИНАМИКА, КОМИЗМ, СҮЗЛӘР БЕЛӘН МӘГЪНӘЛӘР УЕНЫ – АЛАР АРТЫНДА ГАДӘТИ УКУЧЫ ҺӘРЧАК СЮЖЕТНЫҢ ҮЗЕН АБАЙЛАП БЕТЕРМӘСКӘ ДӘ МӨМКИН».

«Поляндрия» сайтыннан

Автор: Дэвид Скотт Хэй

Исеме: «Фонтан»

Нәшрияты: «Поляндрия No Age»

Жанры: хәзерге заман чит ил әдәбияты

Тәрҗемә: Анастасия Рудакова

Елы: 2023

Соңгы арада «Поляндрия» нәшриятында басылып чыккан китаплар үзенең төрлелеге һәм зәвыгы белән аеруча куандыра. Дэвид Скотт Хэй романы да – шундыйлардан. Беренче карашка, бу – безнең һәрберебездә дә яшәгән иҗат һәм талант чаткысы, мөмкинлекләр турындагы роман булса, икенче яктан – үз-үзенә йомылып, тәкәбберлек һәм мин-минлектән, буп-буш шапырынулардан сөрсеп яткан, махинацияләр белән халтурадан тамчы кадәр дә тайчанмаган мәдәни дөньяга ачы сатира, пародия дә.

Фабула ягыннан бар да гади – Чикаго заман сәнгате музеенда «Рәссам бул» дигән күргәзмә кысаларында сынау уздырырга булалар. Һәркем тәкъдим ителгән гап-гади материаллардан (кәгазь, буяулар, тушь, пластилин, каурыйлар, Lego конструкторы һ.б.) заманча сәнгать әсәре тудырып карый һәм «рәссамлыкка» кандидатурасын чыгара ала. Бу, үзенә күрә, шәһәрләрне музейлар белән сәнгать дөньясына җәлеп итү алымы булса, кураторлар һәм сәнгать өлкәсендәге менеджерлар, журналистлар өчен – ставка да. Ягъни алар бу шау-шу тирәсендә үзләренә исем ясый, карьерасын ныгыта яки аны билгеле бер тигезлектә тота, шулай ук газета-журналларга, интернет-платформаларга кайнар, яңа гына табадан төшкән материалларын, фотографияләрен биреп, тамакларын һәм эголарын туйдыра ала. Һәм бу күргәзмә, чыннан да, уңышлы булып чыга: 10 яшьлек малайның пластилиннан ясаган эше белән 70 яшьлек әбинең инсталляциясе «шедевр» буларак бәяләнә, алай гына да түгел,

малай үзенең «шедевр»ын баскычтан төшереп җибәреп, ватып, предмет тирәсендә өстәмә хайп та ясый. Монысы инде сәнгать тирәсендә кайнашып ятучыларны һәм журналистларны бөтенләй шаштыра – алар шунда ук «ачылмаган даһи»лар һәм аларның бәһасе турында сүз көрәштерә, сафсата кайнатырга керешә. Җитмәсә, бу даһилыкның сере дә ачыла, баксаң, малай да, әби дә музей эчендәге фонтаннан су эчкән булып чыгалар.

Шулай итеп, музей белән бу вакыйга тирәсендә чын мәгънәсендә ажиотаж куба. Фонтандагы суны эчкән икәүнең даһилык сәләте ачылганны белеп алган кешеләр агымы музейга чиратка тезелә. Һәркемнең дә таныласы һәм «бөекләр» арасына эләгәсе, үлемсезлек яулыйсы килә. Әмма алар шуны белми: бу даһилык белән бөеклекнең хакы бик кыйммәтле... Озын сүзнең кыскасы, күргәзмә белән музейга өстәмә кызыксыну уятырга тиешле, һәрхәлдә, шуңа йөз тотып уйланган ниятнең азагы бик тә көтелмәгәнчә булып чыга. Фонтанга агылучылар арасында чын мәгънәсендә хаос башлана.

Җитмәсә, автор һәрдаим сылтамаларга мөрәҗәгать итәргә чакыра. Ул сылтамалар, укучы ияләшкәнчә, аңлатма бирү төсмерен генә алып калмый, кайчагында шулай ук мәгънә лабиринтларына алып кереп китә, йә булмаса персонажларның эчке монологларына алып чыга.

Китапта автор бүгенге җәмгыятьне борчыган бик күп мәсьәләләрне күтәрә: сәнгать белән чынбарлык арасында чикләрнең җуелуы нормаль күренешме, әллә юкмы? Сәнгатьнең төп максаты – нәрсәдә, ул кешеләргә тоташ кризислардан һәм тетрәнүләрдән торган, әйтерсең, һәлакәткә таба барган дөньяда юаныч булырга тиешме? Сәнгать кемнәр өчендер бары тик үз амбицияләрен һәм эголарын сыйпаштыру өчен генә кирәкме, әллә иҗат кешесенең нинди дә булса эстетик, этик чикләре булырга тиешме? Һәм, билгеле инде, мәңгелек сорауларның берсе: нәрсә сәнгать әсәрен даһи итә, яисә «шедевр»ларны кемнәр билгели һәм билгеләргә хокуклы?

Дэвид Скотт Хэй роман язарга аны Чикаго музеена бару илһамландырды дип уйлый: «Балалар күргәзмәсе» янында фонтан күрдем дә, башымда уй туды: ә ник әле бу идеяне кулланмаска...» Гәрчә 11 сентябрь белән Чикаго фаҗигасен гәүдәләндерү теләге күптән хыялында булса да, төп этәргеч әнә шул фонтан була, асылда. Үзенең бер әңгәмәсендә ул шулай ук әсәрнең прототиплары турында да сөйли. Ли Бонтеку ретроспективасы аны икенче шедеврны тудыручы әби – Табби героинясын уйлап чыгарырга рухландыра. Бонтеку 60–70 нче елларда бик популяр була, ә аннары онытылуга дучар ителеп, инде бүтән күргәзмәләр оештырмый. Әмма нәкъ менә аның героинясы аша автор безгә сәнгать иясенең танылуы белән чын иҗатның бөтенләй тәңгәл булмавын күрсәтә. Асылда, Бонтеку беркайчан да сәнгатьне ташламый – музейлар белән арасы өзелгәч тә ул үз сараенда иҗат итүен туктатмый.

Күпчелек рецензентлар «Фонтан» бүгенге сәнгатьнең нинди хәлгә барып җитүен күрсәтә, аның чын йөзен ача, дияргә ашыга. Ләкин, игътибар беләнрәк укысак, моның беренче катлам гына булуын аңлыйбыз. Дэвид Скотт Хэй, иң беренче чиратта, геройларының ничек итеп үз амбицияләре һәм омтылышлары колларына әверелүен күрсәтә. Моннан да бигрәк, ул сәнгатьнең сатыла һәм сатып алына торган асылына (ә бу һәркайчан шулай булган, моны бүген генә туган хәл дип уйлау, билгеле, ялгыш) дөньяның максатлары очсызлануын куша һәм кайбер сорауларга җавап якыная төшә дигән тойгы уята.

Әйтергә кирәк, роман гаҗәеп ирониялe һәм саркастик тел белән язылган һәм аны уку, автор безнең белән корган уенны – квестны чишү, детальләр белән символларны «уку» гаҗәеп ләззәт тойгысы бирә.

> – МИҢА ИҢ КЫЗЫГЫ БӘЛӘКӘЙ МАЛАЙ – ТИММИ ОБРАЗЫН ТУДЫРУ БУЛДЫ. ТИММИ – ӘЙТӘСЕ СҮЗЕН ӘЙТӘ ТОРГАН БАЛА, УЛ ОЛЫЛАР КЫЕНСЫНГАН ЯКИ КУРЫККАН НӘРСӘЛӘРНЕ ҖИТКЕРҮДӘН КУРЫКМЫЙ. СҮЗСЕЗ ГЕНӘ ТАБУ САЛЫНГАН ТИЕШСЕЗ НӘРСӘЛӘРНЕ ЯРЫП САЛУДАН ДА. АВТОР БУЛАРАК, МИҢА АНЫ ЯЗУ БИК КҮҢЕЛЛЕ БУЛДЫ. УЛ УҢЫШ АРТЫННАН КУМЫЙ. МИНЕМ МАНЕРАЛАРЫМ КЕМГӘДЕР ЯРАШАМЫ-ЮКМЫ ДИП КАЙГЫРМЫЙ. ДИПЛОМАТИЯ БЕЛӘН МӘШӘКАТЬЛӘНМИ. УЛ – ХАОС ҺӘМ БЕРЕНЧЕЛ ИНСТИНКТЛАР АГЕНТЫ.
>
> Дэвид Скотт Хэй

Роман буенча спектакль чыккач, язучы үзенә ачулы тәнкыйтьчеләр бик каты кизәнгәнен сөйләп көлә: «Без барыбыз да беренче чиратта башкалар һәм җәмгыять алдында нинди булып күренүдән куркабыз», – ди ул. Һәм бик тә мөһим икенче бер фикергә чыгарга өнди: ә нигә без үз хыялларыбыз белән асылыбыздан баш тартудан, үзебезне югалтудан курыкмыйбыз соң?

Әсәрдә кеше асылының бәясе белән җәмгыять безгә куйган маркировка бәясе арасындагы аерманың нинди фаҗигагә китерүе аермачык күрсәтелә. Укучыларыннан алган бер хатта Дэвид Скотт Хэйга мондый сорау бирәләр: «Ә сез үзегез нишләр идегез – фонтаннан эчәр идегезме?» Язучы үзе бу сорауга хат язган укучысының җавабы белән җавап бирергә ярата: «Мин фонтаннан дан белән байлыкка ирешер өчен түгел, ә бер генә көнгә булса да, башкалар минем дә тавышымны ишетсен өчен эчәр идем. Бер генә көнгә булса да...»

Ахыр чиктә, заманыбызның иң төп әнә шул проблемасына алып чыга безне Хэй – әгәр без бер-беребезне ишетергә сәләтле булсакмы... Әгәр...

«Татарстан» журналы үз битләрендә яшь прозаикларның кечкенә күләмдәге әсәрләрен бастыра башлады. Без бу авторларның исемнәрен бик ишетеп-белеп бетермәскә дә мөмкин. Бу – табигый. Араларында әле вакытлы матбугат битләрендә тәүге басылучылары да булачак. Димәк, үзенә күрә сынау, укучы алдында җавап тоту дигән сүз.

Бу кызлар белән егетләрнең заманыбызга, бүгенге көн вакыйгаларына, вазгыятенә үз карашлары, мөнәсәбәтләре бар. Үтә җитди, кискен иҗтимагый темаларга да мөрәҗәгать итә алар, мәңгелек сорауларга да җавап эзли, нечкә хиссияткә бирелеп, парча, нәсер кебек жанрларда да үзләрен сынап карый, юмористик рухта да иҗат итәргә омтылыш ясый.

Нинди ул бүгенге яшьләр прозасы? Кемнәрне дәвам итә алар, йә булмаса, нинди яңалык алып киләләр татар әдәбиятына?

Әйдәгез, укып карыйк.

Рузалия Шакирова

Фото: автордан алынды, pxhere.com

Автор турында белешмә:
Рузалия Шакирова 1994 елның 29 июнендә Әгерҗе районы Салагыш авылында туган. Беренче шигырен җиде яшендә язган. КФУның Алабуга филиалында инглиз теле укытучысы белгечлеге алганнан соң, хосусый укытучы булып эшли, балаларны, өлкән яшьтәгеләрне инглиз теленә өйрәтә. Хәзер Казанда яши. Татар театрына, кинога (бигрәк тә Дэвид Линч, Кристофер Нолан, Ричард Келли фильмнарына), ретро-эстетикага, авыл тормышына, биюгә гашыйк кыз. Ниндидер абстракт нәрсәләрдән логик фикерләр булдырырга, мәгънә эзләргә ярата.

УТЫРЫП УЙЛАР УЙЛАДЫМ...

(парчалар)

ДИСБЕ

Кайвакытта син ниндидер сүз ишетергә тилмереп йөрисең. Син ул сүзне онытасың һәм югалтасың. Бушлык хасил була. Атама бирә алмыйсың эчеңдә булган әйберләргә. Тотыныр әйбер калмый. Ә аннары аны кемдер сиңа әйтә, син аны кайдадыр укыйсың, язганда исеңә төшерәсең. Һәм синең пазлың тулылана. Синдә көч арта. Син бүлешә алу мөмкинлеген тоясың. Сулышың тирәнәя.

Бә-рә-кәт.

Су-лыш.

Я-ра-ту.

Ку-рык-мау.

Кө-лү.

Ях-шы-лык.

Ка-раш.

Син гадиләнәсең. Бер күзәнәкле булып каласың. Әмма бу гадилектән син бик күп нәрсә аласың.

Дус-лык.

Я-шәү.

Шат-лык.

Ты-ныч-лык.

Син сорыйсың. Син бу көннән нәрсә теләсәң, шуны сорыйсың. Дога кыласың.

Эч-кер-сез-лек.

Е-лау.

Син яратуны кичерер өчен нинди зур көч кирәк булуын аңлыйсың. Нәфрәтләнү, качу, нык булып күренергә тырышу аның янында бик кечкенә.

Ба-ры-бер.

Мәң-ге-гә.

Эз-лә-нү.

Ко-чак-лау.

Наз.

Рәх-мәт.

Ха-кый-кать.

Син тагын барлыйсың рәхәтләнеп сүзләрне. Дисбе тарткан кебек. Алар синең намазың бүгенгә. Алар синең «җебең»не табарга булыша. Гыйшык җебен. Чөнки син күптән беләсең: гашыйк булмыйча, яратмыйча тудыра да, туа да алмыйсың син.

Ә-ле-гә.

Ки-лә-чәк.

Бил-ге-сез.

Әм-ма.

Һич-шик-сез.

Хә-ер-ле...

БӘРӘКӘТ

Икенче атна инде борын ис сизми. Минем борын ул борын гына түгел, ә минем ярты йөземне диярлек алып тора торган характерлы үзенчәлек. Аерым бер шәхес, хе-хе. Ул миннән алдан сизә, хәтта миннән аерым яши һәм уйлый да кайвакыт. Шуңа күрә зарымның масштабы да шундый ук зур.

Белмим, нәрсә сәбәп булгандыр: чирме, рецепторларым янып чыктымы шунда, үтә эмоциональ чорны кичергәндә... Йә икесе дәме... Хет нәрсә иснә – борын анестезия астында. Исле майлар, мин яраткан эфлисун исе, үләнле чәй исе, аш исе, миңа шушы шыксыз февральне үтеп-яшәп чыгарга дип бүләк ителгән чәчәкләр исе... – берсе дә юк. Ашаган ашавымның тәме юк, мием туйганны-туймаганны аңламый. Нәрсә белән чагыштырыйм инде... Дөнья төссезләнгән кебек. Тәмсезләнгән кебек. Ниндидер сүз тел очында йөри... Ә!.. Бәрәкәт юк. Бә-рә-кәт.

Бәрәкәт ул эшләгән эшеңнән тәм табу, тәмле телле була белү, кирәкле сүзне әйтеп, кирәкмәгәнен уйлап кына кую, үз-үзеңнән канәгать булу, өлгерү, җыю эффектын «тоту», агым халәтендә булу, аздан да күпне тоя белү, минемчә. Менә мин югалттым шул бәрәкәтне. Югалды да куйды исләр белән бергә. «Юк, сизәсем килми берни дә», – ди киребеткән борын. Ярларымнан чыктым бераз. Йә киптемме... Киресенчә, таба алмыйм үз ритмымны. Кызык...

Июль уртасында гына була торган тымызык тынчу кичтә басу уртасында басып торырга иде хәзер. Көне буе кызып, әлсерәп, салкынча кичтә хәл ала торган яшеллекнең сытылып чыккан дымлы исен тыңларга иде Кама ягыннан искән ябышкак җил астында... Июль исен тыңлап. Кич исен, дөнья шавын туктаткан тургай җырының исен тыңлап. Синең куеныңда гына яңгыраган, синең артерияләреңбуенча гына аккан исне тоеп, бер суларга иде тирән итеп. Бәлки, бәрәкәт кире кайтыр иде шунда миңа. Ә әлегә...

Каршымда – төче чәй. Тәрәз артымда иссез, үле кар ява.

БАШМАКЛАР ҺӘМ КЕШЕЛӘР

Ул зур, аяк киеме белән шыплап тулган кибеткә керде. Күзләр камаша, баш әйләнә хәтта, алмас җиреңнән алырсың бу матуркайларны. Ул бу чаклы зур ассортименттан башта бераз югалып та калды: нинди аяк киеме теләгәнен ул үзе дә төгәл белми иде шул. Якынча, бәлки...

Беренчеләрен ул кергәч үк диярлек күреп алды. Игътибар итмәслек тә түгел: әллә кайдан ук елтыр-елтыр килеп, үзләренә җәлеп итеп торалар. Ул шулай тиз үз «парын» табуына ышанып та җитмәде (әле башкаларны күреп тә өлгермәде ич!), ләкин аяклары аны ирексездән елтырларга таба алып бара иде инде.

Ни кызганыч, соңрак, бу ерактан кукраеп, масаеп ук диярлек торган ботинкаларның бөтенләй карар җире юк икәнен ачыклады ул: бөтенләй юньсез булып чыктылар, хакы да үтә түбән иде аларның. Киштәдә үк алар инде таушалган, арыган булып күренделәр аңа. Ялтыраулары да күңелне күтәрерлек түгел, киресенчә, гарьсез кебек тоелды.

«Артык кычкырып тормый торганнарны эзләргә кирәк», – дип уйлады ул. Тапты да. Матур, тыйнак, ак кроссовкалар. Ныклык, тынычлык исе килеп тора үзләреннән. Тик нишләтәсең, кигәч, аңа бер адым да атларга ирек бирмәде алар: бармаклар кысылды, адымнар чалышланды. Үз аякларында ышанычсызлык сизде ул. Юк, ныклык кына җитми, аның янына сыгылмалылык та кирәк икән.

О! Менә болары икенче эш: җиңел, зәвыклы – аяк боларда биеп кенә тора. Ул шушыларны алырга карар кылды, инде туры килә торган парны эзли-эзли ялыга да башлаган иде. Ләкин бер мизгелдән аруы да, бу парны алу теләге дә юкка чыкты: бу гадиләрнең хакы бер дә гади түгел иде. Аның бу хәтле акчага аяк киеме алу түгел, баштанаяк киенгәне дә юк. Ул күзләрен йомды, моңсу елмайды һәм алга таба эзләнүен дәвам итте.

Аннары бик матурларын тапты. Бик уңайлыларын да. Киеп карады – кимчелексез. Тик нидер җитми иде барыбер. Нәрсә икәнен ул үзе дә аңлап җитмәде. Бәлки, кая киям инде мин боларны, дигән уй тынычлык бирмәгәндер. «Ну, әни! – дип уйлап куйды ул эченнән генә. – Кечкенәдән кием алганда «и в мир, и в пир» дип алырга өйрәттең дә... Менә йөрим хәзер...»

Ә бәлки миңа бөтен шартларга да туры килерлек аяк киеме эзләргә кирәкмидер? Кем идеаль пар бар дип әйтте соң әле? Берсе булсын көн дә кияр өчен, берсе – ял көннәрендә йөреп кайтырга, өченчеләре, тугры дус кебек, ерак юлга чыгып китәргә дә яраклы, дүртенчеләре, ныклы беләккә тотынып кына, сак кына, ашыкмыйча гына, кичке шәһәр буенча атлар өчен...

Кинәт аның карашы касса янындагы матур тышлы язу китапчыгына төште. Кибеттәге бөтен парлар турында онытып, ул сатучы янына таба китте. Китапчыкны һәм аның янына каләм алды һәм үзенең яраткан кедаларында чыгуга таба юл тотты. Аңа шушы зур кибет эчендә үзе ошаткан бер парны да таба алмавы турында язарга кирәк иде.

ЯМЕ?

Исәнме, әни! Ничек хәлләрең? Карале, мин сиңа нәрсә алып кайттым!

Укып бетергән китабымны алып кайттым. Әйе, мин сиңа аның турында сөйләгән идем. Син дә укырсың, сиңа ошаячак, анысында шикләнмәсәң дә була. Ул көчле хатын турында. Чибәр хатын турында. Авыр язмышлы хатын турында. Нәкъ синең кебек, әни. Укы, яме?

Мин сиңа тагын чәй алып кайттым. Аны ничек яратканыңны беләм, гәрчә миңа әйтмәсәң дә. Тик аны безнең авылда сатмыйлар. Кичләрен утырып эчәрсең, яме?

Тагын сиңа фотосурәтләр алып кайттым. Монысы – җәйгеләре, болары – Яңа елдан калганнары. Көн саен диярлек телефоннан җибәреп торсам да, фотоларның менә шундый кулга алырлыклары кадерлерәк нигәдер. Монда без бергә. Сагынганда карарсың, яме?

Әни, мин сиңа тагын яңалыклар алып кайттым. Алга таба планнарымны алып кайттым, борчулар да иярде бергә. Минем белән иртәнгә кадәр сөйләшеп, уйларымны агартырсың әле, яме?

Мин сиңа безнең арада искән җилләрне тындырырга дип кайттым. Арабызга ява биргән карларны көрәргә, үзгәңә үткән тынычлыкны бозарга дип кайттым. Әни, карале, бөтен тормышымны алып кайттым сиңа. Чәй куй. Утыр әле өстәл артына. Ерак араларны юк дип уйлыйк әле, яме?

Чын әйтәм. Минә көн дә бәйрәм, көн дә туй бит синдә, уйлап карасаң. Дөнья, син яхшы бит. Мин синдә саклаучы табам, мин синдә дус күрәм, мин сиңа йокы алдыннан рәхмәт әйтәм, иртә белән сине сәламлим. Дөньям минем! Синдә күпме моң, күпме җыр, күпме чәчәк, күпме елмаю, хыялыйлык, исәрлек, урынсыз көлү, юкка гына да сөенү. Синнән «эх» дигәнче җәннәт ясап булыр иде...

Дөнья, син шундый хикмәтле бит. Үпкәләсәң, тагын да ныграк мыскыллыйсың, авыз ерып йөрсәң, баштан сыйпыйсың, өсте-өстенә сөендерәсең. Син иң шәп укытучы да бит. Сүзсез генә аңлатасың син барысын да. Вакыт ярдәмендә, югалтулар хисабына аңлатасың, аңласаң аңлыйсың синең дәресләреңне, аңламасаң – юк. Йә баштан ук аңлавың, аңламасаң, бөтенләй баш ватмавың хәерле.

Дөнья, син иң җылы, рәхәт өй бит. Минә син. Ә минә мин – синең кунагың, берни дә аңлый алмыйча, басып торам. Нәрсәгә килдем мин кунакка? Кемгә килдем? Ни кирәгем калган монда? Ә син миңа күз кысасың, мыек астыңнан гына елмаясың. Җавап бирмисең. Ә миңа җавап кирәкми дә. Мин кунак ич! Кунак кеше рәхәтләнеп, хуҗа әзерләгән сый-хөрмәтләрдән авыз итеп, җырын сузып, рәхмәт укып, тик утырырга тиештер инде ул!

УКЫРГА «ӨЙРӘНҮ» ТУРЫНДА

Мин бик тыныч мохиттә үстем. Артык тынычтыр да, бәлки. Әни гел мәктәптә, эштә иде, өйдә – күбесенчә бабай, әби йә ишегалдында нидер мыштыр-мыштыр эшли, йә өйдә ашарга пешерү, йон җегерләү, идән-сәке юуише нәрсәләр белән мәшгуль. Әбине хәтерләмим дә диярлек. Ул ниндидер мине яклардай тыл, җылы тойгы булып кына истә калган. Утырып торганын да хәтерләмим мин аның: гел эштә, тынгысыз бал корты кебек. Бабай бик кырыс, коры, күп сөйләшергә яратмый торган кеше иде. Мин читтән генә аның тартылып беткән фильтрсыз «Прима»ларыннан калган чүптән яңа тәмәке ясаганын, әллә ничә детальдән торган кырынгычын ашыкмыйча гына җыюын, пумаланы кап-кайнар суда чылатып, аннан сабынга ышкып күбекләтүен, сак кына сакалын кыруын карап тора идем. Әмма ничек кенә җайлап кырынмасын, бабайның битләрендә кечкенә яралар була иде, һәм ул аларны шундый ук кечкенә һәм юка гәҗит кисәкләре белән каплап куя иде. Сөйләшү юк инде бабай белән, бик теләсәм дә. Әмма күзәтүе кызык. Хәзер дә аны бик сагынам, хәзер булса, сөйләшер идем рәхәтләнеп аның белән, дип уйлыйм.



Иллюстрация: Виктор Калинин «Старик у печки», 1968

Картлар белән сөйләшергә кирәк, сөйләшә белергә кирәк. Балалар белән дә шул ук хәл. Икесенең дә телләре сүтелсә, бик үтемле, бәрәкәтле сөйләшү килеп чыга. Гүя син үткән һәм киләчәк белән сөйләшәсең. Мин бик тә безне калдырып киткән якын картларымны сагынам: үз әбием Вәсимәне, күрше әбием Мәрьямне, Мөхтәр бабамны, үги әтием йортында торганда безнең күрше булган Вәгыйзь бабайны. Бирәсе сорауларны, әйтәсе җылы сүзләрне әйтеп калдырырга иде яраткан кешеләребезгә. Алар исән чакта. Без исән чакта да.

Миңа бер дүрт яшьләр булгандыр. Бабай белән тынлыкны уртаклашып утырган җәйге көннәрнең берсе. Телевизор карап туеп, мин яраткан шөгылемә – кырыс кешене күзәтүгә керештем: гәҗит укып утыра. Бераздан морҗа янына тартырга китте. Бабай гел өйдә тарта иде, җәй диме, кыш диме. Мин сак кына аның караваты янына килеп утырдым, йорттагы бердәнбер кешене күз уңыннан югалтмас өчен. Янымда – яңа гына укылган гәҗит. Сәкедә утырганда башка кызык табып булмас инде, нинди кызык нәрсәләр бар икән шушы кыштырдавык юка битләрдә, дип, мин гәҗитне кулыма алдым. Бабай тәккә генә сәгатьләр буе текәлеп утырмый бит инде аңа! Барыбер күңелсез, барыбер эшләр эш, сөйләшер кеше юк, ник укымаска? Каян хәрефләрне белгәнемне, ничек шулай җиңел, әллә кайчан өйрәнгән кебек укып китүемне хәзер дә аңлата алмыйм. Күрәсең, кызык эзләү, аралашу җитмәү шултиклем көчле булган. Бераз эчемнән генә укыганнан соң, тәмәке көйрәтеп утырган бабайга мәзәк укыганым истә.

Минә шулай «от скуки» укый башладым мин. Шунысы кызык: хәзер дә күп нәрсәне шул принцип буенча эшлим. Ямансулыктан качу, ялкаулыгымны җиңеп, нәрсәдер эшләр өчен иң зур этәргеч булып тора.

ФЕРМЕРЛАР – АВЫЛ ТАЯНЫЧЫ



Гөлсем Спасская

Татарстан авыл хуҗалыгы продукциясенең күпме өлеше гаилә фермаларында һәм шәхси хуҗалыкларда җитештерелә? Фермерлар ни өчен кооперативларга берләшә? Крестьян хуҗалыкларына дәүләт ярдәме җитәрлекме? Хәбәрчебез ТР Фермерлар, крестьян хуҗалыклары һәм авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативлары ассоциациясе президенты Камияр Мөҗәһит улы Байтимеров белән әнә шулар хакында әңгәмә корды.

– Камияр әфәнде, республикада фермерлар ассоциациясе оешканга 32 ел узды. Аның ул вакыттагы һәм бүгенге төп максатлары нинди, күп нәрсә үзгәрдеме?

– 1991 елда ил хөкүмәте алдында гадәти булмаган бурыч – колачлы социаль-икътисадый реформаларны башлап җибәрү бурычы тора иде. Әгәр сүз җирдә эшкәртеп, иген игеп яшәүче кешеләр турында бара икән, бу реформаторлык эшенә кемне җәлеп итәргә кала? Әлбәттә, крестьяннарның үзләрен, ләкин яңа карашлыларын. Фермерлар мәнфәгатен яклау һәм күтәреп чыгу өчен, аларның ассоциациясен төзү гаять мантыйкка яраклы гамәл булды.

Эшкә керешкән чорда төп максат – мөстәкыйль, кагыйдә буларак, гаилә фермерлык хуҗалыкларын булдыруны алга сөргән ассоциация әгъзаларының мәнфәгатьләрен яклау миссиясен хәл итә алдык.

Фермерлыкка алынырга теләүчеләр күп түгел иде. Акча мәсьәләсе һәм башка проблемалар белән тартыша алмаганнар эшне ташлады. Чын мәгънәсендә үҗәтләр генә калды. Үзе, гаиләсе һәм туган ягы өчен тотрыклы киләчәк булдырырга теләгәннәр генә.

Бүген безнең максатлар, әлбәттә, күпкә зуррак, күпкә киңрәк. Терлекчелектә, кошчылыкта, үсемлекчелектә кече хуҗалык формаларының өлеше Татарстанда елдан-ел үсә. Фермер хуҗалыклары аякка баскан елларны карасак, мәсәлән, 1996 елда фермерлар милкендә яки алар кулында арендада 26,8 мең гектар җир булган. Алар барлыгы 800 гә якын кеше иде. Бүген исә фермерлык хуҗалыклары 764 мең гектар тирәсе җиргә ия. Бу республикада чәчүлек мәйданның өчтән берен тәшкил итә диярлек. Ә фермерлар, крестьян хуҗалыклары һәм авыл хуҗалыгы кооперативлары җитештерә торган тулаем продукция күләме тотрыклы рәвештә арта бара һәм соңгы елларда республикада җитештерелә торган барлык авыл хуҗалыгы продукциясенең гомуми күләменең яртысын, хәтта аннан да күбрәк өлешен алып тора. Бу исә Татарстанның агросәнәгать секторында фермерларның лаеклы урын алып торуын белдерә. Әмма шундый зур үсеш динамикасына карамастан, әле менә үрләр, яулыйсы уңышлар җитәрлек, ассоциация әгъзалары да, фермерлар үзләре дә моңа ихлас ышана. Бүген төп максатыбыз шуннан гыйбарәт.

– Фермерларның һәрвакыт кредит алу белән проблемалары бар иде...

– Әйдәгез, тәртип белән карыйк. Фермерлык үсә барган саен, җир кешеләре акрынлап шуны аңлады: ит-сөт ише чимал сату, әлбәттә, шәп, ләкин аны эшкәртеп сатуны күздә тоткан җитештерү эшен җайга салганда, бөтенләй башка төрле саннар булачак. 2006 елда, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Агросәнәгать комплексын һәм хуҗалык итүнең кече формаларын үстерү турында» карары кабул ителгәннән соң, ассоциация авыл хуҗалыгы кулланучыларының кредит кооперативларын үстерүгә алынды. Һәм эш уңышлы килеп чыкты! Шундый еллар булды ки, кооперативларыбыз фермерларга һәм крестьян хуҗалыкларына биргән кредит күләме Татарстанның барлык банклары бергә биргән кредитлардан күбрәк иде.

Тик шунда 2008 ел кризисы башланды. Әйе, дәүләт субвенцияләр бирде, тик алар банкларга гына юнәлтелде, ә без исә исән калу өчен үзебез тырмашырга тиеш идек. Ассоциация тарафыннан гамәлдәге финанс кооперативларын авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативлары итеп үзгәртеп корырга дигән карар кабул ителде. Әлеге кооперативлар авыл хуҗалыгы продукциясен эшкәртү, тәэмин итү һәм сату белән шөгыльләнергә тиеш дип планлаштырылды. Әүвәлге пай-

Фото: tatar-inform.ru

чылар бурычлары белән бергә шунда күчтеләр. Минемчә, бу ул вакытта бердәнбер дөрес карар булды. Һәрхәлдә, без әлеге авыр чорны финанслар һәм кешеләр мәсьәләсендә иң аз югалтулар белән кичерә алдык. Россия төбәкләрендә фермерлар белән бәйле кайгылы хәбәрләр җитәрлек булды. Бүген республикада 336 кооператив эшли.

– Фермер хуҗалыкларына ярдәм итү өчен дәүләт җитәрлек дәрәҗәдә акча бүлеп бирәме?

– Быелтыр фермерлар беренче тапкыр 1 млн 300 мең тонна ашлык җитештерде, быел – 930 мең тонна җыеп алынды. Без, тулаем авыл хуҗалыгы продукциясенең яртысын диярлек җитештереп, аграрийларга бүлеп бирелгән бюджет акчаларының якынча 20 процентын гына алабыз. Минемчә, бу бик үк гадел түгел...

– Әмма фермерлар эшли һәм алар булдыра. Бөтен көч-гайрәтне куллану хисабынамы?

– Фермерлар – оптимистлар, дип уйлыйм. Һәм алар үз көчләренә генә өметләнә. Алар үз җирләрендә чын хуҗа, үз хезмәт җимешләрен үзләре куллана. Алар берьюлы өч вазыйфаны башкара: бер үк зат эшче-хезмәткәр дә, идарәче дә, эшмәкәр дә. Авылының, гаиләсенең киләчәге өчен бөтен җаваплылык аңарда. Бу үзенә бер төрле мотивация тудыра да. Иң мөһиме, фермерларга эшләргә һични комачауламасын. Ә тискәре, күңелсез күренешләр һәрвакыт бар...

– Мәсәлән?

– Россиядә фермер хуҗалыклары эшчәнлеге крестьян (фермер) хуҗалыгы турындагы 74 нче Федераль закон белән көйләнә. Шуңа бәйле рәвештә ассоциациябезнең төп миссиясе – фермерларның һәм крестьян хуҗалыкларының хокукый һәм икътисадый мәнфәгатьләрен яклау. Моның өчен без төрле министрлыклар һәм ведомстволар, хакимият органнары, депутатлар белән хезмәттәшлек итәбез. Татарстанныкы белән генә дә түгел.

Россия крестьян (фермер) хуҗалыклары һәм авыл хуҗалыгы кооперативлары ассоциациясе (АККОР) президенты Владимир Плотников – Дәүләт Думасындагы Аграр мәсьәләләр комитеты рәисенең беренче урынбасары. Шуңа күрә Дәүләт Думасына кертелә торган закон проектларын карау мөмкинлегебез бар. Югыйсә, закон кабул ителгәч, каршылыклар килеп чыгуын көт тә тор. Менә бер мисал: Россия парламентына фермерлардан чимал җыеп, аны эшкәртә һәм сәүдә челтәрләренә әзер продукт сата торган агрегаторлар булдыру турында закон проекты кергән иде. Моның фермерлар өчен һәлакәт икәнен аңлыйсыздыр. Бәхеткә, без канунны яңадан эшләү өчен дип, кире кага алдык.

– Ә аннары нәрсә?

– Хәзер ул агрегаторлар ниндидер чит структуралар түгел, ә безнең авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативлары булсын өчен тырышабыз. Ә республикада аларның иң зурысы агросәнәгать паркы булырга тиеш, ул башта ук шуның өчен корылган иде. Анда бит сәүдә заллары гына түгел, эшкәртү мәйданчыклары да тупланган. Безнең фикеребезчә, әзер авыл хуҗалыгы продукциясен сәүдә челтәрләренә китерү белән нәкъ менә ул шөгыльләнәчәк. Планнарыбыз – Татарстан җирендә җитештерелә торган бөтен нәрсәнең – ит, сөт, бөртекле ашлык, яшелчә бәясен формалаштыра торган биржаны да шушында булдыру.

– Татарстанда әле яңа гына эшкә керешеп килгән фермерларның күбесе грант программаларында катнаша ала. Алар арасында үзенчәлекле, без күрергә күнекмәгән грант алучылар бармы?

– Андыйлар аз түгел. Безнең ассоциациягә Буа районыннан Дәүләтшиннар гаиләсе килде. Бакчаларга грант ярдәме программасы бармы дип сорыйлар? Ә андыйлар юк иде...

ФЕРМЕРЛАР АВЫЛДА ЯШӘҮЧЕ КЕШЕЛӘР ӨЧЕН ГЕНӘ ТҮГЕЛ, ҖИРЛЕ ХАКИМИЯТ ӨЧЕН ДӘ ЧЫН ТЕРӘККӘ ӘЙЛӘНДЕ. Ә БУ ИСӘ ТАТАРСТАН КРЕСТЬЯН ХУҖАЛЫКЛАРЫНЫҢ ЗУР ПОТЕНЦИАЛГА ИЯ ИКӘНЛЕГЕН КҮРСӘТӘ.

Нәтиҗәдә, ул вакытта Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры булган Марат Әхмәтов ярдәме белән без аларның проектын грант ярдәме программасына кертә алдык. Бүген Дәүләтшиннар бакчасы – Татарстанда иң яхшы бакча, ә бәлки бөтен Идел буе федераль округында да иң яхшысыдыр. Анда алма, карлыган, кура җиләге, җиләк үстерәләр. Икенче фермер – Альфред Хәйруллинның Чүпрәле районында 147 га алмагач бакчасы бар, кура җиләге, җиләк һәм карлыган да үстерә. Шулай ук грант ярдәме белән. Ассоциация съездларында әйтелә торган тәкъдимнәр Татарстан Республикасы агросәнәгать комплексы һәм, гомумән, Татарстан Республикасы өчен кирәк булып куя ала.

– Камияр әфәнде, бүген авылның төп проблемасы нидә дип саныйсыз?

– Соңгы елларда авылдан эшкә яраклы 103 мең кеше китте. Бу күренешкә күпчелек агрохолдинглар басымы арту гаепле дип саныйм: алар җитештерүне бер урынга туплый һәм вак хуҗалыкларны кысрыклап чыгара. Авылы белән эшсез калучылар бар, күнегелгән тормыш рәвеше җимерелә. Бу – төп авырткан урыныбыз.

– Ассоциациянең нинди казанышы, сезнеңчә, иң мөһиме?

– Безнең тирәдә фермерлар тупланды. Һәм безне, ниһаять, ишетә башладылар. Фермерларның авыл территорияләрендәге йогынтысы үсә башлау да әһәмиятле. Фермерлар авылда яшәүче кешеләр өчен генә түгел, җирле хакимият өчен дә чын терәккә әйләнде. Ә бу исә Татарстан крестьян хуҗалыкларының зур потенциалга ия икәнлеген күрсәтә. Хезмәтебезнең иң мөһим максаты шунда: «фермер» тамгасы сугылган продуктлар һәрвакыт үз сатып алучысын таба. Т

«КАЙМАК» ФЕРМЕР КҮҢЕЛЕНӘ ХУШ КИЛӘ

Сөт, эремчек, сөт өсте, каймак, кефир, катык, корт, атланмай, берничә төр сыр: «голландский», «российский», «адыгейский»... Бүген әлеге сыйфатлы продукциянең барысын да бер предприятие – Сабадагы «Каймак» авыл хуҗалыгы тәэмин итү-сату кулланучылар кооперативы җитештерә. Аның барлыкка килү тарихы кооперативка берләшүнең фермер хуҗалыклары мөмкинлекләрен күп тапкыр арттыруына иң яхшы үрнәк булып тора.

Бүген «Каймак» кооперативы Саба районының 20 дән артык фермер хуҗалыгын берләштерә. Бу хуҗалыкларда элек-электән җиң сызганып, көчләрен кызганмыйча эшли беләләр, әмма базар икътисады сынауларын кайчак ялгызлары гына үтеп чыга алмыйлар. Савылган сөтне лаеклы бәягә сатарга тырышып, күпме тир түккәннәрен, күпме көч сарыф иткәннәрен хәтта искә дә төшерәселәре килми. Шуңа күрә, авыл хуҗалыгы кооперативын оештыргач, беренче эш итеп, үз эшкәртү куәтләрен булдыру турында уйланалар. Бу чорда оешманы Айнур Мостафин җитәкли.

Дөрес сайланган стратегия һәм дәүләт тарафыннан үз вакытында күрсәтелгән ярдәм синергетик нәтиҗә бирә. 2016 елда «Татарстан Республикасында авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперациясен үстерүгә» грант алгач, «Каймак» сигез миллион сумның барысын да сөт эшкәртү цехын төзүгә һәм аңа кирәкле җиһазлар алуга тота. Бер сменада өч ярым тонна сөт эшкәртергә сәләтле цехны эшләтеп җибәрүгә, фермерларның савылган сөтне сату проблемасы хәл ителә.

«Без үз дәрәҗә-абруебызның кадерен белабез, шуңа күрә табигый һәм сыйфатлы продукция генә җитештерәбез. Якыннарыбызның сәламәтлеген кайгыртабыз!» – дип тәкъдим итә «Каймак» үз продукциясен бер маркетплейста. Кооперативның майлары, сөт-кефирлары, сырлары чыннан да сыйфатлы һәм экологик яктан чиста, бу мәҗбүри рәвештә үткәрелә торган даими ветеринария контроле белән дә раслана. Башкача булуы мөмкин дә түгел – җирле фермерлар сөтбикәләренә табигый, һәр яктан балансслы азык кына ашата. Тагын бер мөһим күрсәткеч – кооператив продукциясенә ихтыяҗ тотрыклы. «Каймак»ның сөт продуктлары Казанда гына да 60 тан артык кибеттә сатыла. Үзләрендә җитештерелгән май, сөт, эремчек, сырларны Байлар Сабасының үзендә дә, якын-тирә районнарда да бик теләп сатып алалар. Кооперативның табигый продукциясе Саба районының социаль учреждениеләренә, мәктәпләргә һәм балалар бакчаларына да җибәрелә.

Бүген «Каймак» авыл хуҗалыгы кооперативы белән Фирдәвес Мостафин җитәкчелек итә. Улы Айнур хәзер үз фермер хуҗалыгын җитәкли, 10 миллион сумлык грант акчасына ул Кукмара һәм Саба районнарында үгез симертү комплекслары төзеп куя. Кече улы Айдар да терлекчелек тармагында эшли, «Уңыш» крестьян-фермер хуҗалыгын җитәкли.

Сүз уңаеннан, Байлар Сабасындагы кооператив ирешелгәннәр белән канәгатьләнеп, тукталып калмый. Аның әгъзалары, чимал түгел, ә эшкәртү продуктларын сату ни дәрәҗәдә отышлырак булуын үз тәҗрибәләрендә төшенеп, ассортиментны киңәйтә һәм җитештерүне үстерә. Бүген исемлектә 15 төрдән артык продукция бар, өстәвенә «Российский», «Голландский» һәм шулай ук сулугуни сырлары тагын бер җитди проектны гамәлгә ашыру нәтиҗәсе булып тора: үз сыр кайнату цехын төзү һәм эшләтеп җибәрү өчен, «Каймак» 19 миллион сум акча кертә. Бу юлы да республика җитди ярдәм күрсәтә: югарыда телгә алынган 19 миллион сумның 7,6 миллионы – кооперативларның матди-техник базасын яхшыртуга грант акчасы, 6 миллион сумнан артыгы бурычка алынган, калганы – үз акчалары. Дәүләт, җирле хакимиятләр ярдәменнән, ТР Фермерлар, крестьян хуҗалыклары һәм авыл хуҗалыгы кооперативлары ассоциациясе булышлыгыннан башка, «Каймак»ның бүгенге үрләрне уңышлы яулаган булуы икеле, дип саный Фирдәвес Мостафин. Моның белән килешми мөмкин түгел. Икенче яктан караганда, «Каймак» та бик күп нәрсәне тормышка ашыра. Яңа эш урыннары, лаеклы хезмәт хаклары, фермерлар өчен сөт сату базары, бюджетка салым – болар барысы да «Каймак» белән бәйле. Әүвәл кооперативка аякка басарга ярдәм күрсәтсәләр, хәзер инде кооператив, үз чиратында, авылда социаль мәсьәләләрне чишәргә булыша, төрле хәйрия проектларында катнаша.

Тормыш шуны исбатлады: хезмәт, җир, акча, транспорт һәм башка ресурсларын кооперативка берләштереп, фермерлар алардан файдалану нәтиҗәлелеген арттырып кына калмый, ә авылларның үсешенә дә яңа этәргеч бирәләр. Саба авыл хуҗалыгы кооперативының тәҗрибәсе һәм үрнәге моның иң яхшы дәлиле булып тора.

Уңышлары һәм планнары турында сөйләгәндә, «Каймак» кооперативында предприятиенең барлыкка килүендә һәм үсешендә ТР Фермерлар, крестьян хуҗалыклары һәм авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативлары ассоциациясенең, аның җитәкчесе Камияр Байтимеровның даими ярдәме, чын күңелдән катнашып йөрүе мөһим роль уйнаганын һәрвакыт телгә алалар.

«Каймак» авыл хуҗалыгы кооперативы коллективы Камияр Мөҗәһит улын чын күңелдән юбилее белән котлап, аның күпкырлы авыр хезмәтендә уңышлар тели.

Фотолар «Каймак» авыл хуҗалыгы тәэмин итү-сату кулланучылар кооперативыннан алынды. РЕКЛАМА

ҖИРДӘ ХЕЗМӘТ ИТҮ – ТОРМЫШ НИГЕЗЕ

Актаныш районындагы Чалманарат авыл җирлеген фермерлар башкаласы дип танырга вакыттыр, мөгаен. Мондагы хуҗалыкларда 800 баштан артык мөгезле эре терлек асрыйлар. Ә крестьян-фермер хуҗалыклары саны берәү-икәү генә түгел, ә алтау!

Хуҗалыкларның барысы да нык, хәлле. Кошчылык тармагында, мәсәлән, казлар саны биш меңнән арта, үрдәкләр исә аннан да күбрәк. Ат үрчетү белән шөгыльләнә торган хуҗалык та бар, калганнары сөтчелек һәм итчелек белән мәшгуль. Газинур Әмиров крестьян-фермер хуҗалыгы әлеге эшсөярләр арасында аерым игътибарга лаек. Бу башкалардан алданрак, әле 2009 елда ук нигезләнгәнгә түгел. Аның хуҗалыгы – туган җирдә бизнесны алып бару, нәтиҗәле эшләү, эзлекле рәвештә алга бару һәм туган авылыңны үстерүгә бар көчеңне бирү үрнәге ул.

Әмиров үзен авыр крестьян хезмәтеннән башка күз алдына китерә алмый торган кешеләрдән. Ул 25 елдан артык «Агыйдел» колхозында хезмәт куя, әүвәл тракторчы була, колхозлар کояшы сүнгән чакта инде инженер вазыйфасын башкара. Коллектив хуҗалык «бакыйлыкка күчкәч», Газинур Әхтәм улы моны үзенең шәхси кайгысы дип кабул итә. Ләкин кул кушырып кайгырып утыру аның холкына туры килми, шуңа күрә эшкә керешергә карар кыла. Крестьян-фермер хуҗалыгын җитәкләр өчен тәҗрибәсе һәм белеме артыгы белән җитә, ә менә финанслар һәм матди як күпкә начар. Гаилә фермасын төзүгә грант Әмировка ниятне тормышка ашыру өчен искиткеч зур этәргеч була. Алгарак китеп, соңрак тагын бер грант алуын да әйтеп үтик, анысы КФХның гаилә фермасын үстерүгә бирелә. Аңлаганыгызча, бу факт хөкүмәт биргән һәр сумның Әмиров тарафыннан эш өчен максималь файда китерерлек итеп сарыф ителүенә иң яхшы дәлил булып тора.

Ферма, бозау абзары, 49 елга арендага алынган 640 гектар җир, трактор... Болар барысы да грант итеп бирелгән миллион бәрабәренә сатып алына һәм төзелә. Бу миллионга күпме авыр хезмәт өстәлгәнен, күпме тир түгелгәнен санап бетерерлек түгел. Аның караве, нәтиҗә күз алдында: хуҗалык хәзер аякта нык басып тора, уңышлары белән елдан-ел сөендерә килә. Фермер Әмиров хуҗалыгында бүген – 80 баш савым сыеры, 40 тан артык тана, 40 бозау, симертеп сатуга дигән ике дистә үгез, сарыклар...

КФХдагы савым һәм артым күрсәткечләре мактауга лаек, бу бер дә гаҗәп түгел. Җәйге көтүлек яхшы болында көйләнгән. Арендага алынган җирләрдә бөртекле культуралар, күпьеллык үләннәр, кукуруз үстерәләр, шул рәвешле ышанычлы азык базасы тәэмин ителә. Үз комбайны, «КАМАЗ»ы, башка кирәкле техника чәчүне, урып-җыюны вакытында башкарып, яхшы уңыш алырга мөмкинлек бирә.

Хуҗалык төп керемне ит һәм сөт сатудан ала. Көн саен 900 литрга якын сөт савалар, ул үз сыйфатын мөмкин кадәр озаграк сакласын өчен, махсус суыткыч танк сатып алынган. Ферма кечкенә түгел, эш бик күп. Боларның барысын да кем тартып бара?

– Хатыным Гөлфинә белән бер таңнан икенче таңгача эшлибез, ул һәм аның дус кызы сыер саву өчен җаваплы. Төп ярдәмчем – улыбыз Илнур. Аның хатыны Гөлназга да эш җитәрлек, – дип сөйли Газинур Әмиров. – Туганнан туганнарым Илфиз һәм Дамир Мөхәммәтдиновлар да КФХда эшли. Кызыбыз гаиләсе белән Актанышта яши, әмма кияү, кайткан чагында, һәрвакыт булыша...

Сүз уңаеннан, әтисенең үрнәге Илнурга киләчәк тормыш юлын сайларга ярдәм итә. 2016 елда ул үзенең фермер хуҗалыгына нигез сала, бүген инде анда 43 сыер һәм өч ат бар. 200 башка исәпләнгән ферма да төзи башлаган. Шулай итеп Илнур Әмиров үз эшен дә уңышлы үстерә. Өстәвенә, зирәк киңәш сорап, ерак барырга кирәкми: икенче буын фермер төзегән яңа йорт әти-әнисе яшәгән урамда, алар каршында гына.

Унбиш елга якын фермерлык хезмәте дәверендә Әмиров табышлы хуҗалык һәм эш урыннары булдыру гына түгел, туган авылына да җан өргән булып чыга. Эш бар, перспектива бар – шулай булгач, нигә дип әле туган җирләрдән китәргә ди? Уң барса, балалар гына түгел, оныклар да үз җирләрендә эшләр әле. Авылдашларының балалары, оныклары да... Авыл ихтыяҗларына акча биреп, мохтаҗларга булышканда, Газинур үзенең изге миссиясен дәвам итә. Һәм ирешелгәннәрдә тукталырга җыенмый да. Үзенең сөт эшкәртү һәм ярымфабрикатлар цехын эшләтеп җибәрергә хыяллана ул.

Сатып алу бәяләре мәсьәләсендә генә өметләрне җимермәсеннәр, ә минем КФХ колачлы планнарны һичшиксез ерып чыгачак, ди фермер. Хезмәт сөючәнлек тел-теш тидерерлек түгел, ә дәүләт ярдәме, җирле хакимият булышлыгы көч бирә. Һәм, әлбәттә, барлык КФХларның ышанычлы терәге – Татарстан Республикасының Камияр Байтимеров җитәкчелегендәге Фермерлар, крестьян хуҗалыклары һәм авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативлары ассоциациясе.

– Камияр Мөҗәһит улы фермерлар мәнфәгатен һәркайда яклый, – ди Газинур Әмиров. – Аның ярдәме безгә бик җитди проблемаларны хәл итәргә булыша, аның киңәш-тәкъдимнәре һәрвакыт файдалы һәм урынлы. Моңа гаҗәпләнәсе дә юк, чөнки ул үзе дә – яшәү мәгънәсен җирдә хезмәт итүдә тапкан тынгысыз фермерлар вәкиле.

Камияр Мөҗәһит улын ихлас күңелдән юбилее белән котлыйм!

Фото Газинур Әмиров архивыннан. РЕКЛАМА

СЫЙФАТЛЫ КОШ ИТЕ ҖИТЕШТЕРҮЧЕЛӘР

Әгәр берләшсәләр, тыйнак фермер хуҗалыклары нинди уңышка ирешә алыр иде? Мамадыш районындагы «ЭкоПтица» авыл хуҗалыгы кооперативы мисалы әлеге сорауга иң яхшы җавап булып тора. Бу кооперативның экологик чиста продукциясенә Татарстанда да, аннан читтә дә ихтыяҗ зур.



Бөтен вак-төягенә кадәр уйланылган эш стратегиясе, оптималь технологик чылбыр, ышанычлы логистика... – әлеге кооперативта эшне оештыру зур кошчылык хуҗалыкларыннан бер дә калышмый. «ЭкоПтица» кобб-500, росс-308 бройлерларын үстереп җиткерү белән шөгыльләнә. Яхшы сыйфат – иң мөһиме. Һәм аны контрольдә тоту иң беренче көннәрдән үк башлана – мәсәлән, тәүлеклек чебешләрне йогышлылык вазгыяте кошлар өчен уңайлы булган төбәкләрдән генә сатып алалар. Чебешләр бик нәзберек, шунлыктан алар өчен тиешле шартлар тудырыла – анда оптималь температура, дымлылык, вентиляция көйләнергә, азык һәрвакыт җитәрлек булырга тиеш. Һәм бөтен технологик чылбыр буена шулай.

«ЭкоПтица» ит продукциясе тәмлелегенең төп үзенчәлеге шунда: кооператив кошларны билгеле бер кондициягә кадәр үстереп җиткерә торган хуҗалыкларны табигый азык белән тәэмин итә. Аларда хайваннардан алынган компонентлар юк – чөнки андый матдәләр продуктның тәмен начарайта. Табигый ки, бар этапта да ветеринария контроле мәҗбүри, шунлыктан әлеге тавык итенең сыйфаты бер дә шикләнерлек түгел.

Сүз уңаеннан, кош сую һәм ит эшкәртү цехы ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының «Яңа эш башлаучы авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативларының матди-техник базасын үстерү» программасының 5 миллион сумлык грант акчасына салынган. Бизнес үзе исә Уткино авылында кошчылык крестьян фермер хуҗалыклары оешкан вакыттан башланган. Аларның берсен Роза Тарасова, икенчесен аның улы Станислав Тарасов, өченчесен исә Руслан Котдусов җитәкләгән.

– Бу өч КФХ, шулай ук тагын 103 шәхси ярдәмче хуҗалык эшкәртү тәэминат-сату авыл хуҗалыгы кооперативына берләште дә инде, – дип сөйли «ЭкоПтица» җитәкчесе, Роза Ивановнаның кызы Татьяна Тарасова. – Ул вакытта безнең кошчылык корпусы бар иде – грант акчасына аны яңарттык. Әмма нәтиҗәле бизнес булдыруга һәм аның киләчәктәге үсешен тәэмин итүгә, әлбәттә инде, тырышлыкны берләштерү һәм дәүләт ярдәме булышты. Бүген «ЭкоПтица» – 106 кеше, 120 мең бройлерлык өч корпус, кош сую һәм ит эшкәртү цехы ул. Шулай ук безнең даими партнерларыбыз һәм гарантияле сәүдә базары да.

Кооперативта үстерелә торган бройлерларга Татарстанда гына түгел, Чувашия, Мари Эл, Удмуртия, Башкортостан һәм башка төбәкләрдә дә ихтыяҗ зур. Бер айлык чебешләр дә, ике айга кадәр үстерелгәннәре дә яхшы сатыла. Моннан берничә ел элек биредә шулай ук кросс Хайсекс Браун тавыкларын да үрчетә башлаганнар. Әлеге тавыклар йомырканы күп сала торган, шунлыктан аларны сатуда да бернинди кыенлык юк. Экологик чиста һәм тәмле кош итенә ихтыяҗ исә бик зур.

Уңышлы җитештерү – авыл терәге. «ЭкоПтица» – эш урыннары һәм лаеклы хезмәт хакы гына да түгел әле. Ул – авылдагы көндәлек социаль мәсьәләләрне хәл итүдә чын ярдәм дә.

«ЭкоПтица» кооперативында ирешелгәннәргә канәгатьләнеп тынычланырга җыенмыйлар: базар даими камилләшүне таләп итә. Биредә җитештерүне тулысынча цифрлаштыру нияте дә бар – цехлардагы микроклиматтан алып азык чыгымнарына кадәр бөтен нәрсәне автоматика контроленә тапшыру турында уйланалар. Фермаларга бара торган юлларны яхшыртуга да өметләнәләр. Татарстанда кооперативларга, фермер хуҗалыкларына максатчан даими ярдәм күрсәтелү, Фермерлар ассоциациясенең актив булышлыгы иртәгәге көндә ышаныч тудыра.

«ЭкоПтица» авыл хуҗалыгы кооперативы коллективы Фермерлар, крестьян хуҗалыклары һәм авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативлары ассоциациясе җитәкчесе Камияр Байтимеровны юбилее белән тәбрикли.

– *Хөрмәтле Камияр Мөҗәһитович! Безнең проблемаларга битараф булмавыгыз, еш үзгәрүчән икътисад шартларында фермерларга һәрвакыт ярдәм күрсәтергә әзер торуыгыз, яңа мөмкинлекләр белән даими таныштыруыгыз өчен рәхмәт сезгә! Күп хезмәт таләп итә торган эшегездә уңышлар һәм сәламәтлек телибез!*

Фото «ЭкоПтица» кооперативыннан алынды. РЕКЛАМА

ФЕРМЕРНЫКЫМЫ? МЕНӘ ШУЛ КИРӘК ТӘ!

Фермер эшенең никадәр авыр икәнен үземнән беләм. Моннан ун ел элек, банкротлыкка чыккан хуҗалык нигезендә КФХ оештырып, «мирас» буларак ташландык хәлдәге өч мең гектар сөрүлек җирләрне кабул итеп алганнан бирле... Эш шулай башланды.

Равил Бикчуров, «Бикчуров Р.А.» крестьян-фермер хуҗалыгы җитәкчесе

Фото «Бикчуров Р.А.» крестьян-фермер хуҗалыгыннан алынды. РЕКЛАМА

Ничек кенә булса да, югалып калмадык. Ташландык җирләр әйләнешкә кайтты һәм хәзер яхшы уңыш белән сөендерәләр. Хуҗалыгыбыз нык – бөртекле культуралар, шикәр чөгендере һәм көнбагыш үстерү белән шөгыльләнәбез. 500 000 кубометр сыйдырышлы буа кордык, хәзер 5 «Казанка» агрегаты чәчүлек мәйданнарны сугарып, яхшы икътисадый нәтиҗәләргә ирешергә мөмкинлек бирәчәк. Министр Марат Җәббаров ярдәме белән безне Татарстанда җиләк-җимеш тармагын үстерү юнәлешендәге 40 млн сумлык яңа программага керттеләр, хәзер тамчылы сугару проекты эшләнә. Проектны «Татмелиорация» траст компаниясе генераль директоры Рөстәм Сөнгатуллин һәм Марс Хисмәтуллин җитәкли.

Һәрбер фермер хуҗалыгының уңышлары нигезендә аның эшчеләренең авыр хезмәте ята. Әмма республика җитәкчелегенең, авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының аграрийларга ярдәменнән башка без әллә ни күп нәрсәгә ирешә алмас идек. Безнең Чүпрәле районында крестьян (фермер) хуҗалыклары эшкәртә торган егерме мең гектар җир районның барлык авыл хуҗалыгы продукциясенең егерме процентган артыгын бирә. Бу сан мондый ярдәмнең нәтиҗәлелеген раслый һәм фермерлыкның зур потенциалга ия булуын күрсәтә. Әгәр дә бу потенциал тулысынча – йөз процентка кулланылса? Нәтиҗә тагын да саллырак булачак дип ышанам.

Фермер хуҗалыкларыбызның чын мөмкинлекләре турында ишетеп кенә белүем түгел. Чүпрәле районы фермерлары ассоциациясе җитәкчесе буларак, хезмәттәшләремнең эшен, аларның планнарын анализларга, проблемаларының төбенә төшеп, аларны хәл итү юлларын эзләргә туры килә. Фермерларга ярдәм итүнең яңа программалары, бигрәк тә югары җитештерүчәнлеккә ия техника сатып алуда булышуны күздә тотканнары, чыннан да нәтиҗәле булачак дип ышанам. Кыенлыклар килеп туганда, Татарстан фермерлары беркайчан да ялгыз калмаячак. Татарстанның Фермерлар һәм крестьян хуҗалыклары ассоциациясе җитәкчесе Камияр Байтимеров менә инде 30 елдан артык мәнфәгатьләребезне һәркайда актив яклый һәм һәрвакыт ярдәм кулы сузарга әзер.

– Камияр Мөҗәһитович! Шәхсән үз исемемнән һәм Чүпрәле районы фермерлары исеменнән сезне юбилеегыз белән котлыйм! Сезнең күпкырлы авыр эшегездә уңышлар телим! Уртак планнарыбыз һәрвакыт тормышка ашсын. Яшәү мәгънәсен җирдә хезмәт итүдә күргән һәркем бәхетенә!

Хөрмәт белән, ТР һәм РФнең атказанган авыл хуҗалыгы хезмәткәре Равил Бикчуров.

ЫШАНЫЧЫБЫЗ ҺӘМ ТАЯНЫЧЫБЫЗ

Без, фермерлар, Камияр Байтимеров булганга сөенеп бетә алмыйбыз! Ул җитәкләгән ТР Фермерлар, крестьян хуҗалыклары һәм авыл хуҗалыгы кооперативлары ассоциациясе фермерлар өчен чын-чынлап яклаучы булып тора. Проблемалар, кыенлыклар килеп чыкса, без, фермерлар, беренче чиратта, Камияр Байтимеров һәм ассоциациянең башкарма директоры Гөлфирә Зыятдинова янына барабыз. Теләсә кайсы вакытта, көндез дә, төнлә дә. Кайчак хәл ителмәслек булып тоелган сораулар да чишелеш таба. Моны үз тәҗрибәмнән чыгып беләм. Әле дә хәтерлим: элек-электән үк минеке булган җирне законлаштыру өчен өч ел йөрдем, кая гына бармадым, тик нәтиҗә юк иде. Ә Камияр Мөҗәһит улы, минем проблемам турында белгәч, турыдан-туры министрга мөрәҗәгать итте, һәм мәсьәлә уңай хәл ителде! Ул искиткеч кеше һәм җитәкче, проблемаларыбыздан һәрвакыт хәбәрдар, хәлдән килгәнчә ярдәм күрсәтергә, киңәш бирергә һәрвакыт әзер.

Фото «Шакирова Л.Р.» крестьян-фермер хуҗалыгыннан алынды

– Хөрмәтле Камияр Мөҗәһитович!

Лилия Шакированың крестьян-фермер хуҗалыгы сезне юбилеегыз белән котлый. Сез безгә һәрчак булышып торасыз һәм илһамландырасыз. Безнең эштәге уңышларыбызда, мактаулы исемнәребездә сезнең дә өлешегез, сезнең дә хезмәтегез бар. Ә безнең өчен төп бүләк – безнең авыр хезмәтебезне һәрвакыт лаеклы бәяләвегез. Татарстанда фермерлыкны үстерүгә куйган тырышлыгыгыз һәрвакыт нәтиҗәле булсын, ә сезнең зирәк идеяләрегез һәркемдә яклау табып, үсеш алсын. Сезнең энергиягез һәм белемегез безнең авыл хуҗалыгы тармагына, барлык татарстанлыларга әле бик күп файда китерәчәк, дип ышанам.

БЕЗ БЕРГӘ КӨЧЛЕРӘК

Саба районының «Умырзая» кооперативы – авыл хуҗалыгы хезмәтчәннәренең, көч-тырышлыкны берләштереп, продукцияне җитештерү, эшкәртү һәм сатуның тулы циклын оештыру аша, нәтиҗәлелекне арттырырга булышу үрнәге ул.

Рамил Гарипов, «Умырзая» авыл хуҗалыгы кооперативы рәисе

«Умырзая» бүген – заманча терлек сую цехы, ит җитештерү цехы, ярымфабрикатлар, кисәкле ит җитештереп чыгару, 6 кибет, 4 автофургон-рефрижератор, эре мөгезле терлекләр ташу өчен 4 йөк автомобиле... Кооператив продукциясенең җитештерү масштаблары һәм базарда көндәшлеккә сәләтлелеге турында сүз алып барганда, саннар теле яхшырак. Әгәр 2018 елда биредә 526 тонна ит җитештерелгән булса, 2020 елда – бу сан өч тапкырга арта. Сату күләме дә бермә-бер күбәя: 2019 елда үсеш, аннан әүвәлге ел белән чагыштырганда, 232 процент тәшкил итә, 2020 елда тагын 132 %ка үсә. Бер узган елда гына да «Умырзая» 2027,8 тонна ит җитештереп, сатуга чыгара.

«Умырзая» әгъзалары – ике шәхси ярдәмче хуҗалык, дүрт крестьян-фермер хуҗалыгы, сигез авыл хуҗалыгы оешмасы. Аларны көчләрен берләштереп эшләп карарга этәргән фактор продукция сату проблемасын хәл итү теләге белән бәйле. Өметләре аклана: биредә терлекне кабул итү бәяләре канәгатьләндерә, ә итне үзләрендә эшкәртеп сату исә аларга бизнесның керемлелеген арттырырга булыша. Ит, субпродуктлар җитештерүгә киткән барлык чыгымнарны исәпкә алып санаганда, 2022 елда «Умырзая» кооперативының рентабельлеге 3,8 % тәшкил иткән. Җитештерү эше барлык санитария таләпләренә катгый туры килә, кооперативтан югары сыйфатлы итнең Саба, Кукмара һәм Теләче районнарының балалар бакчаларына, мәктәпләренә җибәрелүе һич очраклы түгел. Продукция шулай ук Казанга, Мәскәү өлкәсенә, Ижевскига да озатыла.

«Умырзая»ның уңышлары Татарстанда авыл хуҗалыгына даими рәвештә күрсәтелә торган дәүләт ярдәме белән турыдан-туры бәйле. Заманча терлек чалу цехы 2017 елда Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперациясен үстерү программасы кысаларындагы грантын отып төзелә.

Грантлар, субсидияләр аграрийларга базарда үз урыннарын ныгытырга булыша торган шактый саллы матди ярдәм тәшкил итә. Бу тармакны үстерү өчен дәүләт ярдәменең никадәр мөһим икәнен Татарстанда яхшы аңлаулары аеруча куандыра. Без, фермерлар, кооператор, абруй һәм хөрмәт казанган шәхес, Татарстан Республикасының Фермерлар, крестьян хуҗалыклары һәм авыл хуҗалыгы кооперативлары ассоциациясе рәисе, авыл хуҗалыгы хезмәтчәннәренең мәнфәгатьләрен сүздә генә түгел, эштә дә яклаучы Камияр Байтимеров кебек зат булуы белән дә бик үндык.

Юбилеегыз белән, Камияр Мөҗәһитович! Сезнең кыю идеяләрегез һәрвакыт тормышка ашсын.

Фото «Умырзая» авыл хуҗалыгы кооперативыннан алынды. РЕКЛАМА

ЧЫН ИПЕКӘЙ ТӘМЕ

Базарда бүген нинди продукциягә ихтыяҗ аеруча зур? Экологик яктан чиста, сыйфатлы, тәмле ризыкларга. Үзебез яшәгән тирәлектә үстерелгән һәм җитештерелгәненә. Кибет киштәсенә куелганчы, меңнәрчә чакрым үткәненә түгел...

– Унбиш ел элек Сарман икмәгенең мактаулы исемен торгызырга алынгач, мин дә алдыма әнә шундый һәркемгә аңлаешлы максатлар куйган идем. Ләкин эш шунда ки, аларны чынга ашыру өчен кредитлар алырга һәм шактый тир түгәргә туры килде – бер ай гына да, хәтта бер ел гына да түгел. Аның каравы, хәзер кешеләрнең күзенә карарга оялмыйсың: тырышлык бушка китмәгән, без пешергән ипекәйне Сарманнан тыш, җиде күрше-тирә районда да көтеп алалар.

Икмәк пешерү тармагын яңадан торгызганнан соң, сөт җитештерү юнәлешенә керешер вакыт җитте. Безнең сөт заводы озак еллар эшсез торды, үз теләк-ниятем белән генә, мин, бәлки, аңа җан өреп өлгерергә тотына да алмас идем: исән калган җиһазларның исеме генә бар, белгечләр дә, тәҗрибә дә юк... Әмма нәкъ менә шул вакытта Татарстан Республикасы Рәисе инициативасы белән авыл хуҗалыгы кооперативлары төзелә башлады, анык дәүләт ярдәме чаралары эшләнде һәм аларны гамәлгә ашырырга керештеләр.

Без сөт заводын аякка бастырдык, аңа заманча җиһазлар урнаштырдык, квалификацияле белгечләр дә табылды. Бүген Сарман предприятиесендә җитештерелгән сөт продукциясен дә ипиебездән ким яратмыйлар. Сарман сөтен, кефир, йогырт, катык, маен үзләрендә һәм күрше-тирә районнарда бик теләп сатып алалар, чөнки әлеге продукция сыйфатлы, табигый, яңа гына җитештерелеп сатуга чыккан.

Башкарылган эшләрне барлаганда, бу вакытта ярдәм кулы сузганнарның һичкайсының булышлыгыннан башка ниятләрнең барысын да тормышка ашыру мөмкин була алмаганлыгын аңлыйм. ТР Фермерлар, крестьян хуҗалыклары һәм авыл хуҗалыгы кулланучылар кооперативлары ассоциациясе башлыгы Камияр Байтимеровка аерым рәхмәт. Дөресен әйткәндә, аның киңәшләре, бәяләп бетергесез тәҗрибәсе, хакимият белән элемтәләр урнаштыра белүе минем өчен үзенә күрә осталык дәресләре булды. Бу дәресләр авыл хуҗалыгы кооперативын ачу һәм аякка бастыру чорында бик ярап куйды.

Камияр Мөҗәһит улы – республикадагы фермерлык, авыл хуҗалыгы кооперативлары хәрәкәтенең лидеры булуын сүздә генә түгел, гамәлләрендә дә күрсәтә. Фермерлык хезмәтенең авырлыгын үз җилкәсендә татыган зат буларак, крестьян хуҗалыклары тиешле ярдәмне алсын өчен, хәлдән килгәннең барысын да эшли, килачәкнең кооперация кулында икәнен аңлап, авыл хуҗалыгы җитештерүчеләре кооперативларга берләшсен өчен дә күп көч куя.

Камияр Мөҗәһитович! Сез җитәкләгән ассоциация – өметебез һәм таянычыбыз. Энергиягез, белемегез, аналитик фикерләү сәләтегез һәрвакыт кирәк булачагына ихлас ышанам. Юбилеегыз белән!

Рөстәм Нуруллин, «Сарман икмәге» һәм «Сарман-продукт» ЖЧҖ җитәкчесе

Фото «Сарман икмәге» ЖЧҖ тарафыннан алынды.

ЯНӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

Реклама бүлеге:

тел: (843) 222-09-79, +7-9600-487-900, +7-9033-132-741

Реклама 16+

ТАШБИЛГЕ: ИЗГЕЛӘР РУХЫ САКЛАНГАН ҖИР

ТАШБИЛГЕ

Фото: Александр Ефремов

Әлки районында «Татарстан» журналының тугры укучылары яшәгәнен беләбез. Ташбилге авылына баргач та, моңа тагын бер кат инандык – безнең журналга багышлап хәтта күргәзмә дә әзерләгәннәр иде. Аңа сөендек инде!

Ташбилге район үзәге Базарлы Матакка терәлеп үк тора. Моның уңай, тискәре ягы нидә? Зур булмаган авылда булып, аның олы шатлыклары һәм борчулары хакында белештек.

Руфия Фазылова

ДҮРТ ЯКЛАП КАБЕРЛЕКЛӘР...

Авылның исеме кайчандыр аерым язылган, хәзер исә әнә шулай Ташбилгегә әйләнгән. Бүген биредә 379 кеше гомер итә, 129 хуҗалык бар. Үз көенә тыныч кына яшәп ятучы бик борынгы авыл ул.

Салага ничә яшь икәнен төгәл генә белүче юк. Ләкин авыл башында изгеләр каберлекләре бар. Җирле халык ул җирләрне «изгелекләр» дип атый. Аларда төгәл нәрсә язылганын һаман да әйтә алмыйлар, гәрчә тарихчылар килеп караса да. Әмма аерым бизәк, язулардан күренгәнчә, бу каберлекләр болгар чорына караган булырга тиеш.

Ташбилге авыл җирлеге башлыгы Рәмзил Әхмәдиев безне ул изгеләр җирләнгән урынга алып барды. Әлеге изге урын дәүләт саклавында булган тарихи һәйкәл буларак теркәлгән. Авыл җирлегенең максаты – бу урынны тулысынча рәшәткә белән әйләндереп алу.

1
Иң нык сакланган ике каберлекнең тирәсе әйләндереп алынган.

2
Аерым бизәк, язулардан күренгәнчә, бу каберлекләр болгар чорына караган булырга тиеш.

3
Ташбилге авылы мәчетенә йөрүчеләрнең йөзендә нуры бар кебек тоелды.

– Үзсалым акчасының бер өлешен шунда тотарбыз дип торам, – диде Рәмзил Әхмәдиев. – Бу урында ничә кеше җирләнгәнен төгәл генә белмибез. Әмма шунысы хак: чынлап та серле, изге ул. Җәен кап-кара болытлар куркыныч булып килә дә, шушы урынга җиткәч тарала. Әйтмәгәнем булсын, безнең авылда каты гарасатлар, җил-давылларның булганы юк. Әнә шушы «изгелекләр» саклый дип уйлыйбыз. Әби-бабайлар да шулай дип сөйли иде.

Авыл җирлеге башлыгы белән изге урыннарны карап чыктык. Гаҗәеп җир: күпме серне, ә бәлки дәһшәтле вакыйгаларны сыйдыргандыр ул. Шул чорның шаһиты булып бүген бередә дүрт кабер ташы гына тора. Алар бер-берсеннән ерак урнашмаган. Иң нык сакланган ике каберлекнең тирәсе әйләндереп алынган. Бу Ташбилге авылында яшәүче абыйлы-энеле Нуруллиннарның изге гамәле икән.

«КОЛХОЗ БЕТҮ ХАРАП ИТТЕ...»

Серле, тарихи урыннан кайтканда, авылның мәчетенә кердек. Берничә бабай өйлә намазына әзерләнә иде. Гадәти көннәрдә – алты-җиде, җомга намазына ун кеше йөри икән.

– Ташбилгедә революциягә кадәр ике мәчет эшләп торган, – диде авылның имамы Исмәгыйль Ситдыйков. – Авылыбыз бик борынгы, дини булган. Менә архивларда утырып, шуның тарихын өйрәнгән кеше юк. Әни сөйли иде: «Революциягә кадәр, йортлар салырга дип, авыл башына, ягъни изгеләр күмелгән җиргә кадәр таяклар кактылар. Кеше күп булганга күрә, халыкка торак җитми иде. Тик 1921 елгы ачлыкта Ташбилгедә 658 кеше вафат булды. Шуннан авыл кечерәйде. Һәм теге сугылган таяклар шулай утырып калды, йорт салырга ихтыяҗ калмады...» Туксанынчы елларда авылда янә кеше күпләп кимеде – яшьләр сыйныфлары белән

диярлек шәһәргә китте. Болай барса, тагын бер ун-егерме елдан авыллар бөтенләй бетәчәк. Менә шушы проблеманы ничек булса да дәүләт контрольгә алсын иде. Журналга шулай дип яз, яме...

Исмәгыйль абый күп еллар колхозда механизатор булып эшләгән кеше, шуның өчен дә Ташбилгедә фермалар бетүгә бик борчыла. Шулай да авылның имамы белән күбрәк мәчет тарихы турында сөйләштек.

– Әлеге мәчетебез 1991 елда ачылды, – дип дәвам итте ул. – Бу урында гомергә мәчет булган. Совет власте килгәч, мәктәп балалар бакчасы булып та торган ул. Аннан исә элеккеге колхоз рәисе яңа мәчет салдырды. 1906 елда нарат агачыннан салынган иске мәчет бинасы әле хәзер дә бар, тик яраксыз хәлдә инде. Яңа мәчетебез башта бер генә яклы иде, тора-бара өстәп янкорма салдык. Аллаһ йортының манарасы киселгән, ишегенә йозак эленгән булса да, авылда диннән ваз кичмәделәр. Гает намазлары ел саен уздырылды. Аннары, авылның бик иманлы кешесе – Мансур абый бар иде. Сиксәненче елларда гает намазлары аның йортында узды. Ул махсус шулай ясады: өенең урта ягындагы бүлемнәре күтәрелеп куела иде. Алай иткәч, йортка кеше күп сыя бит. Шулай итеп, мәчет ачылганчы, Мансур абыйның йорты гыйбадәтханә ролен дә үтәде.

Мәчет картлары белән авылның үткәне турында сөйләшәбез: Ташбилге авылының колхозы миллионер исемлегендә йөргән. Тавык, куян, сарык, сыер, бозау фермалары – барысы да гөрләп эшләгән. Колхоз банкрот дип игълан ителгәннән соң, авыл җирләрен «Кызыл Шәрык» алган. Әле алар килгәч тә, фермалар буш тормаган. Куян, сарык асрамасалар да, мөгезле эре терлекнең баш саны берничә йөзләп булган. Тик өчдүрт ел элек кенә гөрләп торган ферма биналары бүген бушап, ярымҗимерек хәлдә калган.

Колхозда күп еллар баш агроном булып эшләгән Солтан Хәсәнов та мәчеттә иде. Авылның гөрләп торган чакларын бик сагынып искә алды ул:

– Безнең «Югары Актай» колхозы районда беренче булып миллионер исемен алды. Миллионер, ягъни колхозның исәп-хисап счетында 1 миллион сум акчасы бар дигән сүз. Безнең колхозның рәисе Сафа Гафиятуллин исемле кеше иде, ул күрше Карга авылыннан килеп эшләп йөрде. Сафа абый бик яхшы җитәкче булды, колхозыбызны шундый югарылыкка күтәрде. 1968 елда агроном булып эшли башладым. Ул инде колхозның дәрәҗәле чаклары иде. Эх, ничек матур яшәгәнбез!

Намус белән хезмәт иткәне өчен Солтан Хәсәнов «Татарстанның атказанган агрономы» исеменә дә лаек булган. Туган авылы өчен җан атып яшәүче Солтан абый бигрәк күңелгә кереп калды: сөйкемле сөяге бар. Гомумән, Ташбилге авылы мәчетенә йөрүче бу абыйлар, бабайларның һәркайсының йөзендә нуры бар кебек тоелды.

4

Намус белән хезмәт иткәне өчен Солтан Хәсәнов «Татарстанның атказанган агрономы» исеменә дә лаек булган.

МӘКТӘП АТА-АНАЛАР ТЕЛӘГЕ БЕЛӘН ЯБЫЛГАН...

Ташбилгедә мәктәп юк. Гәрчә авылда гомергә башлангыч мәктәп булган, ә ике ел элек белем үзәген япканнар. Илленче елларда авылда җидееллык мәктәп тә эшләгән. Тик аннан соң, балалар саны азаю сәбәпле, аны башлангычка калдырганнар.

– Ата-аналар балаларны Базарлы Матакка йөртеп укытырга үзләре теләде, – диде Ташбилге авылы китапханәчесе Рузалия Абдуллина. – Мәктәп булганда безгә дә рәхәт иде: балалар өйләренә кайтканда китапханәгә керми калмадылар. Хәзер автобус белән йөргәч, алай көн саен кермиләр шул. Соң да кайталар.



5

– Мәктәп булганда безгә дә рәхәт иде: балалар өйләренә кайтканда китапханәгә керми калмадылар, – ди Рузалия Абдуллина.

– Ә ни өчен авыл мәктәбендә укытырга теләмәделәр? – дим.

– Хәзер бит шулай: ата-ана баласын яхшырак шартларда укысын, ди. Аннан, алар бишенчегә барыбер район үзәгенә бара, ияләнә торсыннар диючеләр дә булды. Югыйсә безнең башлангычлар мәктәбе бер дигән, укытучылар да тәҗрибәле иде. Ләкин ата-ана сүзенә каршы килеп булмый...

Ташбилгенең мәдәният йорты, китапханәсе менә дигән. Ике ел элек капиталь төзекләндерү үткәрелгән. Заманча, якты, җылы ул. Китапханәче Рузалия апа сүзләренә караганда, мәдәният йорты белән бергә эшлиләр. Өлкәннәр өчен төрле түгәрәкләр бар. Шунда йөрүче апалар белән махсус хәрби операция зонасына кирәк-яраклар әзерлиләр. (Сүз уңаеннан, Ташбилгенең ике егете мобилизацияләнгән. Без барганда аның берсе кыска вакытлы ялга кайткан иде.)

– Эшләргә бик уңайлы, рәхәт, – диде Рузалия апа. – 1987 елда Казан дәүләт мәдәният институтының китапханәчеләр факультетын тәмамладым. Башта район үзәгендә эшләдем, аннан мәктәптә рус теле укыттым. Ә 2000 елдан бирле биредә хезмәт итәм. «Татарстан» журналын бик яратабыз, чаралар үткәргәндә дә файдаланабыз.

6

Ташбилгенең мәдәният йорты, китапханәсе бер дигән. Ике ел элек капиталь төзекләндерү үткәрелгән.

7

Мәктәп булмаса да, авылда балалар бакчасы бар. Анда ун бала йөри.

БАЛАЛАР БАКЧАСЫ – АВЫЛ КҮРКЕ

Мәктәп булмаса да, авылда балалар бакчасы бар. Анда ун бала йөри. Хәер, Ташбилгедә мәктәп яшендәге балалар да кырыктан артык. Әгәр белем йорты авылда булса, класс саен укучы булыр иде...

Балалар бакчасы дидем. Ул башлангыч мәктәп белән бер бинада булган. Хәзер исә зур бер бинаны үзләре генә били. Балалар бакчасында өч төркем эшләгән чакларны да әле күпләр хәтерли. 1990 нчы елларда исә ул ике төркемгә калган, ә хәзер бер генә.

– Бу бина 1986 елда салынган, – диде Ташбилге авылы балалар бакчасы мөдире Гүзәлия Зәйдуллина. – Чорына күрә заманча итеп, махсус эшләнгән. 2013 елда капиталь төзекләндерү булды. Шуннан нәниләргә бер төркем генә ясап, бинаның икенче ягын башлангыч мәктәпкә итеп эшләделәр. Инде менә ике ел мәктәп балалары юк, күңелсез калды. Әле бөтен бәйрәмнәрне бергә үткәрә идек, гөрләп тора иде монда.

Бакча мөдиреннән кала, биредә бер тәрбияче, бер пешекче, ярты ставкада тәрбияче ярдәмчесе эшли. Татар балалар бакчасы санала, шуның өчен сабыйлар бер дигән итеп татарча сөйләшә. Нәниләргә барлык шартлар да тудырылган: йокы, уен, ашау бүлмәләре

аерым. Тәрбияче апалары исә аларны дүрт-биш яшьтән хәреф танырга, санарга өйрәтә. Шуның өчен малай-кызлар мәктәпкә тулы әзерлек белән бара икән.

– Җәен бакчабыз шау чәчәктә була, – диде Гүзәлия Зәйдуллина. – «Иң матур бакча» конкурсында катнашып, район буенча призлы урыннар алабыз. Әти-әниләргә, балаларга да күңелле булсын, дип тырышабыз.

ФЕРМЕР БУЛУ ҖИҢЕЛМЕ?

Авылда көтү юк. Өч-дүрт ел элек хуҗалыкларда йөз баштан артыграк сыер булса, хәзер өч дистәгә дә тулмый. Сәбәбе бик гади – халык өлкәнәя, ә мал асрауның файдасы юк. Быел литры унҗиде сумга калган сөт бәясе белән сатып алынган печән, игеннең бәясен чагыштырсаң, сыер асраучының минуста калганлыгын аңлыйсың.

Шулай да Ташбилгедә мал саны аз түгел, чөнки эре фермер бар. Салават Нуруллин хуҗалыгында 70 баш сыер, уннан артык ат, берничә дистә бозау исәпләнә. Егет 2017 елда КФХ булып теркәлгән. Шул елдан бирле баш санын киметмичә, матур гына эшләп килә фермер.

– 2018 елда эш башлаучы фермер буларак дәүләттән 3 миллион сум күләмендә грант откан идем, – диде Салават. – Ул акчага ферма бинасын төзедек. Дөресен генә әйткәндә, монда бөтен гаиләбезнең көче керде: абыйның да, этинең дә. Шулай булгач, аны гаилә фермасы дип тә әйтеп була. Ә рәсми рәвештә КФХ минем өстә. Бездә читтән биш кеше эшли: ике сыер савучы, ике терлекче, бер бозау караучы. Савым бинасында барысы да көйләнгән: савылган сөт махсус торбалар аша суыткычка китә. Сыер савучылар чиләк күтәреп интегеп йөрми. Хәер, хәзер күп җирдә шулай: тора-бара бу эшне фәкать роботлар гына башкарыр әле. Хәзер хуҗалыкта да кул белән сыер савыш бетте бит. Бер шәхси эшмәкәр, көн саен килеп, сөтне алып китә. Бүгенге көндә литры егерме биш сум илле тиенгә күтәрелде.

Фермер хуҗалыгында унлап ат та бар. Аларны хуҗа кеше фәкать күңел өчен асрыйбыз, ди. Атлар яраталар икән. «Атларны суеп ашамыйбыз, кул күтәрелми. Ә менә колыннарны сатабыз», – диде Салават.

Нуруллиннарның ике йөз илле гектар җире дә бар. Халыкның пай җирләрен арендага алганнар. Фермадагы малларга азыкны тулысынча үзләре әзерлиләр. Игенне чәчү, җыю өчен бөтен төр техниканы табыштырганнар. «Иске техникаларны берәм-берәм сатып алдык», – ди яшь фермер.

8

Салаватка егерме җиде яшь. Туган нигезендә әти-әнисе белән яши.

Бүген фермерларның күбесе токымлы сыерлар алырга тырыша. Салаватның исә бу нисбәттән үз фикере:

– Яхшы ашатсаң, тәрбияләсәң, үзебезнең сыерлар да әйбәт сөт бирә. Бозаулаган чорда өчәр тапкыр да савабыз. Тәүлегенә 25–30 литр сөт бирәләр. Малның яшенә дә карый бит. Ел саен сыерларны яңартып торабыз. Үгез бозауларны үстереп иткә озатабыз, ә таналарның яхшыларын сыер итәбез. Соңгы елларда гел шул тәртип белән эшлибез, Аллаһка шөкер. Фермерлык эшен бер көйләсәң, бара инде ул. Әлбәттә, ягулыкка бәя кыйммәт, ә сөткә, игенгә бәя арзан булу безне дә борчый. Тик кул кушырып утырмыйбыз, башладың икән, эшләргә кирәк.

Салаватка егерме җиде яшь. Туган нигезендә әти-әнисе белән яши. Әлегә гаилә кормаган. Егет авылда калган һәм шуңа бер дә үкенми. «Шәһәрдә яшәп карадым, һавасына кадәр яратмадым», – ди.

... Әлкидән һәрчак күтәренке кәеф белән кайтыла: дуслар белән аралашканнан соң башкача мөмкин дә түгелдер. Ташбилгедә дә яңа дуслар таптык. «Тагын килегез», – дип калдылар. Килербез, чөнки әле биредә без күрмәгән урыннар, аралашмаган кешеләр байтак калды.

ТАРИХ СӘХИФӘЛӘРЕННӘН

Ташбилге авылы заманасында бик тарихи татар авылы булган. Тарихчы-археолог Һарун Йосыпов бу авыл зиратында XIII–XIV йөзләргә мөнәсәбәтле кабер ташы язмалары тапкан.

Ташбилге авылы оешу турында бер риваять яши: Бөек Болгар Аксак Тимер тарафыннан тармар ителгәч, Мөслим бабай һәм аның кардәш кабиләсе биредәге Актай елгасы буена килеп утырган. Яңа оешкан авылга Таш Билге дигән исем биргәннәр. Бу турыда татар халык иҗатының «Риваятьләр һәм легендалар» томында язылган.

Мөслим бабай бик галим һәм кыю кеше булган. Аның абруе зур саналган. Шәһри Болгар ханы да, Мөслим бабайны олылап, аңа кадер-хөрмәт күрсәткән, диләр.

(Авыл китапханәсендә тупланган материалдан).

«КОРОЛЕВА МАРГО» КҮЛМӘКЛӘРЕНДӘ (0+)

Танылган фильм геройлары кигән костюмнарны, шулай ук төшерү барышында кулланылган аксессуар һәм бутафорияне «Закройщики иллюзий» дип аталган күргәзмәдә күрергә мөмкин. Бу – Мәскәү кино музее белән илебез кинематографының әйдәп баручы рәссамнарының берсе Дмитрий Андреевның уртак проекты. Күргәзмә Пушкин, Лермонтов, Лев Толстой һәм Достоевскийның классик әсәрләрен экранлаштырудан алып Алексей Ивановның «Тубыл» романына, Александр Дюманың «Королева Марго» романына һәм Оскар Уайльдның «Идеаль ир» пьесасына кадәр дистәләгән картиналар төшерү өчен эшләнгән материалны тәкъдим итә. Экспозициягә 42 костюм комплексы, аксессуар һәм бутафория, шулай ук костюмнар буенча рәссамнарның фильмнарга ясалган эскизлары кертелгән. Күргәзмәне «Эпоха – Модельер» уникаль фотофильмы тулыландыра.

Кабул итү урыннарының Күргәзмәләр залы,
«Казан Кремле» музей-тыюлыгы

СӘХНӘ АРТЫ СЕРЛӘРЕ (6+)

Сәхнә арты серләренә төшенү, спектакльне әзерләү процессына күз салу тормышка ашмаслык хыял түгел. Опера һәм балет театры үз спектакльләренең ачык репетицияләренә килергә чакыра. Гадәттә тамашачыга күренми торган бөтен нәрсәне дә диярлек күрергә мөмкин. Сез гадәти киемнәрдә репетицияләр үткәрүче артистларны күрә, режиссер һәм «сәхнә арты» белгечләренең эшен күзәтә алачаксыз. Ә тамашачы театр дөньясына тулысынча чума алсын өчен, репетиция алдыннан спектакль турында лекция үткәрелә. Проект яшьләргә исәпләнгән, шуңа күрә ул «Театр – яшьләргә» дип атала да.

17 ноябрь, 17:15 сәгатьтә – «Шүрәле» балетының ачык репетициясе.

М. Җәлил исем. Татар дәүләт опера һәм балет театры,
Казан, Ирек мәйданы

«СИТСА ТУЙ»ГА ЧАКЫРУ (16+)

Ситса туйны, билгеле булганча, бер ел бергә яшәгән яшь парлар билгеләп үтә. Тик яшьләр хөрмәтенә тостлар һәм матур теләкләр яңгыраганчы, аларга тамашачылар белән бергә шикләнү һәм ачышлардан торган юл үтәргә туры киләчәк.

Классик әйткәнчә, бөтен бәхетле гаиләләр дә бер-берсенә охшаш, ә бәхетсезләре һәркайсы үзенчә бәхетсез. Илгиз Зәйниев пьесасында да дүрт яшь пар үзләренең ситса туйлары көнендә көтмәгәндә аерылышыр дәрәҗәгә җитәләр. Һәр гаиләнең үз сере, үз сәбәпләре һәм үз сынаулары...

Ни өчен бер-берсен яраткан парлар кинәт кенә аңлаша алмый башлый соң? Нигә гаилә тормышында мондый проблемалар килеп туа? Әлеге тормыш сынауларын ничек җиңеп чыгарга?

Спектакльдә артистлар башкаруында татар эстрадасы хитлары да яңгыраячак.

23 ноябрь, 12:00; 19:00 сәг.
10 декабрь, 12:00; 18:00 сәг.
Г. Камал исем. ТДАТ, Казан, Татарстан ур., 1

Фото: kamalteatr.ru, tatar-inform.ru, kazan-kremlin.ru, tinchurinteatr.ru, Г. Тукай исем. Филармония матбугат хезмәтеннән алынды

БҮЛӘККӘ – МЫЛТЫК (16+)

Совет лидеры Леонид Брежневка Финляндия Президенты Урхо Кекконен бүләк иткән ау мылтыгын күрәсегез киләме? Ә безнең генераль секретарьга Монголия халык-революцион партиясенең генераль секретаре Юмжагин Цеденбал бүләк иткән мылтыкны? Яки Куба Республикасы оборона министры Рауль Кастроның СССР маршалы Родион Малиновскийга бүләк иткән пистолет-пулеметын? Шундый уникаль экспонатларны Казанда РФ Кораллы көчләре Үзәк музее фондларыннан «Күренекле Россия һәм совет хәрби эшлеклеләренең бүләк кораллары» күргәзмәсендә күрергә була. Биредә шулай ук илебезнең танылган хәрби җитәкчеләренең исемле пистолетлары, мылтыклары, салкын кораллары, шулай ук аларның шәхси әйберләре тәкъдим ителгән.

Көн саен 10:00 дән 18:00 сәгатькә кадәр (җомга – 11:00 - 20:00 сәг.). Ял көне – дүшәмбе
Туп ишегалды музее, «Казан Кремле» музей-тыюлыгы

ЯҢА МӘКТӘП (12+)

Кариев театры быел «КАРАШ» инсценировка мәктәбен оештырды. Нишләп әле үзебезгә татар классик әдәбияты буенча инсценировка язарга өйрәтә торган мәктәп булдырмаска дигән ниятне шулай тормышка ашырдылар биредә. 17 егет һәм кыз бер атна дәвамында драматургия нигезләрен үзләштерде. Соңрак үзләренә ошаган әсәрне сайлап, инсценировканың беренче күренешләрен яздылар.

Тиздән «өй эшен» тикшерәчәкләр. Татарстан театрларының директорлары, режиссерлары, артистлары, композиторлары, рәссамнары, тәнкыйтьчеләре һәм, әлбәттә, тамашачылар тавыш бирү ярдәмендә иң-иң эшләрне ачыклаячак. Иң күп балл җыйган әсәр Кариев театры сәхнәсендә куелачак, икенче урынны алган эшләр исә башка театрлар портфеленә тәкъдим ителәчәк. Сезне «читка»ларга чакырабыз! Керү иркле.

21 ноябрь, 16:00 сәг.
Кариев исем. Казан яшь тамашачы театры, Казан, Петербург ур., 55 Б

«РОССИЯНЕҢ АЛТЫН ТАВЫШЫ» – КАЗАНДА (6+)

Түбән Новгород опера һәм балет театры солисты, РФ президенты премиясе һәм «Алтын битлек» театр премиясе лауреаты Венера Гыймадиева (сопрано) Казанда кунакта. Кичәдә Г. Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Анатолий Шутиков җитәкчелегендәге ТР Дәүләт халык уен кораллары оркестры чыгыш ясаячак. Оркестр концертлары Татарстан һәм Россия шәһәрләрендә, Австрия, Германия, Голландия, Көньяк Корея, Италия, Болгария, Португалия кебек илләрдә уңыш казанды. Югары башкару культурасы, әсәрнең формасын һәм стилен яхшы тоеп эшләү коллективның иҗади йөзен билгеләде. Программага арияләр, рус һәм чит ил композиторлары опералары, шулай ук эстрада көйләре дә кергән. Концертны музыка белгече, Татарстанның атказанган артисткасы Лилия Аппакова алып бара.

Концертка «Пушкин картасы» программасы буенча керергә мөмкин.

23 ноябрь, 18:30 сәг.
Г. Тукай исем. Татар дәүләт филармониясе, Казан, Павлюхин ур., 73

САЙРА, БЫЛБЫЛ, САЙРА! (6+)

Гомер көзе иң шатлыклы вакыт түгел, тик «Ай, былбылым!» комедиясе геройлары һич тә алай дип уйламый. Алар гомерләре көзендә, төрле сәбәпләр аркасында, картлар йортына эләккән. Ләкин алар үзләренең биредәге тормышын һич кенә дә гомернең «соңгы туктальшы» дип кабул итми. Хәтта Гөлҗәннәт белән Фикус кавышырга да ниятлиләр. Тик кара күзлекле Рәхимҗан пәйда булгач кына, вакыйгалар агышы башка төс ала.

Спектакль тамашачыны җылы атмосферасы, матур куелышы һәм театрның өлкән буын сәхнә осталарының ихлас уены белән җәлеп итә.

24 ноябрь, 18:30 сәг.
К. Тинчурин исем. Татар дәүләт драма һәм комедия театры, Казан, Горький ур., 13

айкәфе: бәйрәмчә

КАЗ КАНАТЫ КАУРЫЙ-КАУРЫЙ...

Элек-электән татар халкы салкыннар җитү белән, кош-кортын, мал-туарын суеп, озын кышка әзерләнгән. Шактый мәшәкатьле саналган бу эшләрне алар өмә җыеп башкарган. Каз өмәсе – әби-бабаларыбыздан килгән шундый күркәм йолаларның берсе.

Өмәдә каз итеннән бәлеш пешереп кунакларны сыйлаганнар. Казларны тозлау, каклау да популяр булган. Никах-туйларга каздан сый әзерләнгән, пар каз бүләк итү дә матур гадәт булып кереп калган. Каз мамыгыннан мендәр-ястык ясаганнар. Җиткән кызлары булганнар бирнәгә дип мамык мендәрләр тутырган.

Әлеге күркәм йола бүген дә саклана. Күптән түгел генә Казанда, Кабан күле буенда урнашкан Иске Татар бистәсендә, «Каз өмәсе» бәйрәме үтте. Бәйрәмдә Габдулла Кариев исемендәге Казан яшь тамашачы театры артистлары шәһәр халкы һәм кунаклары өчен музыкаль-театральләштерелгән тамаша һәм кышка казлар әзерләү милли йоласын күрсәтте. Тамаша вакытында казларны чистарту, Кабан күле буена төшеп юу кебек эшләр башкарылды. Бәйрәмгә килгән халык җыр-биюләрдә, такмак әйтешләрдә, уеннарда катнашты. Кунаклар шулай ук кайнар чәй, мичтә пешкән коймак белән сыйланды.

Безнең фотохәбәрчебез дә әлеге бәйрәмдә булып кайтты һәм тамашаның иң күңелле мизгелләрен фотосурәтләрендә теркәде.

Фотолар: Александр Ефремов

Об'явление работы худ. Л. Гамбургер.

«Татарстан»журналының реклама бүлеге:
тел.: (843) 222-09-79, 8-9600-487-900, 8-9033-132-741

Реклама 16+